Безнең МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

06

июнь 2019

ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ГРИГОРИЙ МЕДВЕДЕВ «АХИРӘТЛӘР»

Фотолар shaimiev.tatarstan.ru сайтыннан алынды

КАЗАН КРЕМЛЕНДӘ КИҢӘШМӘ

Казан Кремлендә Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе һәм «Яңарыш» республика фондының Попечительләр советы рәисе Минтимер Шәймиев Татарстан Республикасында беренче күптелле белем бирү комплекслары проектын гамәлгә ашыру концепциясен эшләп бетерү һәм аның барышы буенча киңәшмә уздырды.

Анда ТР мәгариф һәм фән министры Рафис Борһанов күптелле белем бирү комплексларының эшләп бетерелгән концепциясен тәкъдим итте. Фикер алышуда КФУ ректоры И.Гафуров, Түбән Кама, Алабуга һәм Арча районнары башлыклары А.Метшин, Г.Емельянов, И.Нуриев, Казанның 165 нче мәктәбе директоры А.Шәмсетдинов һәм Казанның 121 нче лицее директоры В.Афонская катнашты.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС

12 +

06 (306)

июнь 2019

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

17

38 РИЗАЭДДИН КАЗЫЙ САБАКТАШЫ ХӨСНУЛЛА АХУН



89 ЙОЛДЫЗНЫҢ НУРЛЫ УЛЫ. *Рабит Батулла*

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 **Зыя Ярмәки**

ТАРИХИ МИРАС

4 **Сөембикә.** *О.Иванова*

10 **Бер мәктәпнең кыскача тарихы.** *К.Нәҗми, Я.Мамкиев, И.Хәмзин*

13 **Таҗетдин хәзрәт чишмәсеннән...** *Р.Ахунҗанова*

17 **Казан ханлыгында ислам дине.** *Ә.Әкъсәнов*

20 **Чат татарлары.** *Ф.Бәйрәмова*

28 **Новосибирск шәһәренең мәдәни тормышыннан кайбер сәхифәләр**

34 **Камышлы хатирәләре.** *М.Зәйнетдинов*

38 **Ризаэддин казый сабакташы Хөснулла ахун**

45 **Рафаэль Бәһаветдинов: «Без рухи-әхлакый хәзинәләрне сакларга тиеш!»**

52 **Әйт, авылым, кайда соң моң?** *Э.Шәвәлиева*

ТАТАР ГАМЕ

56 **Әмир Гәрәев: «Татар мәдәниятенең байлыгы – безнең горурлыгыбыз!»**

62 **Күңеле пакьнең эше дә ак.** *Т.Галиуллин*

70 **Сусау ләззәте.** *Г.Морат*

ДИНИ МИРАС

74 **Ислам дөньясы.** *Габдерәшит Ибраһимов*

ӘДӘБИ МИРАС

80 **Ярмәк әдибе Г.-Халикъ Садри.** *А.Имамиева*

82 **Безнең таң.** *Г.-Халикъ Садри*

89 **Йолдызның нурлы улы.** *Р.Батулла*

93 **Үпкәләрмен кебек.** *Р.Мингалим*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)
Лотфулла Шәфигуллин
(«ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Альберт Борһанов
Мөдәррис Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-93)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-93)

Бүлек мөхәррире
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

ХӘТЕР САНДЫГЫ

94 **Фәтхуллиннар эзе.** *Ә.Зарипов*
104 **Истә, һаман да истә!**

СӘНГАТИ МИРАС

106 **Борынгы татар милли музыка уен кораллары**

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

108 **«Татарстан»** *Р.Сәфәров*
110 **Ә маймылы кайда?** *М.Әгъләм*
111 **«Сүзләр тавыш биреп атлыйлар...»** *Г.Мөхәммәдкәрим*

ХӘТЕР САГЫНДА

112 **Татарстан Республикасының Милли китапханәсе**

116 **«Безнең мирас» хәбәрләре**
118 **Мирасворд**
119 **«Безнең мирас» елъязмасы**. *Июнь*

Заказ №О-1373. Тираж – 2800 данә. Формат 70х108 1/16.
Басарга кул куелды: 23.05.2019.
Чыгу көне: 29.05.2019
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе иркле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела. Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, Кукмара туган якны өйрәнү музееннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды. Тышлыктагы Ә.Тумашев рәсемнәре ТР Дәүләт сәнгать музее тупланмасыннан алынып бирелде.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – **«Ахирәтләр»**. 1924. ***Григорий Медведев рәсеме***

Зыя Ярмәки
(1887-1965)

АК КАЕН

Яфраклары яшел ак каенның
Хәтфә җәйгән кебек һәр ягы.
Әйлән-бәйлән уйный яшь балалар,
Гөрләп тора һәр көн тау ягы.

Яшь балалар, бигрәк матур кызлар
Ак каенны сөеп мактыйлар.
Яз башында алар һәр ел саен
Ак каенда бәйрәм ясыйлар.

Ап-ак каен — инде бик карт каен,
Бизәлә ул язлар килгәндә.
Яшел яфрак яра һәр ел саен,
Кояш җылы нурлар сипкәндә.

Ап-ак каен инде бик карт каен,
Яшьләр күңеле аның куенында.
Ялгыз үсә, ялгыз гына яши
Әүлияләр тавы буенда.

---

*Шагыйрь Зыя Ярмәки (Әхмәтзыя Шәйхетдин улы Насыйров) 1887 елның 9 (яңа стиль белән – 21) гыйнварында элекке Самара губернасының Богорыслан өязе (хәзер Самара өлкәсенең Камышлы районы) Иске Ярмәк авылында мулла гаиләсендә туа. 1965 елның 26 ноябрендә Ташлак авылында (Үзбәкстан, Фирганә өлкәсе) вафат була һәм Фирганә өлкәсенең Маргилан шәһәрендәге Хуҗагәз зиратында җирләнә.

Безнең мирас №6 июнь 2019

СӨЕМБИКӘ

Ольга Иванова

«Сөембикә». Билгесез рәссам эше

Тәрҗемәчедән:

Бу өзектә дә, вакыйгалар агышына бәйле рәвештә, Сафагәрәй хан шәхесе алгарак чыгып торачак.

Дата-тарихларны, кайбер исем-тасвирламаларны, белгәнебезчә, рус чыганакларына таянып язган булса да (ул чорлар беренче кул татар язма чыганакларында теркәлеп калмаганлыктан), Һади Атласи аларга, үз күзлегеннән чыгып, объектив бәя бирергә тырыша: «Русларның Казан өстенә килүләре Казан коткычыларының чакыруы буенча булган икәнлеге Сафагәрәйгә беленде. Ханның ул эшкә ачуы кабарып, «йорт»ны русларга сатарга тырышкан бәкләрне үлем илә җәзалый башлады...» Илгә бүре китергән этләрдән һәм тәхет дошманнарыннан үч ала алуын Сафагәрәй, тик үзен Казан халкына каршы куярлык хаталы гамәлләр дә кыла... Кыйсса мөәллифе (авторы), мәгълүм риваятькә ияреп, бу уңайдан Гәүһәршадның да соңгы сәгатен тасвирлый. «Сафагәрәй хан Казан корткычларын ничаклы нык җәзалап, аларның тамырын корытырга тырышты исә дә, бөтенләй бетерә алмады... Болар, борынгыдан бирле, йорт өчен кирәкле булган эшләрне эшләүдә берләшә алмасалар да, аны сатар өчен булган эшләрдә тиз берләшәләр иде. Бу юлы да шулай булды... 1545 елның 29 июлендә Казан бәкләреннән Кадыш илә Чура, Иванга кеше юллап, аңардан Казан өстенә яу җибәрүне үтенде. Сафагәрәй ханны, шулай ук аның якыннарыннан булган 30 Кырым бәген тотып русларга бирергә булдылар...», – дип әрнеп яза мәшһүр галимебез.

Әлеге фаҗигале-канлы вакыйгаларның әдәби әсәрдә ничек чагылуын чагыштырып карау өчен, алга таба укуны дәвам итик.

Әмма Казан диваны башлыгының ханга каршы яшертен эш йөртүнең җепләрен чуалтырга, яшерергә тырышуы юкка гына булып чыкты. Кечүк инде Шириннең мәкерле ниятләренә кушылган башка аксөякләрнең дә эзенә төште. Рәхимсез җәзалауларга түзә алмыйча, алар берәм-берәм сер капчыгын чишәргә мәҗбүр иделәр. Шул рәвешле, фетнәчеләрнең тулы исемлеге хан кулына килеп иреште.

Үч алу шул ук көнне башланды. Сафагәрәй әмере белән, Кырым яугирләре атаклы

Дәвамы. Башы журналның 2019 елгы 3 нче санында.

Казан түрәләренең ишеген каерып ачты, аларны, тиешле җәзасын күрсәтергә, дип, урамга сөйрәп чыгардылар. Башкала акырган-бакырган тавышларга, туктатып булмастай елау-сыктау авазларына тулды. Гади халык, ярсу җайдакларга юлыкмас өчен, өйләреннән баш сузып карарга да курыкты. Зиндан тиз арада ташып чыгардай булып бүселде. Төрмә хөҗрәләренең «кара балыгы» бик тиз арада Булатширин, Әхмәтаргын кебек хан йортының элегрәк буй җитмәслек түрәләрен дә үз карынына йотты. Болар арасында бары тик Гәүһәршад кына күренмәде; юк, бу – хан нәселеннән булган хатынга Сафагәрәйнең кагылырга куркуыннан түгел иде. Танылган ханәкә башкаладан гына түгел, ханлыктан да томандай эреп юкка чыкты, югыйсә, ачуы кабарган хакимнең боерыгын үтәп, аны бөтен даругалардан, хәтта кечкенә авыллардан да эзләп карадылар. Ибраһим белән Нурсолтанның баш бирмәс кызы кайда яшеренгәнен берәү дә белмәде. Бары тик Кабан күленең җилле-давыллы төннән соң куерган салкын сулары гына ул серне чоңгылларына чумырып, бүтән беркемгә ишетелмәслек итеп, эченә йомды...

Кала буйлап кулга алулар дулкыны ишелеп килә башлауга, ханәкә әллә ни зур булмаган бер көймәне әзерләп, суга төшерергә кушты. Ул гадәти юл белән – кырымлылар сагында калган шәһәр капкалары аша түгел, ә су буйлап – Болактан Кабан күленә төшеп качты. Ярдагы кайчандыр яратып йөргән Турыише белән кереп сыенган истәлекле җир йортта аны соңгы мәгъшугы – тугрылыклы угланнарның берсе көтә иде. Чит-ят күзләрдән яшеренгән җитез атларны иярләгән тән сакчылары исә, алдан күрүчән ханәкәне үз канатлары астына алып, Нугай далаларына озатырга әзер торды.

Шулай эз яздырган сәгатьтә көтмәгәндә генә Болакта җил уйный башлады һәм Гәүһәршад җылы япмасына ныграк төренергә мәҗбүр булды. Елганың кара-кучкыл суларына борчыла төшеп, кашларын җыерып күз ташлады ханәкә. Шактый иркен көймә Болак буйлап җиңел генә шуып китте, көзге җил тавышы аша аны эзәрлекләве мөмкин булган хан кешеләре дә ишкәк чупылдавын ишетмәгәндер. Хатын әсирләрнең нык куллары каекның юнәлешен дөрес тотканын тавыш-тынсыз гына күзәтте, аннары аның битараф-салкын карашы ирләрнең кырыс чырае буйлап шуып үтте. Тегеләре исә, әле үзләренең ошбу әҗәл тагарагында, җан сорап тарткан дулкыннар авызына таба ишүләрен белмичә, беренче кат күргән ханым-әфәндегә ярарга тырышты. Ханәкә ничек эз югалтырга икәнен яхшы чамалый, аның качканын күргән шаһитларны, әлбәттә, исән калдырырга ярамый иде. Ул кабыргасын җылытып торган кечкенә сандыкны сыйпаштырып куйды, анда хан кызына чит-ят җирдә бер авырлык та күрмичә яшәрлек хәзинәсенең бер өлеше ята. Бу тәңкәләр һәм асылташлар, алтын-көмешләр кайчан да булса, аңа, башын горур тотып, тантаналы рәвештә Казанга кайтырга ярдәм итәр әле. Монда ханәкәнең иксез-чиксез байлыгыннан бер тамчы гына, ханлыкта аның сарайлары, биләмәләре калып тора, бу юлы аларны үзең белән алып китү мөмкин түгел шул.

Гәүһәршад, тынын да алырга куркып, тирә-ягына колак салды. Җил тагын да усаллана төште, искән саен ныгый гына барды. Үзләрен сизеп-күреп алуларыннан куркып, әсирләр мешалеләргә[1] ут элдермәделәр, әмма аларны әзер тоталар иде. Көймә, җил белән көрәшә-көрәшә, ипсез борылыш ясап, Кабанга килеп керде. Яннан китереп бәргән дулкын аны дер селкетеп алды, ханәкә ирексездән кычкырып куйды. Көймә кырыннан чайпалган су аякларны чылатты. Ханым-әфәнде, тешләрен кысып, сандыгына ныклабрак ябышты, ярга тизрәк барып җитү өчен, догасын укып, Ходайга ялварды. Ләкин ярлар күренми, өстәвенә, яңгыр ява башлагач, күзләрне томалаган төн карасы тагын да куера төште. Күл өстендә давыл күтәрелергә тора иде. Өлкән яшьтәге назир, борчылып, төпсез караңгылыкка бакты, әсирләрне ашыктырды. Тегеләр, дәррәү ухылдап, бөтен көчләре белән киерелеп, ишкәкләргә бастылар, тик тырышулары һичнинди нәтиҗә

[1] Мешале – факел (төрекчә – тәрҗ. иск.).

бирмәде. Ярлар күренми дә күренми, көймә исә бер төштә әйләнеп йөргән кебек кенә тоела. Мешалене авырлык белән кабыздылар, аны болгап кычкырырга тотындылар, тик беркем дә аларга җавап кайтармады, бары җил генә дулады, дулкыннар, сызгырып, көймә кырына ташланалар да сынган кебек артка авып төшәләр. Ханәкә калтырана башлады, киеме сыгып алырлык булып чыланды, салкын җил тәнне үтәли чыга иде. Ул, өметләнеп, як-ягына карангалады, ерак ярдан ут әсәре эзләде. Әмма күз алдында, ярсыган тай көтүе сыман үрә баскан дулкыннардан кала, берни дә күренмәде, коткарырга тиешле ут юк, хәлдән тайган кешеләрнең бу чоңгылдан чыгу өмете киселде. Шул арада әсирләрнең берсе ишкәген югалтты, икенчесе таныш түгел телдә кычкырып дога укырга кереште. Назир, камчысын ташлап, кайнап-өерелеп торган суга таба кулын сузды да, тынына кабып, карлыккан тавыш белән кычкырды:

– Аждаһа! Бу – Аждаһаның үч алуы. Бөек Елан бездән корбан таләп итә.

– Ахмак! – дип кычкырып җибәрде Гәүһәршад. – Сабыйларга уйлап чыгарылган әкияткә кем ышансын?! Әгәр әсирләрне ишкәкләренә ябышырга мәҗбүр итә алмасаң, иң элек үзең балыкларга азык булырсың!

Әмма куркудан шаша язган назир аны ишетмәде. Гаҗизләнгән ханәкә дилбегәне үз кулына алырга маташып карады, тик аны танып та өлгермәгән әсирләр шулхәтле ярсып күзләрен аларттылар ки, чая хатын үз гомерендә беренче мәртәбә чигенергә мәҗбүр булды. Дулкыннар иртәме-соңмы ярга чыгарып куяр яки таң беленә башлагач, караңгылык таралыр да бу бәладән котылу юлы табылыр әле, дип ышанганга, ул, телен тешләп, тынып калды. Гәүһәршад армый-талмый шул турыда гына уйлаганда, җил өермәсе белән килгән зур дулкынны күрми калды. Дулкынның көймәне йомычка кебек очыртып алып китүе булды, күз ачып йомганчы аның астын өскә әйләндереп тә ташлады. Ярсу дулкыннар кочагында тыпырчынган кешеләрне көзге суык су куырыпөтеп алды. Ирләр йөзтүбән яткан көймәнең юеш-тайгак кырларына әле беркавым ябышырга тырышып карадылар, ләкин дулкын аны, бәргәләнгән хәлсез куллардан тартып алып, әллә кая куалады.

Караңгы чоңгыл Гәүһәршадны үзенә суыра башлагач та, хатын бу хәлдә калуына ышанмады. Ул бит әлегәчә башын тәкәббер чөеп, куәтле-кодрәтле булып, теләсә нинди көчләргә каршы нык тора иде. Язмышы ханәкәне һәрвакыт саклады, үз канаты астына алып, көнчеләрдән саксыз кылануларының нәтиҗәсе булган чакларда да яклап килде. Бөек ханның кызы туган көненнән үк һичкемнең буе җитмәслек биеклеккә күтәрелде, ә менә хәзер, кисеп ташлаган тырнагына да тормаслык әсирләр белән бергә, шулкадәр мәгънәсез әҗәл тигәнәсенә кереп бара. Ул, язмышынамы, әллә Ходай Тәгаләнең үзенә үкме үпкәләп, соңгы тапкыр ярсып-ачуланып кычкырды, әмма карлыккан-кипкән авызы бозлы суны гына чөмереп алды, тавышы дулкыннар үкерүенә күмелеп калды. Көчләр тигез түгел. Шулай да хатын әле бирешми, тыпырчына һәм, чираттагы дулкынга ияреп, бата-калка өскә күтәрелеп алгалый иде. Гәүһәршад ханәкәнең башы су астына иң соңгысы булып күмелде. Көчле, нык бәдәнле әсирләр, бу хатындагы тимер ихтыярның яртысы да булмаган көе, аңардан алдарак баттылар. Ә хан кызы, суыкны да, куркуны да тоймыйча, төпкә китте, шулчак аны ниндидер рәхәт җылылык биләп алды, караңгылыкны кисеп, янына якты нур килеп керде. Аның өстенә кемнеңдер йөзе иелде. Бу – Турыиш, хатын аны елмаюыннан, үзе чын-чынлап яраткан ир-егетнең күзләреннән таныды. «Курыкма, – дип пышылдады Турыиш, – әйдә, минем белән киттек...»

Әйләнеп капланган көймә, ятим бишек кебек, төне буе дулкыннар өстендә тирбәнде, иртә таңда гына «арып-талып» ярга чыгып ятты. Балык тотучылар камыш арасында йөргән яугирләрне күрделәр, алар судагы гәүдәләрне эзлиләр иде, күрәсең; тик берни дә таба алмадылар. Ә шул тирәдә яшәүче халык, күпмедер заманнар узгач, җил-давыл вакытларында Кабанның суы икегә ярыла да, ярга, корбан малай таләп итеп, ханбикә

чыга, дип ышана, башкаларны да ышандыра башлады. Тиздән бу хикәятләр, телдән-телгә күчеп, тагын бер риваятькә әверелде...

Кабан сулары хан кызын йоткан сәгатьтә Булатширинның бернидән хәбәре юк иде. Ул Гәүһәршадның язмышыннан көнләшеп тә куйды әле. Әмир, зинданның тар тәрәзәчегеннән күренер-күренмәс кенә булып торган тишек ямаулык кебек кенә төнге күккә багып, үз язмышы турында уйланып утыра иде. Ул беренче түрә үтәргә тиешле юлны узды, бу озын юлда башкаларның төшенә дә кермәгән иң зур хөрмәткә, буй җитмәслек дәрәҗәгә ирешә һәм хисапсыз байлыкка ия булды. Әйе, олы карачы тормышта күпне күрде, күпне кичерде, барысы да аның алдында тез чүгәләр иде, хәтта ханнар да аңа каршы сүз әйтергә кыймадылар. Хәзер әнә җилнең сагышлы улавы артында аны әҗәл каравыллап тора. Таш түшәлгән урамны камчылаучы яңгыр шавында ул Газраилнең канат кагуын ишетә. Булатширин белә: үлем иртәгә таңнан ук киләчәк, бик азлар гына аның үткен тырнагыннан читкә тайпылып кала алыр. Бары ул – хәйләкәр ханәкә генә качып котылды. Булатширин мыек астыннан елмаеп куйды, ышкыланмаган көе генә җәелгән такта ятагына ишелеп төште. «Их, Гәүһәршад! Бу дөньяда кавышырга язмады шул безгә. Әгәр шуңа ирешсәк, бездән дә дәһшәтлерәк көч булмас иде! Менә хәзер дә син ИРЕКТӘ калып, Нугайга яисә Төмән далаларына очып кына барасыңдыр. Минем хакта – соңгы сәгате җиткәнче генә яшәп торган зиндан тоткыны турында исеңә төшерәсең микән?» Ширин әмир чапанын каплап йокыга талганын сизми дә калды, әмма тиздән суык аны куенына кереп уятты. Менә ул, исәпсез-хисапсыз мал иясе, калтырана-калтырана пычрак постауга төренергә мәҗбүр булды һәм хөҗрәсенең дымлы таш идәнендә кечкенә учак кабызып, шуңа берәм-берәм коры чыбык ташлап утырырга хыялланды.

***

Башкалада җәзалаулар берничә көн буе барды. Шәһәрнең төп мәйданында, хурлык тамгасы алып, мәгърур Булатширин, карачы Әхмәтаргын, Солтан бәк һәм ханлыкның башка иң атаклы затлары фани дөнья белән бәхилләште. Оран салучылар Казан иленең бөтен почмакларында, туган җиргә дошманнарны чакырып китергән хаиннарның исемнәрен атап, аларның гаебен әче тавыш белән раслап тордылар. Кешеләр ышанырга да, ышанмаска да белмәделәр, куркып калганнары, бәладән башаяк, дип, тизрәк өйләренә таралышты. Ишекләрен зур йозаклар белән бикләп, тын түрләрендә Аллаһка дога кылдылар, аңардан мәдәт һәм ярлыкау сорадылар. Казанның зур түрәләре арасында фетнәгә катнашы булмаганнары да табылды, әмма алар да куркудан, биләмәләрен һәм сарайларын ташлап, кайсысы Мәскәүгә, ә кайберләре Нугай белән Хаҗитарханга ычкынды. Ләкин шундый авыр вакытларда да бирешәсе-биреләсе килмәгәннәр пайтәхеттә калды. Ханга каршы берләшкәннәр канга батса, батты, хәтәр сукмактан үзләрен әйдәп баручыларны да югалтты, мәгәр, вакытлыча посып, җан саклый алдылар. Алар рәхимсез аучыдан урман-чытырманда, үтеп чыкмаслык сазлыкларда яшеренеп калган яралы җанварлар сыман иде. Яшерен өннәрендә беркадәр хәл җыйгач, баш күтәрүчеләрнең икенче сулышы ачылды шикелле. Элек Сафагәрәй ханга тугрылыклы булган күп кенә казанлылар да, каршы якка чыгып, тиз арада чираттагы фетнәне оештырырга керештеләр, анда катнашырга әзерләнделәр. Аларга хакимнең җәзаланган әмирләрнең биләмәләрен Кырым килмешәкләренә таратуы ошамады. Буш янчыкларын күтәреп килгән кырымлылар хәзер сарайларга кереп урнашты. Мул биләмәләрне җиңел генә үзләштереп, җәзалап үтерелгән бәкләрнең һәм угланнарның хәрәмханәләренә хуҗаларча атлап керделәр, аларның малына ия булдылар. Казан сараендагы түрәләр сукранды, ә хан уйланып җитмәгән гамәлләре белән кичәге юлдашларыннан үзенә дошманнар ясавын күрергә дә, аңларга да теләмәде.

Яңа фетнәнең башында Боерган сәед, Кадыш һәм Чуранарык әмирләр тора иде.

Җәй ахырына таба алар Мәскәүгә чапкын юлладылар. Ханга каршы як, бүтән әмәл күрмичә, кабат Мәскәү хакименнән Казан өстенә урыс явын җибәрүне үтенде. Ләкин Иван IV ханлыкның капка төбеннән күптән түгел генә, үзе әйтмешли, «не солоно хлебавши», ягъни хурлыклы нәтиҗә белән борылып кайтуын яхшы хәтерли, шуңа күрә бөек кенәз казанлылардан күңелләренә ярамаган ханны үзләре тәхеттән бәреп төшерүен һәм, Мәскәү гаскәре килгәнче, аны сак астында тотуларын таләп итте. Фетнә оештыручылар хәлиткеч хәрәкәткә күчү өчен көч тупларга керештеләр һәм бу юлы инде түнтәрелештә төп дилбегәне халык кулына тапшырырга карар кылдылар. Гади кешеләрне хакимгә каршы ачыктан-ачык баш күтәрергә өндәү башланды. Котырту өчен тиздән сылтавы да табылды: Кырым килмешәкләренең калтасын баетыр өчен, Сафагәрәйгә болай да зур салымнарны күтәрү кирәк булды.

Бу тынычсыз көннәрдә Сөембикә ханбикә әтисеннән кисәтүле-шелтәле хат алган иде. Бәкләр бәге Йосыф кызын акылсыз иренә йогынты ясарга чакырды, берзаман аны һәлакәткә алып баруы ихтимал булган гафу ителмәстәй хаталарына күзен ач, дип сорады. Сөембикә мәктүбне укып чыкты, башында исә күңелсез уйлар мыж килде. Аңа Сафагәрәйнең Казанда ничек хакимлек итүе күптән ошамый иде инде, хатын-кызның нечкә сиземләве әйтеп тора – бәлагә ерак калмаган! Гади халыкның аеруча яраткан шагыйре Мөхәммәдьяр да, якынлашып килгән давылны алдан күреп, пәйгамбәрләрчә юрап куйган бит:

Ышанып җитмәү дәүләтне җимермәстер,
Ә изүдән көчле ил дә таркалыр.
Ышанмавы үзенә генә зыян итсә,
Изү илне түзалмаслык хәлгә салыр.

Ашык-пошык кына язылган бу юлларны Мөхәммәдьяр Казан ханбикәсенә юллаган иде, Сөембикә аны кат-кат укыды, шулчакта күкрәгенә боз тулган кебек тоелды. «Ут белән уйный ул, – дип уйланды хатын. – Сафагәрәй шулхәтле уйламыйча эш йөртә башлады. Йа Хода, син аны акылга китерә алырсыңмы икән?!»

Ул ирен ничек туктатырга да белми. Сөембикә җәзага тартылган аксөякләрнең гаиләләрен якламакчы иде, әмма Сафагәрәй, кан исен сизгән бүре сыман, табышын ычкындырырга теләмәде. Алар беренче мәртәбә бик җитди рәвештә сүзгә килделәр, бу инде электәге кебек, вак-төяк аркасында җиңелчә суыну, бер-берсеннән читләшеп алу гына түгел иде, ир белән хатынның карашлары, ниһаять, мәңге килешмәслек булып, капма-каршы якка аерылды һәм хаким үз ханбикәсен чын-чынлап ачу белән әрләп ташлады:

– Хатын-кызга ир-ат эшенә кысылу килешми. Хатының сәясәткә керә башласа, үзенең хуҗасын назлауны һәм аның нәселен дәвам итәргә тиешле төп вазыйфаларын оныта!

Сөембикә мондый рәхимсез сүзләрдән тыны кысылганын тойды:

– Сез, дәүләт эшләре синнән бала табу сәләтен тартып алды, димәкче буласызмы?

– Болар барысы да сафсата, җанкисәгем, аларын син үзең яраткан каләм кортлары белән армый-талмый үрә-сүтә аласың. Тик белеп тор, гыйлем иясе кыяфәтенә кереп, дәүләт мәнфәгатьләрен кайгырткан булып акыл сатучы хатыннар минем саруымны кайната!

Сөембикә, үпкәләвен җиңеп, аңлашу өчен соңгы тапкыр талпынып карады:

– Хаким, Сез уйлап эш итмисез, тиздән барысы да, хәтта дин әһелләре дә Сездән йөз чөерәчәк! Сезнең исемегез белән балаларны куркыта башлаячаклар, ә кырымлыларны барчасы да күралмый. Соңга калганчы, туктагыз, Сафагәрәй!

Сафагәрәйнең йөзе кызыл-комач таплар белән капланды, хатынына кул күтәрүдән ул көчкә генә тыелып тора кебек иде. Хан үзен тыярга өлгерде, әмма ярсуны барыбер ничектер чыгарырга, басарга кирәк бит. Ул Сөембикәнең беләгеннән эләктереп алды да аны ачык тәрәзәгә таба этеп җибәрде:

– Әнә, кара! Күрәсеңме, анда сезнекеләрнең берсе дә өнәмәгән Кырым угланнарым тора! Ә алар көн-төн, ару-талуны белми, минем сараемны, үземне һәм сезне – хатыннарымны саклый! – Хан, тынычрак сөйләшүгә кучәргә омтылып, тирән итеп сулыш алды: – Ничек уйлыйсың, гүзәлем, алдыгызда кояш кебек балкыган карачы Булатширинның фетнәсе уңышка ирешә калса, синең белән ни булыр иде? Йә тол калырсың, ә, бәлки, мәсхәрә ителеп, өстеңдә урыслар рәхәт чигәр иде. Син шуны теләдеңме?!

Сөембикә учлары белән йөзен каплады, хатынны өметсезлек басымы изде. Ире белән төрле телләрдә сөйләшүләрен ул беренче тапкыр ачынып тойды, бу – һичкайчан ханбикәнең омтылышларын аңлый торган кеше түгел! Югыйсә, ул да бит, Сафагәрәй кебек үк, бәгырь түрендәге халкының язмышына басымчылык иткән мәскәүләрне күралмый, ләкин бу хәлдән чыгу юлын хаким дөрес сайлады, дип тә санамый.

«Ул бары тик кырымлы гына шул! – дип кайгырып-хафаланып уйланды ханбикә. – Аларның арасындагы бер мескен малай һәм бөтенесе дә шуның белән аңлатыла! Сафагәрәй һичкайчан үзенекеләрне ятка бирмәячәк, ул бөтен казанлыларны кырып бетерергә һәм ханлыкны төрек солтанына илтеп тапшырырга мөмкин. Ирем хаклымы-юкмы, моны бер Хода гына белә. Йа, Аллаһ! Иһдинас-сыйратәл-мүстәкыйм, сыйратәл-ләзинә, әнгәмтә галәйһим, гайрил-мәгъдуби галәйһим үәл-әд-дзаллин[2]. Без бәхетсезләргә акыл бир һәм туры юлга бастыр, Илаһым!»

Сөембикә кулларын түбән төшерде, аның агарып калган йөзендә бер бөртек яшь тамчысы да юк иде. Сафагәрәй, гаҗәпләнеп, аның торышын күзәтте: «Бу нинди хатын бу! Бүтән теләсә кайсысы хәзер үк яшенә буылыр яисә куркуыннан егылып үләр иде. Ә бу тораташ кебек каткан да тик чекерәеп тора, күзләрендә яшь әсәре күренми һәм җылылык та юк».

– Үзегезгә карагыз, хуҗам, Сез ни кылганыгызны үзегез беләсез булыр.

Ул ханбикәне тоткарлап калмакчы иде, әмма өлгермәде: Сөембикә ишектән шуып кына чыкты. Шул төнне хан аңа хәрәм агасын арадашчы итеп җибәргән булды, тик анысы да тиздән ялгызы гына әйләнеп кайтты. Ханым үзенең авыру икәнлеген һәм әле түшәккә ятарлык хәле булмавын әйтергә кушкан, имеш. Аңламады түгел Сафагәрәй, бик аңлады: Сөембикә гарьлектән, ачудан шулай кылана һәм, күрәсең, гаилә корабы өстеннән узган давыл басылганчы, аңа тими торырга кирәктер. Бу төндә һәм шуннан соңгыларында да хаким кәнизәкләре кочагында гына ләззәт кичерде. Ә Сөембикә, вакыт-вакыт, Сафагәрәйнең хакимияте таркалган кебек, үзләренең зур мәхәббәте югаласүнә барганын тоеп әрни иде.

***

Кышка аяк бастылар. Ул казанлылар белән хан арасындагы киеренке мөнәсәбәтне, тартышны тыныч хәл итү юлын күрсәтмәде. Тиздән урыс ягыннан салкын, хәвефле хәбәрләр җиле исә башлады: бөек кенәз Владимирга килгән, тиз-тиз генә гаскәр җыюга керешкән икән. Мәскәүдән яңа куркыныч янавын тоеп, хаким сагая калды һәм, бәкләргә, угланнарга пайтәхетне якларга эндәшүле боерык биреп, бөтен Казан җире буйлап чапкыннар җибәрде. Ләкин шәһәргә кырымлылар яклы берәм-сәрәм аз санлы хәрби берләшмәләр генә җыела башлады. Ханга каршы як шунда ук җанланып, канатланып китте һәм, һиҗри исәбе белән 952 нче сәнәнең зөлкагъдә[3] аенда, Сөембикә ханбикәне инде байтактан борчуга салган шешнең, ниһаять, тулып-өлгереп килүе аермачык булып күренә иде.

Дәвамы бар

Урысчадан ***Мөдәррис Вәлиев*** *тәрҗемәсе* ■

[2] Коръәннең «Әл-фатиха» сүрәсеннән ике аять (тәрж.иск.).

[3] 952 нче сәнәнең зөлкагъдә ае – 1546 елның гыйнвары.

ТАССР

БЕР МӘКТӘПНЕҢ КЫСКАЧА ТАРИХЫ: *татар-башкортлардан кызыл командирлар хәзерләү эше**

Кави Нәҗми, Якуб Мамкиев, Исмәгыйль Хәмзин

Үзенең алты еллык гомерендә бик күп көрәшләрне уздырган, төрле исемнәр белән аталып, хәзерге көндә Татарстан Үзәк Башкармасы исемендәге «Берләшкән татар-башкорт сугыш мәктәбе» дип йөртелгән бу уку йортының тарихы түбәндәгечә.

Татар-башкортлардан кызыл командирлар хәзерләү өчен аерым команда курслары оештырырга кирәк, дигән фикер 1918 елны ук туган иде. Чөнки, фронтлардагы татар-башкорт частьларында командирларның җитешмәве аркасында бик күп читенлекләр очрап, һич кичектермичә мондый курсларны ачарга кирәк булды. Бу курслар башта **Мөселман җәяүле гаскәрләренең Казандагы беренче команда курслары** исеме белән 1918 ел 21 декабрьдә төзелә башлаган иде. Ләкин, Колчакның Казанга якынлашуы аркасында, курслар **Беренче татар полкы**на кушылдылар, фронтка чыгып сугышка катнаштылар.

Берничә айлардан соң, Казанга Мөселман команда курсларын яңадан аякка бастыру турында боерык килә һәм 1919 елның 6 июненнән башлап **Икенче мөселман җәяүле команда курслары** исеме белән эшкә керешә. 1920 елның июленә кадәрле дүрт чыгарылышы булып, 100 чамасында кызыл командирларның күбесе фронтларга, калганнары Кафказга, **Төркестандагы татар бригадалары**на һәм **Украинадагы татар полклары**на җибәреләләр. Шулай итеп, татар гаскәрләре полкларында да

ТатЦИК председателе Шәймәрданов иптәш «Берләшкән татар-башкорт сугыш мәктәбе» лагеренда

*Текст **«Кызыл Армия сафында татар-башкортлар: тарихи, әдәби, рәсемле альбом»** җыентыгыннан алынды (Төз.: Кави Нәҗми. – Казан: Татарстан матбугат-нәшрият комбинаты басмасы. – Казан, 1925. – Б.211-215).

эшче-крәстиән арасыннан чыккан кызыл командирлар ана телендә сәяси белем бирә башлыйлар һәм сугыш һөнәрләренә өйрәтергә тотыналар. Шуның аркасында аң-белем тарату эше һәм дисциплина тиешенчә юлга салына.

1920 елның 12 июнендә Мөселман команда курслары яңадан фронтка озатыла. Калган кисәге, Петергофтагы бишенче җәяүле команда курсларына кушылып, «**Мөселман батальоны»** исемендә йөртелә башлый. Андагы курсантларның күбесе курсант бригадалары белән Көньяк һәм Көнбатыш фронтларына китеп, зур батырлыклар күрсәтәләр. Бик күбесе Кызыл Байрак орденнары алып, курсларның исемен оныттырмаслык итәләр.

1920 елның августында **16 нчы мөселман җәяүле команда курслары** ачылып, беренче, икенче курсларның эшләрен дәвам иттерергә тотына. 1921 елның 15 февралендә «Курслар 24 сәгать эчендә җыенып, хәзерләнеп, Түмәнгә китәргә тиешләр!» дигән ашыгыч телеграмма алына. 16 нчы курслар, Түмәндәге кулаклар фетнәсен басар өчен бер укчы полк, бер батальон һәм штаб төзеп, фронтка китәләр. Бу сугышларда курслар үз составының яртысын югалтып булса да, баш күтәргән кулак бандаларын туздырып, үз бурычын бөтенләйгә үтәп кайтты. Шуның билгесе буларак, Татарстан Үзәк Башкармасы исеменнән курсларга Сугыш Байрагы бүләк ителде. Бу сугышлардан соң курслар тагын да уку-өйрәнү эшләренә керешеп, Кызыл Армиягә байтак командирлар хәзерләп бирә.

1922 елның җәендә курслар, Бохара-Әфган чикләрен саклау өчен, Кушка крепостена *(хәзерге Төрекмәнстандагы Серхетабад шәһәре. – **Ред.**)* барып, уңышлы маневрлар ясадылар. Бу маневрларда курсантларның күбесе малярия белән авырый башлап, курсларның составыннан 25 проценты кимеде.

1923 елның гыйнварыннан башлап, 16 нчы җәяүле команда курслары **Көнчыгыш халыкларыннан атлы командирлар хәзерләүче 9 нчы курслар**га кушылдылар. Бу курсларның да тарихы искиткеч батырлыклар белән тулы. Алар Гражданнар сугышының иң авыр елларында 1918 елда төзелгән **21 нче Әстерхан атлы командирлар курсларының татар-башкорт эскадроны**нда оештырыла. Башта «**Беренче мөселман атлы командирлары курсы»** аталып, Көньяк фронтта сугышучы курсант бригадасына бер эскадрон һәм Себер кулакларына каршы көрәшләргә ярты эскадрон курсантын җибәрә.

9 нчы кавалерия курслары 1922 елны җәен Бохара фронтында була. Анда батырларча сугыша һәм бер яктан сугыш, икенче яктан көчле малярия уртасына очрап, 70 процентка кимеп кайта.

1923 елның башында атлы һәм җәяүле команда курслары берләштерелә. Икенче зур бер гаскәри көч булып, «**Берләшкән мөселман җәяүле команда курслары»** исеме белән яңа чорга аяк атлыйлар.

1923 елның азагына таба ул курс, дәрәҗәсеннән югары күтәрелеп, өч ел мөддәтле *(еллык. – **Ред.**)* сугыш мәктәбе төсенә керә һәм «**Берләшкән татар-башкорт сугыш мәктәбе»** дип атала башлый. 1924 елда, Советлар Союзы Реввоенсоветы приказы белән, мәктәп Татарстан Советларының Үзәк Башкармасы исеменә багышлана.

***

Мәктәпнең куелышына, төзелешенә, уку-укыту эшләренә тукталганда түбәндәге фикерләрне әйтергә кирәк була. Уку-укыту – 3 ел. Керүчеләр татарча һәм урысча укый-яза, сөйләшә белергә, шулай ук хисаптан дүрт гамәл чыгара алырга тиешләр.

Завод-фабрикадан һәм сукадан яңа гына аерылып килгән татар-башкорт яшьләренең урыс телен белүләре бик чикле булганлыктан, хәзер мәктәп янын-



Татарстан Үзәк Башкармасы исемендәге «Берләшкән татар-башкорт команда курслары»

да берьеллык хәзерлек бүлеге ачылырга уйлана. Ул вакытта урыс телен бик начар белүчеләр өчен мәктәптә уку вакыты 4 ел булачак.

Мәктәпнең «берләшкән» дигән исеменнән аның ике төрле командирлар хәзерләвен аңларга кирәк. Берсе – җәяүле гаскәр, икенчесе – атлы гаскәр өчен.

Бу мәктәптә укучылар иң яңа методлар буенча тактика, топография, ату эшләре, фортификация, инженерлык кебек сугыш фәннәрен, марксизм-ленинизм, җәмгыятьне өйрәнү, тарих кебек социальный фәннәр, табигать, җәбер *(алгебра. – **Ред.**)*, һәндәсә *(геометрия. – **Ред.**)* кебек фәннәр белән танышып, җәяүле яки атлы гаскәр өчен командир булып чыгалар. Уку-өйрәнү эшләренең күбесен практикада, лагерьларда, маневрларда үтәләр.

Укудан буш чакта курсантларга ял итү, үз көчләрен күрсәтү, сәяси тәрбия алу өчен мәктәп янында зур клуб бар. Кыскасы, бу мәктәп тән тәрбиясенең, төрле белемнәр алуның, сугыш һөнәрләренә өйрәтүнең, сәяси тәрбия бирүнең куелышы белән сугыш мәктәпләренең алдагысына керә һәм Татарстан Җөмһүрияте өчен мактанырлык бер урын булып эш күрсәтә. Безгә бу мәктәпнең туктаусыз яшәвен, үсүен һәм революция юлында көрәшергә хәзер булган батыр йөрәкле эшче-крәстиән яшьләренең бу мәктәпкә омтылуларын гына көтәргә туры килә.

1924-1925 уку елында да мәктәп үз эченә яңадан 200гә якын яшь курсант алды, яңа килгән көч үзенең революционный аңы һәм белеме белән күзгә бәрелә. Аларның 60 проценты – коммунистлар.

1925 елның сентябрендә «Берләшкән татар-башкорт сугыш мәктәбе» йөзгә якын кызыл командир хәзерләп, Кызыл Армиядәге милли бүлекләргә бирә. Бу төркем 3 еллык нормальный мәктәп шартлары эчендә белем алганлыктан, үзенең хәзерлеге белән аеруча урында тора. Болар арасында берникадәрле таранчы *(уйгырлар. – **Ред.**)*, дүнгән *(кытай мөселманнары. – **Ред.**)*, кыргыз иптәшләр дә бар. 70 процент кадәрлесе – партиецлар. Бу чыгарма Татарстан Җөмһүриятендәге һәм башка җирләрдәге эшче-крәстиәннәр өчен иң яхшы куаныч билгесе булыр. Алар тагын да бер мәртәбә чын күңелләреннән: «Яшәсен көчле Кызыл Армиянең батыр командирларын хәзерләүче Татар-башкорт сугыш мәктәбе!» – дип, авылларын, заводларын яңгыратырлар.

*Текстны басмага **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Таҗетдин хәзрәт чишмәсеннән...

Рухия Ахунҗанова

Җиде-сигез яшьлек чагымда һәрдаим, әбиемә ияреп, авыл зиратына йөри идем. Әбием юл буе дога укып бара, килеп җиткәч, койма буенда туктала һәм күккә ашкан куш нарат янындагы каберләргә текәлә дә: «Монда изге зат – Ялчыгол углы Таҗетдин хәзрәт җирләнгән», – дип әйтә иде...

Мин, әлбәттә, мәгърифәтче, галим, педагог, шагыйрь, язучы, табиб Таҗетдин хәзрәтнең кем булуын әдәбият белән кызыксына башлагач кына белдем. Ул Дагыстанда белем алган, чит илләрдә сәяхәт иткән. 17 яшеннән башлап, бөтен гомерен балалар укыту һәм халыкны агарту эшенә багышлаган. Үзе җиде бала атасы булган. Кече Сөн, Җирекле, Кызыл Чапчак, Мәлем авылларында яшәгән, белем бирү белән беррәттән, иҗат белән дә шөгыльләнгән. Шәрык шагыйрьләренең әсәрләренә шәрехләр (аңлатмалар) язып, шөһрәт казанган. Шул шәрехләре арасында иң билгелесе – Суфи Аллаһиярның «Сөбател-гаҗизин» («Гаҗизләрнең ныклыгы») әсәренә язган аңлатмасы. Ул аны кызы Газизә укып файдалансын өчен язган. Китапның исеме дә тора-бара «Рисаләи Газизә» дип кенә йөртелә башлаган, соңыннан мәдрәсәләрдә башлангыч сыйныфлар өчен дәреслек итеп файдаланылган. Таҗетдин хәзрәт гомере буе китаплар күчереп язган, ягъни хәттат булган. Шулай ук гарәпчә һәм фарсыча башка әсәрләргә дә аңлатмалар биргән. Инде килеп, мәшһүр «Кыйссаи Йосыф»ны халыкка таратуда да күп көч куйган.

Бу мәшһүр шәхеснең туган елын төрлечә фаразлыйлар. «Борынгы татар әдәбияты» (Казан, ТКН, 1963, 76 бит) китабында Ялчыголның яшәү еллары 1763-1837 итеп күрсәтелгән.

1984 елда Татарстан китап нәшрияты «Татар әдәбияты тарихы»ның I томын бастырып чыгарды. «XVIII йөз татар әдәбияты» бүлегендә галим, текстолог Мәсгут Гайнетдин Ялчыголның яшәү вакытын нигәдер 1768-1838 елларга үзгәрткән иде.

Дамир Гарифуллин да «Казан утлары» журналындагы (1989, №2, 181 б.) мәкаләсендә хәзрәтнең туу вакытын 1768 ел дип билгеләгән. Аңа җавап йөзеннән ризасызлыгымны белдереп язган мәкаләм «Татарстан яшьләре» (29 апрель, 1989) газетасында басылды. (Соңрак ачыкланганча, бу язмам Дамир абыйны күп еллар бимазалап торган).

Д.Гарифуллин Таҗетдин хәзрәтнең шәҗәрәсен төзеп, аның нәселенә караган шәхесләр турында мәгълүмат туплап, аларның фотосурәтләрен эзләп табып, энциклопедик характердагы «Чырагы нур сибә бүген дә...» (Казан, «Сүз» нәшрияты, 2009) китабын нәшер итте. Ләкин автор Таҗетдин хәзрәтнең гомерен элеккечә 1768-1838 еллар белән чикләгән иде.

Минем: «Таҗетдин хәзрәтнең туу вакытын нигә һаман шулай яздыгыз?» – дигән

соравыма Дамир абый сорау белән җавап бирде: «Аның 1763 елда тууын нәрсәгә таянып әйтәсең?» – диде. Мин «Борынгы татар әдәбияты»на ишарәләдем...

Шуннан соң күп сулар акты. 2012 елның октябрендә Дамир абый мактанулы да, җиңүле дә тавыш белән телефон аша: «Рухия, Таҗетдинеңнең кайчан һәм кайда тууын белдем бит! Архив документын таптым. Синең фаразың дөрескә чыкты», – дип хәбәр итте.

Сөенечемнең иге-чиге булмады. Дамир абыйдан бу хакта тизрәк «Сарман» һәм «Мәдәни җомга» газеталарында язып чыгуын үтендем.

Шуннан соң башта район газетасында, бераз соңрак «Мәдәни җомга»да (30 ноябрь, 2012) Дамир Гарифуллинның «Таҗетдин Ялчыгол кайчан һәм кайда туган?» исемле күләмле мәкаләсе басылып чыкты.

«Ниһаять, – дип язган иде Дамир абый әлеге язмасында, – калын-калын зәңгәр кәгазь битләрендә үземне күп еллар бимазалап торган сорауга җавап таптым.

1820 елның 13 августында дворяннар утырышчысы Казанцев, Минзәлә өязенең Минзәлә земство суды тәкъдиме буенча, Таҗетдиннән сорау алу үткәрә һәм татарча сөйләгәннәрне урысчага әйләндереп язып бара: «Тазетдином меня зовут, Якшигулов сын, от роду мне 57 лет, уроженный Бугульминского уезда из деревни Чалпов...»

Сорау алу вакытында әдип үзен 57 яшьтә дип күрсәтә, димәк, ул 1763 елда туган була».

Шулай итеп, Таҗетдин Ялчыголның 1963 елның 4 октябрендә туып, 1838 елның 26 июнендә бакыйлыкка күчүе расланды.

...Тагын бер нәрсәгә аерым тукталып үтәсе килә: безнең якларда укуга хирыслык электән үк килгән. Һәр йортта Коръән һәм башка дини китаплар сакланган. Имәнлебаш мәчетле, мәдрәсәле авыл булган. Биредә Сәгъдетдин исемле атаклы хәттат яшәгән. Дин галиме, табиб Таҗетдин Ялчыгол аның янына Мәлем авылыннан кунакка килә торган булган, авыру кешеләргә һәрдаим ярдәм дә иткән.

Шундый сәфәренең берсендә ул Габдессәлам исемле дустында тукталган һәм кунарга калган. Дамир Гарифуллин «Чырагы нур сибә бүген дә...» хезмәтендә язганча: «Иртән намазга барып кайтканнан соң, алар чәй эчәргә утыралар. Шунда бер касә чәй эчеп, әллә нигә кәеф үзгәреп тора әле, дип, ястыкка таянып тора һәм озак та тормый үлеп тә китә»...

Мәлем авылының күршесендәге Иганәбаш авылында 1975 елның җәендә табылган кулъязма җыентыкның (ул Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивында саклана) 24 нче битендә: «1838 елда Сәратан йолдызының 24 нче көнендә... Мәзкүр Мәлем карьясендә тереклек идәче мелла Таҗетдин (бине) мелла Яхшыколый хәзрәтләре Зәй буенда маризларә (авыруларга) дәва идеп йөрдеке вакытында Зәй суы карбендә (якынында) Имәнлебаш карьясендә вафат улып, анда дәфен улынмышдыр...» – дип язылган.

Таҗетдин Ялчыгол хакында әбиемнән гел сораша идем. Халык арасында галим турында төрле фикерләр йөргән. Күп белүенә гаҗәпләнеп, им-томчыдыр бу, тиктомалдан кеше мондый булмый, дигәннәр. Аның гыйлемлелеген олылап, «изге хәзрәт», «әүлия» дип атаганнар...

Үлеменә карата да ике фараз яши. Таҗетдин, чыннан да, Мәлемнән Имәнлебашка авыруларны дәваларга килгән җирендә, җәйге эссе көнне вафат булган. Берәүләр аны мунчада ис тидергән, дисә, икенчеләре урамда барганда кинәт егылып үлгән, дип әйткән. (Хәлилрахман бабай, аның үлгән урыны, дип, Маһитап тыкрыгын әйтә иде). Авыл халкы хәзрәтне бөтен шартын китереп, хөрмәтләп җирләгән. Кабер ташына мәрхүмнең

«Таҗетдин Ялчыгол». Рушан Шәмсетдинов рәсеме

исеме, үлгән вакыты язып куелган. Тарихчы Дамир Гарифуллин андагы гарәпчә язуларны укыган:

«Дарел фанәдән дарел бакая
Рихләт кылды дамелла
Таҗетдин Ялчыгол углы
1838 сәнәдә».

Ягъни: «Фани йорттан мәңгелек йортка күчте», – диелгән.

Ялчыгол углы Таҗетдин хәзрәт күмелгән зират Имәнлебаш халкы өчен изге урынга әйләнгән. Казан, Алабуга, Чаллы югары уку йортлары студентлары һәм галимнәре дә, ел саен бирегә килеп, әлеге каберлекне зиярәт кылалар.

...Күршебез Сөләйман бабай да, безне – бала-чагаларны үз янына җыеп, чал тарихны дастан итеп сөйли иде. Сөйләгән саен, хәтеребездә калсын, диептер, Ялчыголның безнең авылда мәңгелек йокыга талуын да искәртә иде. «Салкын чишмә изгелекне, мөгаен, шуңардан алган», – дип тә өстәп куя иде ул. Чыннан да, Сөләйман бабай телгә алган Салкын чишмә хәзер дә үзенең сихәтлелеге белән бөтен тирә-юньгә танылган.

Имәнлебашны татар галәменә таныткан ошбу олуг затны авылдашлар онытмыйлар. Укучым, эшмәкәр Ленар Шаһиев ярдәме белән авыл зиратында әдипнең кабер ташы яңартылды, яңа чардуган куелды. Гарәп хәрефләре белән язылган иске ташның тарихи әһәмияте зур булса, гарәп һәм кирилл хәрефләре белән язылган яңа таш яшь буын өчен мәгълүмат чыганагы булып тора.

Имәнлебаштан Зәй-Кама Аланы юлы буенда 2007 елның маенда Таҗетдин Ялчыгол истәлегенә манара корылды. Зәй шәһәрендәге урамга һәм мәчеткә аның исеме бирелде, аңа стелла куелды. Күренекле рәссам Рушан Шәмсетдинов, прототибы итеп әдипнең нәселеннән Госман Таҗетдиновны сайлап, Ялчыголның рәсемен ясады.

Якташ галимебез, филология фәннәре докторы, академик Хатыйп Йосыф улы Миңнегулов «Рисаләи Газизә» китабын 2001 елда ике том итеп «Иман» нәшриятында бастырып чыгарды. Матбугатта дөнья күргән күп санлы мәкаләләрендә дә Ялчыголга шактый зур урын бирә ул.

Дамир Гарифуллин Таҗетдин хәзрәтнең шәҗәрәсен төзеде. Аның шулай ук, алда телгә алынганча, галимгә багышланган «Чырагы нур сибә бүген дә...» китабы дөнья күрде. Дамир абый әлегәчә Таҗетдин Ялчыгол турында яңадан-яңа мәгълүматлар эзләп таба («Казан утлары», 2018, №7, 166 б.).

Талантлы язучы, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллинның «Васыять» исемле тарихи романы (Татарстан китап нәшрияты, 2017) Таҗетдин Ялчыголның бай һәм гыйбрәтле тормышын колачлап иҗат ителгән.

Имәнлебаш авылында һәр елның август аенда «Таҗетдин Ялчыгол укулары» үткәрелә. Чарада күренекле дин әһелләре, галимнәр, язучылар катнаша.

Күрше Югары Шепкә авылында Ялчыголның бишенче буын вәкиле – өлкән яшьтәге Җүәйрә апа, аның гыйлем чишмәсен дәвам итеп, гомере буе авылга иман нуры таратты, догалар белән рухыбызны ныгытты. Хәзер аның игелекле эшен кызы Фирдәвес башкара.

Атаклы галим әле дә хәтерләребездә саклана. Шөкер, аңардан дәвалау үзлеген алган Салкын чишмәбез дә саекмый. Барыбыз да галимлек, язучылык, табиблык сәләтләренә ия булган Таҗетдин хәзрәт чишмәсеннән илһам алабыз.

Редакциядән:

Хөрмәтле каләмдәшебез һәм авторыбыз Рухия Фәхразый кызы Ахунҗанованың 20 июньдә гомер бәйрәме. Аны юбилее белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек һәм иҗат уңышлары телибез! ■

Хан сарае. Нияз Халитов реконструкциясе

Казан ханлыгында ислам дине:
өйрәнү проблемалары һәм перспективалар

Әнвәр Әкъсәнов

Казан ханлыгында ислам дине торышына бәйле кайбер сорауларга тарихчылар тарафыннан җавап табылган инде. Ш.Мәрҗани, М.Г.Худяков, Д.М.Исхаков һәм башка галимнәр раслаганча, борынгы илебездә Ислам шактый киң җәелгән һәм мөселман руханилары аның иҗтимагый-сәяси тормышында мөһим урын тоткан [5; 6; 7; 8; 11; 13]. Археология материаллары һәм кабер ташлары да Казан ханлыгының төп өлешендә (Казан арты, Идел буе, Түбән Чулман, Көнбатыш һәм Үзәк Чулман арты) мөселманнар яшәвен күрсәтә, биредә мәҗүси каберлекләр табылмаган [5, б.81]. Мәгълүм хәдистә искәртелгәнчә, дин төп өч өлештән тора: иман (ышану), ислам (дини-хокукый нормалар) һәм ихсан (ихлас табыну). Язма чыганаклар күрсәткәнчә, Казан ханлыгында исламның сөнни юнәлеше таралган.

Елъязмалар һәм илчелек кәгазьләре ханлыкның иҗтимагый-сәяси тормышында сәетләрнең – Мөхәммәт (сгвс) пәйгамбәр торыннарының мөһим роль уйнавын күрсәтә. Ил башы сәеткә (рухи башлыкка) карата һәрдаим үзенең ихтирамын һәм игътибарын белдергән. Австралия дипломаты С.Герберштейн бу турыда болай дип яза: «*Ул (сәет. –* ***Ә.Ә.****) аларда шундый куәткә һәм ихтирамга лаек ки, күренүенә үк патшалар аңа якынаерга омтылалар, баскан килеш кул сузалар, баш иеп, кулына орыналар, ә ул атта утыра бирә; мондый эш патшаларга гына рөхсәт ителә; герцоглар исә аның кулына түгел, тезенә генә кагыла; аксөякләр – табанына; кара халык – фәкать кием чабуына яисә атына гына*» [3, б.177].

Хан юк чакта хөкүмәтне сәет җитәкләгән, шулай ук ул тәхет варисларын билгеләгәндә, дәүләт идарәсе мәсьәләләрен караганда да үз сүзен әйткән.

Д.М.Исхаков һәм И.Л.Измайлов күзәтүләре буенча, чыганаклар дин әһелләренең дипломатия эшләрендә яхшы ук катнашуын раслый, хәтта «халыкара мөнәсәбәтләр ведомствосы аппаратын нәкъ менә сәет җитәкләмәгәнме икән», дигән фикергә урын калдыра [5, б.84]. Сәетләрнең дипломатик функцияләре, күрәсең, Үзбәк хан чорында Жучи Олысын исламлаштыруда төп көчләрдән булган нәкыйп Сәет-Атаның хәрби функцияләреннән башлангыч алгандыр. Кол Мөхәммәт сәет (ул 1550 ел кышында Казан капкаларының берсен саклауны да җитәкләгән әле) «Зафернамә-и вилайәт-и Казан» хезмәтендә «Пәйгамбәр әфәнде нәселеннән Сәет-Ата оныгы» дип телгә алына [4]. Соңрак чорга караган Урта Азия чыганакларын өйрәнгәннән соң, тарихчылар шуңа инана: мәртәбәле нәкыйп (дин башлыгы һәм хәрби оештыручы) вазыйфасын башкару, Үзбәк хан әмере белән, Сәет-Ата торыннарына тапшырылган [7, б.451]. «Зафернамә...»дәге мәгълүмат та шуны ук раслый, анда Кол Мөхәммәт сәетне «мәрхүм Сәетнең» углы иде, дип язалар [4]. Д.М.Исхаковның ышандырырлык дәлилләр белән нygытылган фикеренчә, Кол Мөхәммәтнең этисе – Казан тәхете өчен көрәштә Сафа-Гәрәйне яклаган Әстерхан сәете Мансур булган [6, б.88-89]. Казан, Касыйм, Әстерхан, Кырым, Кубань, Дагыстан сәетләренең туганлык җепләрен күрсәтүче гениалогик мәгълүматлар да байтак [2, б.226; 1, б.22]. Димәк, Сәет-Ата торыннары Алтын Урда таркалганнан соң да рухи башлык булып торуларын дәвам иткәннәр.

Урыс елъязмаларында Казан ханлыгының дин башлыклары составы тәфсилләп телгә алына. Болар: сәетләр, шәехләр, шәехзадәләр, муллалар, муллазадәләр, казыйлар, хафизлар, дәрвишләр һ.б. Шунысы игътибарга лаек: әлеге категорияләр турында без иң мөһим сәяси мәсьәләләр каралган «ил җыеннары» турында бәян кылынган елъязмалардан да укып беләбез. Бу гаять әһәмиятле дәүләт органы әгъзалары исемлеген шулай ук сәетләр яисә сәетләр белән муллалар башлап җибәрә, алардан соң гына ил башында торган династия вәкилләренә – угланнарга игътибар бирелә, соңыннан – бәйләргә, морзаларга. Аннары янә руханилар саналып китә: шәехләр, шәехзадәләр, муллазадәләр, имамнар, хаҗилар, хафизлар, данишмәндләр. Кайбер вакытта (1551 елгы корылтай очрагын искә алыйк) аристократия, руханилардан соң язылган [10, б.167]. «Ил җыены» исемлегендә сәет, һәрчак диярлек, беренче булып күрсәтелә. Бу, мөгаен, аның Дәүләт Шурасын – Диванны җитәкләвенә бәйледер. Чагыштырмача соңгы арада гына фәнни әйләнешкә кергән «Кара тәварих» (XVI гасыр уртасы) төрки-татар чыганагы Алтын Урданың ахыргы елларында диванны сәетләр җитәкләвен раслый [12, б.72-73]. Дин әһелләренең шундый мәртәбәле урыннар биләве тагын бер кат Казан ханлыгы җәмгыятенең гаять дини булуы турында сөйли.

Бая телгә алынган категорияләргә М.Г.Худяков мондый билгеләмә биреп үтә: *«Шәехләр – мөселман миссионерлары һәм, гомумән, изге картлар; муллалар һәм имамнар – мәчетләрдә гыйбадәт кыла торган затлар; дәрвишләр – мөселман монахлары; хаҗилар (урысча яңгырашта: ази) – Мәккәне зыярәт кылган затлар; хафизлар – Коръән уку осталары; данишмәндләр – укытучылар, мөдәррисләр; шәехзадә һәм муллазадәләр – шәехләрнең һәм муллаларның укучылары, угыллары»* [13, б.198].

Галим тәкъдим иткән трактовкалар белән килешергә мөмкин, ләкин, алай да, кайбер урыннарны тәгаенләбрәк китсәң, яхшырак булыр. М.Г.Худяков, күрәсең, бу категорияләрне гомум шәркый күзаллауларга нигезләнеп билгеләгән. Әмма соңгы дистә елларда яңа синхрон мөселман чыганаклары фәнни әйләнешкә кереп китте, алар телгә алынган дефиницияләрнең мәгънәсен төгәлрәк ачарга ярдәм итә.

Мөселман җәмгыятендә шәех дип рухи остазларны да (мөршидләр), аерым бер гыйлем дәрәҗәсенә ирешкән дин белгечләрен дә (шәйхел-ислам) атый алганнар.

Ләкин без күзәткән чор төрки-татар чыганакларында шәех дип, нигездә, нәкъ менә мөршидләр аталган. Мәсәлән, «Кара тәварих»та аталганнары: «Шәех әл-Әкътәби Наиб әз-заман Сәгъдетдин әфәнде», «Шәех Нәҗем әд-дин Кубра» һәм «Шәех Сәйф әд-дин Бахирзи» [12, б.14, 19, 34].

М.Г.Худяков дәрвишләрне мөселман монахлары дип хакыйкатькә беркадәр хилафлык китерә, чөнки, нәсаралыктан аермалы буларак, исламда гаилә кору тыелмый; киресенчә, хуплана гына; ә дәрвишләр омтылган аскет тормышы (зөһед) дөньялыктан бөтенләй ваз кичүне белдерми.

Ислам тарихыннан күренгәнчә, дәрвишләр, гаилә кору белән бергә, еш кына хәлле, бай да булганнар әле. Зөһед исә, беренче чиратта, милектән рухи ераклашу, юмартлык һәм тулаем Илаһка буйсыну булып аңлашылган.

Хәтта шушы берничә фрагментар мәгълүмат та исламның Казан ханлыгында (халыкның көндәлек мәшәкатьләреннән башлап дәүләт эшләренә кадәр) зур урын тотуын күрсәтә. Ләкин чыганакларның азлыгы ханлыктагы дини тормышны тулаем, һәрьяклап колачларга мөмкинлек бирми. Әлеге мәсьәләне өйрәнү перспективалары, яңа язма, археологик һәм эпиграфик чыганаклар табудан тыш, булганнарын комплекслы тикшерүгә дә бәйле.

Әйтик, Казан ханлыгының **Өмми Камал** (XIV гасыр ахыры – 1475 ел), **Мөхәммәдьяр** (1497-1549 еллар), **Кол Шәриф** (XVI гасыр башы – 1552 ел) һәм **Аднаш Хафиз** кебек фикер ияләренең мирасы хәзерге заман күзлегеннән төгәл текстологик һәм семантик анализга мохтаҗ. Мәгълүм булганча, үз хезмәтләрендә алар ислам таләпләренә буйсынып, яхшылыкка, итагатькә һәм даими рухи камиллеккә омтылырга өндәгән [9, б.515-523]. Ләкин бу авторларның интеллектуаль багажы тиешенчә өйрәнелмәгән, аларны баягы фикерләргә этәргән чыганаклар да ачыкланмаган. Шуларны яңадан бер карап чыгу – ул чордагы дин гыйлеме дәрәҗәсен аныграк күрергә, Казан белән Шәрык арасындагы интеллектуаль-дини бәйләнешләрнең ныклыгы турында өстәмә шәрехләр алырга һәм әлеге әсәрләрне төптәнрәк, яхшырак аңларга да ярдәм итәр иде.

Файдаланылган әдәбият:

1. Ахметзянов М.И., Шарифуллина Ф.Л. Касимовские татары (по генеалогическим и этнографическим материалам). – Казань: Магариф, 2010. – 375 б.
2. Әхмәтҗанов М.И. Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2002.
3. Герберштейн С. Записки о Московии. – М., МГУ, 1988. – 430 с.
4. Зафер наме-и вилает-и Казань // Эхо веков. – № 1. – 1995.
5. Исхаков Д.М. Измайлов И.Л. Введение в историю Казанского ханства. – Казань: Институт истории им.Ш.Марджани АН РТ, 2005, – 116 с.
6. Исхаков Д.М. Институт сейидов в Улусе Джучи и позднезолотоордынских тюрко-татарских государствах. Казань: Изд-во «Фэн» АН РТ, 2011. – 228 с.
7. Исхаков Д.М., Габбасов К.А. Институт сейидов в позднезолотоордынских тюрко-татарских юртах как историческое наследие Золотой Орды // XIII Фаизхановские чтения. Наследие Золотой Орды в государственности и культурных традициях народов Евразии: материалы международной научно-практической конференции. Санкт-Петербург, 4-6 мая 2016 г. СПБ.: ИД «Медина», 2017. – С.446-456.
8. Марджани Ш. Извлечение вестей о состоянии Казани и Булгара (Мустафад ал-ахбар фи ахвали Казань ва Булгар). Ч. I. Казань: Иман, 2005. – 200 с.
9. Миннегулов Х. Литература Улуса Джучи и постзолотоордынских татарских ханств // Золотая Орда в мировой истории. Коллективная монография. Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2016. – С.515-523.
10. Полное собрание русских летописей. Т.13. Ч.1. Патриаршая или Никоновская летопись. СПб.: Типография И.Н. Скороходова, 1904. – 302 с.
11. Тоган З.В. Исламско-тюркская культура в Казанском ханстве (Отчет, направленный из Казани в 1550 году во времена Кануни) // Средневековые тюрко-татарские государства. Сб. статей. Вып. 5. Вопросы источниковедения и историографии средневековых тюрко-татарских государств. – Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2013. – С.119-138.
12. Утемиш-хаджи. Кара таварих. Казань: Институт истории им.Ш.Марджани АН РТ, 2017. – 312 с.
13. Худяков М.Г. Очерки по истории Казанского ханства. – М.: ИНСАН, 1991. – 320 с., карт. ■

Безнең мирас №6 июнь 2019

Чат татарлары

Фәүзия Бәйрәмова

Чат татарлары Навил Шаһабетдинов (уңда) һәм Гариф Галиев (сулда) милли тугра янында

*Сезнең **чат татарлары** турында ишеткәнегез бармы? Ә менә мин ишетеп кенә калмадым, аларны ерак Себергә барып күрдем дә... Сезнең **1200 еллык**, халкының кулында шушы бөек тарихны исбат итә алырлык фәнни һәм рәсми документлары булган татар авылын күргәнегез бармы? Ә менә мин ерак Себергә – Новосибирск өлкәсенә барып, чат татарларының борынгы авылларын күрдем, тарихларын өйрәндем, шунда яшәп ятучы милләттәшләрем белән очраштым. Хәзер шушы вакыйга турында бар татар дөньясына хәбәр бирәсем килә...*

Йорт-Оры – Умар-авыл

Новосибирск өлкәсендә егерме биш меңгә якын татар яши, алар, берничә шәһәрдән тыш, тагы егермеләп татар авылында көн күрә. Шул авылларның иң борынгыларында – Йорт-Орыда (Умар-авыл) һәм Йорт-Акбалыкта чат татарлары яши. Чат татарлары – себер татарларының бер өлеше, алар шулай ук Томск һәм Кемерово өлкәләрендә дә гомер итә, күпчелеге хәзерге Новосибирск өлкәсендә көн күрә. Чат татарлары, димәк, зур сулар чатында, елгалар койган урында, чикләр киселешендә яшәүчеләр. Йорт-Оры авылы Обь елгасы буена урнашкан, ә Обьны чат татарлары Умар, диләр, шуңа күрә авылның да икенче исеме шулай дип атала.

Йорт-Оры – Умар-авыл, өлкәдә генә түгел, бөтен Себерендә иң борынгы татар авылы. Новосибирск өлкә хакимиятенең 1994 елда чыгарган карарыннан күренгәнчә, анда инде VIII гасырдан бирле чат татарлары яшәгән. Археологик тикшерүләрдән күренгәнчә, биредә борынгы шәһәрлекләр һәм курганнар табылган, шулар нигезендә, Йорт-Оры авылы өлкә дәрәҗәсендә тарихи-мәдәни ядкяр, дип игълан ителгән һәм дәүләт тарафыннан саклана. Йорт-Оры авылы табигатьнең искиткеч матур урынына – Обь елгасы буена, карагай-әрбет урманы эчендә урнашкан, авылны тирән күлләр әйләндереп алган. Биредә халык урман төпләп иген иккән, балык тоткан, мал асраган, аучылык белән шөгыльләнгән, җиләк җыйган, как койган, балалар үстергән, сугыш чыкса, атына атланып, яуга барган, иле-җире өчен көрәшкән.

Заманында чат татарлары – Төрки каһанлыклар, Алтын Урда, Себер ханлыгы составында булган, урыслар Себерне яулап алгач, XVII гасыр башларыннан Россия дәүләтенә буйсындырылганнар. Шунысын да әйтергә кирәк, Себер ханлыгы өчен соңгы сугышлар нәкъ менә чат татарлары җирләрендә була: 1598 елның 20 августында урыс гаскәрләре Ирмән елгасының Обька койган тамагында Күчем ханның җәйге ыстанын тар-мар итә, шушы дата рәсми рәвештә Себернең Россиягә кушылуы, дип билгеләнгән һәм энциклопедияләрдә шулай язылган. Узган елның көзендә без беренче тапкыр Новосибирск өлкәсендә Хәтер көне уздырдык, тарихи урыннарда булдык, дин-милләт өчен шәһит киткән әби-бабаларыбыз рухына дога кылдык, «Түгәрәк өстәл» җыенында чыгышлар ясадык.

Инде без хәзер шул чат татарларының варислары янына, аларның тарихи ядкярләре сакланып калган урыннарга – Себер авылларына юл тотыйк. Йорт-Оры Новосибирскидан 50-60 чакрым төньяк-көнчыгышта, Томск ягына таба юл өстендә булып чыкты. Новосибирск өлкәсе хакимияте 1994 елның ноябрендә Йорт-Оры авылын дәүләт саклавына кую турында махсус карар кабул иткән.

Әлбәттә, мондый документлар кабул ителгәнче, галимнәр Йорт-Оры авылы тирәсендәге тарихи ядкярләрне, борынгы шәһәрлекне, авыл халкының милли үзенчәлекләрен озак өйрәнәләр. Биредә 1969 елда Томск университеты этнографлары, 1979 һәм 1989 елларда Омск университеты галимнәре киңкырлы тикшерү эшләре алып бара, авылның тарихы, этнографиясе, фольклоры буенча бай фәнни материал туплый. Шуларга нигезләп, себер татарларын озак еллар буе өйрәнгән тарихчы-галим, Омск тарих институты директоры Н.А.Томилов мондый нәтиҗәне чыгара (документ кыскартып бирелә):

«Деревня Юрт-Оры является древним поселением чатов – группы так называемых томских татар, входяших в сибирско-татарский этнос. К приходу русских чаты жили в районах Барабинской степи, представляли собой племенное объединение, возглавлявшееся князцами и мурзами... На Оби, у Кривой Луки, чаты основали городок, который в русских документах назывался Чатским. Как предполагают ученые, этот городок стоял на берегу Оби, где-то возле современной деревни Юрт-Оры. Имеются сведения, что чаты жили по берегам Оби и до прихода русских... Таким образом д. Юрт-Оры представляет собой древнее поселение сибирских татар на территории Новосибирского Приобья...» (Н.А.Томилов. Экспертное заключение об исторической значимости памятника истории Западной Сибири – деревни Юрт-Оры Колыванского района Новосибирской области. 4 ноября 1992 г.).

Рәсми документтан күренгәнчә, Йорт-Оры урынында VIII гасырдан себер татарлары яшәгән, аларның анда шәһәрлекләре булган, милләт (этнос) буларак исә алар бу якларда XVI гасырда формалашкан. Шушыларга нигезләп, өлкә хакимияте

Йорт-Оры авылын тарихи ядкяр буларак саклау турында махсус карар кабул иткән. *«Включить село Юрт-Оры Колыванского района, как памятное место, место древнего поселения сибирских татар, в списке памятников истории и культуры Новосибирской области, стоящих на государственной охране как объекты историко-культурного наследия местного значения»,* – диелгән бу карарда. Хөкүмәт карарына өлкә хакимияте башлыгы вазыйфаларын башкаручы В.Н.Киселев кул куйган. Карарга өстәмә рәвештә, дәүләт тарафыннан сакланырга тиешле бу тарихи объектта, Йорт-Оры авылында һәм аның тирәләрендә башкарасы эшләрнең планы да теркәлгән.

Дөресен әйткәндә, мин беренче тапкыр татарларның борынгы тарихын дәүләт

Йорт-Орыда чат татарлары музее

дәрәҗәсендә саклау һәм яклау турындагы шушындый хәлне, әлеге документны күрәм. Йорт-Оры авылын VIII гасырдан себер татарлары яшәгән урын, дигән бит! Бу – Себердәге татар авылына 1200 ел дигән сүз һәм шуны өлкә хакимияте, галимнәр таный! Таный гына түгел, авылны тарихи ядкяр буларак сакларга кирәк, дип, рәсми карар кабул итәләр, эш планнары төзиләр... Әлбәттә, бу карар бүгенге көндә тулысынча үтәлә, дип әйтеп булмый, әмма ул рәсми һәм тарихи документ буларак үз көчен югалтмаган, гамәлдән чыгарылмаган.

***

Халыкның сөйләве буенча, Йорт-Оры авылында Күчем хан үзе дә булган, бу авылда аның морзалары һәм яугирләре яшәгән. Авыл су юлында да, олы юл өстендә дә урнашкан, соңрак аның аша Мәскәү-Себер тракты үткән, каторжаннарны Турухан краена, рудникларга, Сахалин утравына моннан сөргәннәр. Йорт-Оры авылы аша декабристлар да үткән, Сахалин утравына юл тоткан Антон Чехов та биредә булган, Колчак гаскәрләре дә моннан көнчыгышка таба чигенгәннәр. Инде Россия составына кергәч, Йорт-Оры ир-атлары чирүле (йомышлы) татарлар булып хезмәт иткән, кулларына корал тотып, бу илнең көнчыгыш чикләрен саклаган, аның өчен бөтен сугыш-

ларда катнашкан, гомерләрен биргән. Узган гасырларда чат татарларының Төньяк сугышта, Наполеон яуларына каршы сугышларда катнашулары да билгеле.

Йорт-Орыда бүгенге көндә биш йөзгә якын кеше яши, ел фасылларына карап, бу сан үзгәреп тора – җәен, дачниклар хисабына, икеләтә арта, кышларын исә бик кими. Мин монда беренче тапкыр килгәндә, 2011 елның җәендә, биредә әле мәчет тә, музей да юк иде, ә хәзер икесе дә гөрләп эшләп тора! Хәер, Йорт-Орыда элек-электән мәчет булган, монысы инде – сигезенчесе. Авылда 1805 елда 137 чат татары яшәгән, 1897 елда бу сан 224кә җиткән, ә 1911 елда 270 кеше булган. Шунысын да әйтергә кирәк, еллар үткән саен, авылның милли составы үзгәрә барган, узган гасыр башында

Үзләре ясаган көймәләр чат татарларының төп транспорты

Йорт-Орыда яшәүчеләрнең 76 проценты – себер татары, 15 проценты – Идел буеннан күчеп килгән казан татары, 9 проценты исә урыслар булган.

Авыл халкы элек тә үз көнен үзе күргән, хәзер дә шулай. Зур су буенда яшәгәнлектән, биредә бигрәк тә балыкчылык киң таралган, Йорт-Орыда көймәне дә тоташ өянке агачыннан каеп, үзләре ясаганнар. *«Именно в д. Юрт-Оры в 1970-х годах этнографам удалось собрать ценные материалы по традиционным орудиям рыболовства (способы рыбной ловли острогами и лучением, удами и др.), средствам передвижения (лыжи-голицы с бортиками, лодки-долбленки, седла деревянные и др.)»*, – дип яза югарыда телгә алган экспертизасында профессор Томилов. Халык монда алтын куллы, һөнәрле, ризыклы, матур итеп көн күрә. Чат татарларының тышкы кыяфәтләре дә матур, аларда себерлек тә бар, европа йөзле, яшькелт күзлеләр дә очрый. Өй эчләре җыйнак, чиста-пөхтә, ризыклары тәмле, безнеңчә, саф татарча...

Мәчет һәм музей төзелешләре артыннан башлап йөрүче кеше – шушы авылда туып-үскән, элеккеге хәрби офицер, хәзер Новосибирск шәһәрендә яшәүче, өлкәнең милли һәм дини хәрәкәте активисты Навил әфәнде Шаһабетдинов. Ул – намаз иясе, читтән торып Казанда Ислам университетын тәмамлады, Йорт-Орыда «Иман» мөселман оешмасын теркәткән, өлкә күләмендә «Чат татарлары мирасы» оешмасы

эшләп килә, «Навил Шәех» псевдонимы астында рус телендә шигырьләр дә яза, китабы басылып чыккан. Йорт-Орыда тагы бик күркәм яңа традиция барлыкка килгән – һәр нәсел «Буыннар аллеясы»на үз агачын утырткан, ул бер чакрым арада авылга хәтле сузылган, 26 борынгы ыру үз шәҗәрәсен төзегән, шулай итеп, авыл башында хәзер нәсел урманы күтәрелеп килә.

Узган җәй Йорт-Орыда себер татарларының музее ачылды, анда мин дә катнашып, чыгыш ясадым, алар турында язылган хезмәтләремне, китапларымны бүләк иттем. «Чат татары утары» дип аталган тарихи-мәдәни комплексның нәкъ менә Йорт-Оры авылында төзелүе бер дә очраклы хәл түгел. Бу авылның нигез булып торырлык борынгы тарихы, лидерлык традицияләре, бүген дә шушы эшләрне алып барырлык шәхесләре бар. Музей-комплекста чат татарының карагай агачыннан салынган йөз еллык йорты, чоланы, мунчасы, бакчасы, җәйге йорты, коесы, мал абзары урнашкан. Өй эчендә себер татарларының бөтен яшәү рәвеше чагылыш тапкан – түр-сәкесе һәм акшарлы миче, бишеге һәм чиккән мендәрләре, сандыгы һәм савыт-сабасы урын алган, шулай ук ханнар һәм морзалар гына кия торган затлы җилән-чапаннар да элеп куелган. Чоланда исә себер татарларының бөтен эш кораллары – тоташ өянкедән каеп ясаган җиңел кәмә-каеклары, ишкәкләре, балык тоту өчен җәтмә-кармаклары, арба-чаналары, ау капкыннары, агач тырмалары, тимер сәнәкләре тезеп-элеп куелган. Алга таба бу татар утары Новосибирск шәһәренең туристлык маршрутына кертеләчәк, биредә каек-кәмәләр ясау, милли ризыклар әзерләү буенча да мастер-класслар үткәреләчәк.

Йорт-Оры авылының тарихын өйрәнү алга таба да дәвам итәчәк, чөнки монда җир астында әле ачылмаган татар тарихы җәйрәп ята... Бу тарихны хәзергә урыс галимнәре генә өйрәнә, нигәдер, Казан галимнәре бу якларга килеп җитә алмый. Ә килергә кирәк иде, чөнки урыс галимнәре әлеге борынгы тарихны ханты-мансылар, селькупларныкы белән бутап, нидидер гибрид халык тудырып яталар, чат татарлары турында да, татар дигәнен төшереп калдырып, *обские чаты,* дип кенә яза башлаганнар. Шул юл белән, моннан йөз ел элек чулым татарлары – *чулымцыга,* кузнец татарлары – *шорларга* һәм *телеутларга,* абакан татарлары *хакасларга* әйләнде... Чат татарларын да, татар сүзен алып ташлап, чат башына утыртып калдырмасалар ярар иде инде...

Йорт-Акбалык – Паш-Тура

Шушы ук районга кергән Йорт-Акбалык авылында да чат татарлары яши, мин анда инде икенче тапкыр булдым. Бу авыл Уен елгасы буенда, йөзәр еллык нарат һәм эрбет (кедр) урманнары арасында урнашкан. Авылның икенче исеме – Күрбәс, күрше авыллар аны соңгысы белән атап йөрткәннәр. Җирле галимнәр авылның исемен судагы ак балык белән дә, Балык морза исеме белән дә бәйләп аңлаталар. *«Село Юрт-Акбалык находится в 84 км. к северу от Колывани на окраине реликтового бора*, – дип яза алар. – *Юрт-Акбалык в переводе с тюркского означает: «юрта» – владение, позже – жилище; «ак» – белый, «балык» – рыба, т.е. жилище белой рыбы. Вторая версия происхождения названия села: Юрты Балыкские принадлежности поселения князю Балыку. Есть еще одно малоизвестное название этого поселения «Курбес» (в переводе с тюркского – видимые). Так называли жителей села их соседи из д.Батурино Томской области».* (Л.П.Чернобай. Малые реки левобережья Оби. – Новосибирск, 2011).

Авыл янында 56 борынгы курган бар, алардан бронза чоры һәм скиф ядкярләре табылган, галимнәр чат татарлары авылын өйрәнүне дәвам итә. Курганнардан чык-

кан әйберләрдән күренгәнчә, биредә кешеләр инде бронза чорында ук, ягъни моннан 4-5 мең еллар элек үк яшәгән, шулай ук төрки чор әйберләре дә табылган. *«Здесь хорошо сохранился комплекс исторического, этнографического и археологического наследия одной из ветвей сибирских татар-чатов, населяющих эту территорию более тысячи лет назад,* – дип яза галимнәр. – *Являясь коренной этнической группой Западной Сибири, чаты с момента формирования и до настоящего времени проживают в левобережной пойме Оби в населенных пунктах: Юрт-Ора, Черный Мыс (в переводе с тюркского «Кара Яр»), Красный Яр («Кызыл Яр»), Марахта (н/ж), Юрт-Акбалык и др... Аналогичный андроновский могильник эпохи бронзы обнаружен у д. Юрт-Акбалык*

Йорт-Оры авылы мәчете

Колыванского района... Наиболее изучены курганы этого периода у д. Юрт-Акбалык Колыванского района и Крохалевка Коченевского района. В могилах найдены бронзовые и железные поясные бляшки и даже иранская монета 534 г. Население принадлежало к монголоидному типу». (Л.П.Чернобай, күрсәтелгән хезмәт, 25-26, 74-75 битләр).

Археологлар ачкан борынгы Паш-Тура, ягъни Баш-Кала хәрабәләре дә монда. Бу исә себер татарларының электән бер үзәге – башкаласы биредә булган дигән сүз. Әйткәнебезчә, Йорт-Акбалыкта да бик борынгы һөнәр – тоташ өянке агачыннан каеп көймә (долбленка) ясау сакланып калган. Каек ясау һөнәре Новосибирск өлкәсенең өч татар авылында гына бар – Йорт-Орыда, Йорт-Акбалыкта һәм Ордын районындагы Усть-Олеузда.

«Больше всего Юрт-Акбалык известен своими мастерами, – дип яза җирле галимнәр. – *Здесь от отца к сыну передается уникальная технология производства лодок – долбленок, на которых плавали их далекие предки. Ученые не могут объяснить, каким образом до наших дней сохранились секреты мастерства тысячелетней давности. Сейчас в Юрт-Акбалыке 5-6 мастеров и около 30 используемых лодок. Наиболее известные мастера – Хакимулла Сафиевич Муратов, Муталлап Сафаргалиевич Амиров и Робинзон (Рубчик) Рахматуллович Мавлютов. Правда, сами они уже не*

долбят лодки, но молодых учат охотно. Весной 2011 года в селе была изготовлена еще одна лодка». (Л.П.Чернобай, күрсәтелгән хезмәт, 26 бит).

Мондый тоташ каекларны Америка индеецлары да ясаган, ул шулай ук Аляска эскимосларында да булган. Шушындый тоташ каекны мин Мюнхен шәһәрендәге Бөтендөнья көймәләр музеенда да күреп кайткан идем, ул дүрт катлы музейның бер залына куелган һәм аның кырыена «төньяк халыкларының каегы» дип язылган иде. Кем белә, бәлки заманында Йорт-Акбалык татарлары ясаган өянке каегы шулай алман иленә килеп эләккәндер...

Чат татарлары белән аралашканда, бигрәк тә аларның каекларын күргәч, тагы

Йорт-Акбалык мәчетендә халык белән очрашу

Америка индеецлары искә төште. Майя һәм ацтек кабиләләренең төрки халыклар белән тарихи уртаклыклары турында татар галиме Әбрар Кәримуллин күптән язып чыккан иде инде. Бу көннәрдә матбугатта, интернетта тагы бер хәбәр халыкны кузгатып алды – баксаң, Америка индеецларының Ана Ватаннары Себер, Алтай крае икән бит! Пенсильвания университеты галимнәре тикшерүенчә, Америка индеецлары моннан 14 мең ел элек Себердән Аляскага, аннан Американың башка төбәкләренә таралган. Галимнәрнең әйтүенчә, Алтай краенда моннан 20 мең еллар элек яшәгән кеше җәсәденең генетик структурасы бүгенге Америка индеецларыныкына бөтенләе белән туры килә икән. Бу нәрсә дигәнне аңлата? Бу – бүгенге көндә Себернең төп һәм иң борынгы халкы булган татарларның, бигрәк тә, чат һәм бараба татарларының нәселе Америка индеецларында да дәвам итә дигән сүз. Моңа тарих уртаклыгы да, йөз-кыяфәтнең бертөрлелеге дә, аерым сүзләрнең туры килүе дә керә, бары тик чат татарларында һәм Америка индеецларында гына сакланып калган каек-кәмәләр турында инде әйтеп тә тормыйм... Ә «Алтай крае» дигән төбәк атамасына килгәндә, ул бары тик 1937 елда гына барлыкка килә, аңа кадәр хәзерге Новосибирск, Томск, Кемерово, Алтай крае «Западно-Сибирский край» дип атала, ә ерак тарихта исә бу төбәк Бараба-Парапа – Татар Даласы, буларак билгеле...

Йорт-Акбалык халкы, аның морзалары моннан нәкъ 400 ел элек урыс патшасына ант китерергә мәҗбүр булган, бу хакта тарихи документлар саклана. 1911 елда Йорт-

Акбалыкта 44 өйдә 280 кеше яшәгән, аларның 205 баш атлары, 180 сыерлары, 50 сарыклары һәм кәҗәләре булган. Бу – һәр хуҗалыкка 4-5 ат һәм сыер малы туры килә дигән сүз бит, халык бай яшәгән дигән сүз! 1910 елда халык җыелып үз акчасына мәчет сала, мәчет каршында мәдрәсә була, анда укулар татар һәм гарәп телләрендә алып барыла. Авылның үзендә хәтта кибете дә була! Хәзер бу авылда биш йөздән артык кеше яши, барысы да диярлек татарлар. Йорт-Акбалык халкы башлыча урманнан туена: аучылык итә, җиләген, гөмбәсен, эрбет чикләвеген җыя, үзенә дә ел буена җитәрлек итеп әзерли, артыгын сата. Халык шулай ук мал асрый, итчелек белән шөгыльләнә, балык тота.

Авыл халкында тарих, әдәбият белән кызыксыну да көчле булып чыкты, дингә тартылу да сизелә, эрбет урманы аланында Сабан туйлары уздырыла. Казанның, татар галимнәренең бурычы – бу авылны төрле яктан өйрәнү, тарих, тел, мәдәният, һөнәр үзенчәлекләрен киләчәк өчен теркәп калу булырга тиеш. Йорт-Акбалыкта тугыз еллык мәктәп бар, элек анда укыту бары тик татар телендә алып барылган, хәзер исә татар теле йә предмет, йә факультатив итеп кенә укытыла. Халык белән бу турыда да җитди сөйләшү булды. Йорт-Акбалыкның тарихы өйрәнелмәгән, язылмаган, авылда аны язардай кешеләр бар. Алар – мәктәп директоры Вилюр әфәнде Мәүлетов һәм Новосибирскидан килеп, бирелә алман теле укыткан иманлы милләттәшебез Мөдәрис Абакиров. Нур өстенә нур булып, шушы кара урман уртасындагы татар авылында соңгы елларда мәчет ачылган, мин беренче барганда ул әле юк, моңа бик үзәгем өзелгән иде.

***

Кайбер галимнәрнең язуы буенча, бараба, чат татарларына ислам дине XVIII гасырда гына кергән, аңа кадәр алар, имеш, курчакларга табынган. Әлбәттә, бу күренеш тә, дата да бәхәсле, чөнки Себер ханлыгы составында яшәгән татарлар ислам динен шул вакытта ук кабул иткәннәр, нәсел шәҗәрәләреннән күренгәнчә, алданрак кабул итү очраклары да булган. Себер татарларының ислам динен кабул итүендә Бохарадан килгән дәгъватчы-мессионерларның, соңрак Казан ягыннан килгән мөселман-татарларның да роле зур. Кайбер галимнәрнең язуынча, бу якларда ислам динен чат татарлары тараткан, алар инде XVI-XVII гасырлардан ук исламда. Мин Йорт-Акбалыкта да, Йорт-Орыда да мәчетләрдә халык белән очраштым, аларга борынгы тарихыбызны сөйләдем, динебезне аңлаттым, китапларымны бүләк иттем.

Новосибирск өлкәсе – себер татарлары яши торган иң соңгы һәм иң ерак төбәк, аннан соң инде Алтай крае һәм Казакъстан башлана. Әмма шушы ераклыкка карамастан, өлкәдә милли һәм дини эшләр яхшы бара, төрле фестивальләр, милли-мәдәни чаралар гел булып тора. Соңгы вакытта биредә милләт тарихына да зур игътибар бирә башладылар: берничә фәнни-гамәли конференция уздырылды, төбәктәге татар тарихы турында китаплар чыгарылды, менә хәзер милли музейлар да ачыла башлады. Алда торган бурыч – Новосибирск шәһәрендә Себер ханлыгының соңгы башкаласы булган Чат шәһәрлеген яңадан торгызу, анда себер татарларының музеен ачу, милләткә үз бөек тарихын кире кайтару.

Шунысын да әйтергә кирәк, Новосибирск шәһәре һәм өлкәсенең герб-тамгасы Себер ханлыгының туграсын кабатлый – аягүрә баскан кара кеш-собольләр хан таҗын саклап басып тора. Димәк ки, бары тик XIX гасыр азагында гына барлыкка килгән Новониколаевск-Новосибирск шәһәре һәм төбәге, үзе дә сизмәстән, җирләре һәм халкы белән бергә, Себер ханлыгының дәүләти символын һәм традицияләрен дә кабул иткән. Шулай итеп, бу бөек тарих яңадан татарларның үзләренә кайта башлады. ■

Новосибирск шәһәренең мәдәни тормышыннан кайбер сәхифәләр



Новониколаевск (хәзерге Новосибирск) шәһәренең 1915 елгы картасында ипподром, Татар урамы, бистәсе һәм зираты. Фрагмент

Татар бистәсе һәм мәчетләр тарихы

Новосибирскида татарлар шәһәр оешканнан бирле яшәсә дә, 1908 елдан соң гына бистә булып тупланалар, дип әйтергә мөмкин. Нәкъ менә шул елда татар җәмәгатьчелегенең үтенечен истә тотып, милләттәшләребезгә Крылов һәм Гоголь урамнарыннан йортлар салыр өчен, 18 ел аренда шарты белән, 7 квартал җир бирелә. Новосибирск шәһәрендә татарлар Фрунзе урамындагы тарихи мәчет, Ипподромная һәм «Березовая роща» тукталышлары, «Строитель» һәм Жиркомбинат» мәдәният йортлары тирәсендә, Достоевский, Некрасов, Лермонтов, Кольцов, Дарьялская урамнарында күпләп яшәгән. Хәзерге шәһәрнең иң зур урамы «Ипподромная» заманында «Татар урамы» дип аталып, аның үзәгендә ат чабышлары оештырылган.

***

1907 елда имам Гариф Вәлиев башлангычы белән мәчет салу өчен акча җыела башлый, шәһәр хакимияте җир бүлеп бирә. 1910 елның май аенда мәхәлләдән берничә кеше, мәчет төзелешенә рөхсәт алу өчен, Санкт-Петербург шәһәренә, премьер-министр П.А.Столыпин янына бара. Шулай итеп, 1916 елны Бурлинская урамында (хәзер Фрунзе) мәчет төзелеше башлана. Шәһәрдә яшәүче Э.Алямовның әйтүенә караганда, аның

бабасы К.Насретдинов, ат арбасына төяп, мәчет нигезе өчен гранит таш ташыган. Мәчетне төзү эшендә Новосибирскиның барлык мөселманнары да диярлек катнаша. Төзелешкә Н.Әгъләмов җитәкчелек итә. Шулай ук әлеге изгә эштә А.Мамлиев, М.Әгъләмов, С.Мәхмүтов, А.Кутаев, Н.Хөсәеновлар да актив катнаша. Шәһәрнең иң бай татар сәүдәгәрләре А.Низаметдинов, Рамазанов, Мәхмүтовлар матди ярдәмне кызганмый. 1916-1917 елларда төзелеп беткән мәчет тиз арада Новосибирск татарларының рухи-мәдәни үзәгенә әйләнә. Н.Әгъләмов аның имамы булып эшли башлый.

Мулла Гариф Вәлиев (сулда)

Истәлекләргә караганда, мәчеткә хатын-кызлар да йөргән. Алар намазны балалары белән югарыдагы антресольдә, намазлык белән килгән ирләр исә түбәндә укыган. 1924 елда мәчет бинасында татар мәктәбе дә эшли: әти-әниләр, укытучы яллап, балаларын укыта. 1927 елның 15 июнендә мәчеттә Новосибирск шәһәре мөселманнарының җыены узганы да мәгълүм.

Шунысын да әйтергә кирәк: Новосибирск татарлары беренче Сабан туен 1930 нчы еллар уртасында шәһәр ипподромында үткәрә. Шунда ук ат чабышы һәм көрәшне дә оештыралар, балаларга бүләк тә өләшәләр. Шул еллардан соң татар бистәсендәгеләрне эзәрлекли башлыйлар. Насыйбулла Хәсәнов, Гомәр Хәсәнов, Идрис Кадыйров,

Фрунзе урамындагы тарихи мәчетнең 1920 нче еллардагы фотосы

Әгъләмов, Хөсәенов, Исмайловлар, гомумән, Фрунзе һәм Совет урамында яшәүче шактый гына ир-ат репрессияләнә. Аларның бик сирәкләре генә төрмәдән кире әйләнеп кайта.

1937 елда мәчет мөселманнардан тартып алынгач, манарасын сүтеп, икенче катны төзиләр. Биредә төрле елларда янгын сүндерүчеләр клубы, сугыш елларында госпиталь, соңрак «Новосибдорстрой» тресты урнаша.

***

Новосибирскида тагын бер төзелеп бетмәгән мәчетнең тарихы мәгълүм. Җирле татарлар аны хәзерге «Берёзовая роща» паркына (элекке зират урынын саклап калырга теләп булса кирәк), «Чертово колесо» аттракционы янында төзи. Төзелешне Тобольскида туган, 1946 елда Новосибирск имамы итеп тәгаенләнгән Х.Хәлиуллин оештыра. Мәчет төзелеп бетә, манара куеп, эчке эшләрен генә башкарасы кала. Әмма бу мәчет ачылмый. Ф.Вахитов, М.Зәйнуллин һәм тагын өч активист кулга алынып, төрмәгә озатыла. Мәчет бинасы, сатылып, башка урынга күчерелә һәм йорт буларак файдаланыла башлый, ә зират урынында парк төзелә.

Совет чорында Новосибирск шәһәрендә төрле елларда берничә урында намаз йорты була. 1943 елда Пушкин урамындагы 113 нче йортта да дини мәхәллә теркәлеп, 50 кешелек гыйбадәт йорты ачыла. Әмма, 1948 елда дингә каршы сәясәт көчәю сәбәпле, район башкарма комитеты карары нигезендә, гыйбадәтханә мөселманнардан тартып алына һәм бинасы утынга ягыла. 1950 елдан татарлар җомга һәм бәйрәм намазларын Крылов урамында үз акчаларына сатып алган 122 нче йортта укый башлый. 1968 елда бу йорт сүтелә. 1970 нче елларда МОПР урамында сатып алынган йорт дини үзәккә әйләнә. 1993 елга кадәр Дарьяльская урамында урнашкан 4 нче йорт мәчет вазыйфасын башкара. Шулай итеп, Новосибирск татарлары совет чорында да дини йолаларны, традицияләрне сакларга омтыла.

***

Җирле татарлар берничә дистә ел дәвамында Фрунзе урамында 1916 елда төзелгән тарихи мәчет бинасын кайтарырга омтылып карый. Фәкать 1992 елның декабрендә генә Новосибирск шәһәр Советы гыйбадәтханәне Көнбатыш Себер мөхтәсибәтенә

бирү турында карар чыгара. Әмма бина 1993 елның азагында, татарлар оештырган митингтан соң гына кайтарыла. 2010 елда мәчеткә реконструкция ясала: әүвәлгеләр салып калдырган нигез урынына, элекке архитектура стилен саклап, яңа бина төзелә.

Татар мәктәбе

Өлкә архивы мәгълүматларына караганда, 1924-1925 елларда Новосибирск округында 102 татар мәктәбе, 1925-1926 уку елында – 112, 1935-1936 уку елында 194 татар мәктәбе эшли. Рус мәктәпләрендә дә татар классларының саны арта. 1924 елда Новосибирск шәһәрендә татар һәм башкорт мәктәпләре өчен «Русский букварь: тексты с ударениями и переводами» исемле дәреслек басылып чыга. Татар мәктәпләре өчен укытучы кадрлар Томск шәһәрендәге Себер төрки-татар педтехникумында әзерләнә.

Новосибирскиның татар мәктәбе шәһәр үзәгендә – Ипподромная тукталышында, Демьян Бедный һәм Татар урамнары чатында урнашакан бинада 1924 елда ачыла. Бер катлы бина янәшәсендә укытучылар өчен тулай торак та була. Мәктәп директоры Хизбулат Бәширов та шунда яши. Җидееллык мәктәптә барлык фәннәрдән дә татар телендә белем бирелеп, уку ике сменада оештырылган. Хизбулат Бәшировның кызы Галия ханымның әйтүенә караганда, әтисе 300ләп баланы театрга алып барган. Шушы саннан гына да мәктәптә күпме татар баласы белем алганын чамаларга мөмкин. Татар мәктәбендә балалар бакчасы һәм драма театры да эшләгән. Бу театрда уйнаучылар нигездә татар мәктәбенең укытучылары икәне мәгълүм. Күпләр әле дә биология һәм химия укытучысы, соңрак мәктәп директоры булып эшләгән Хизбулат Бәшировның бик оста итеп мандолина, думбра һәм скрипкада уйнавын искә ала.

1943 елдан мәктәптә русча гына укыта башлыйлар. 1948-1950 елларда анда башлангыч сыйныфлар гына эшли, татар теле бөтенләй укытылмый. Уку йорты ябылганнан соң, аның бинасында балалар бакчасы урнаша, ә укытучылар шәһәрнең башка мәктәпләренә таратыла.

Татар мәктәбе укучылары. Уртада – Хизбулат Бәширов

Татар драма түгәрәге артистлары. Беренче рәттә мәктәп директоры Хизбулат Бәширов. 1939 елның 6 марты

«Азат Себер» газетасы

1920-1930 елларда «Азат Себер» газетасы редакцисе дә иҗтимагый-мәдәни тормышның үзәгенә әйләнә. Газетаның беренче саны 1919 елның 23 декабрендә Омск шәһәрендә басыла. 1921 елдан ул Новосибирскида нәшер ителә башлый. Беренче мөхәррире – Фәхри Әхмәтов. Төрле елларда җаваплы мөхәррир булып С.Фәхриев, Х.Гайсин, М.Юсупов, И.Вәлиев, Х.Курмаев һәм Х.Вәлиевлар эшли. «Азат Себер» 1924 елда – 1100, 1925 елда – 1200, 1928 елда – 2300, 1930 елда 6250 данәдә атнага бер мәртәбә тарала. 1930 нчы елларда ул тагын да ешрак чыга башлый. 1931 елда – 120, 1931 елда – 119, 1932 елда – 161, 1933-1934 елларда – 180, 1935 елда 128 саны дөнья күрә.

«Азат Себер» редакциясенә чит ил һәм СССРдагы яңалыкларны яктырту, партия, эшчеләр, хатын-кызлар, авыл хуҗалыгы, кооперацияләр тормышы турында язу бурычы куела. Шул юнәлештә махсус рубрикалар да эшли. 1921 елда газетага кушымта итеп «Яшьләр сәхифәсе» исемле журнал чыга. 1939-1931 һәм 1933-1934 елларда, татар алфавиты реформасын пропагандалап, «Яңалифкә сәфәр» исемле кушымтасы да басыла.

Редакциягә Томск, Анжеро-Судженск, Кемерово, Прокопьевск, Кольчугино, Омск, Тара, Иркутск, Бодайбо, Красноярк, Минусинск, Каргат шәһәрләреннән, Алтай губернасы һәм Ойрот Автономияле өлкәсеннән махсус билгеләнгән хәбәрчеләр даими мәгълүмат җибәреп торган. Аларга бу хезмәт өчен каләм хакы да тәгаенләнгән. Кызганыч, 1936 елда «Азат Себер» газетасы чыгудан туктый.

Әлеге газета турында татар вакытлы матбугаты белгече Исмәгыйль Рәмиев 1925 елда менә ниләр язган: «1919 елда 23 декабрьдә «Русия коммунистлар партиясенең Омск вилаять комитеты янындагы мөселман секциясе һәм Омск ревкомитеты тарафыннан чыгарыла торган әдәби һәм сәяси татарча гәзитә» булып, Себер өлкәсе Колчак бандаларыннан тазартылганның соңында чыга башлады. Себердә чыгарылган гәзитләрдән иң озак дәвамлысы һәм төп гәзит булып шушы калды. Хәзерендә дә дәвам

итә. Үзгәрә торган лозунгларыннан берсе: *«Тиф йокмасын, дисәң, таза-чиста йөрергә, җыш-җыш эчке киемне алыштырып торырга кирәк. Тифтан саклану өчен бердәнбер чара – таза йөрү. Моны бер дә истән чыгарырга ярамый».*

Имля вә теленнән үрнәк:*«Элекке канлы Николай заманында чиннарын арттыру өчен тырышып йөргән бер токым чукынчык морзалар, аларга ияреп ахмак муллалар бер-бер нәрсә булса җыелып, садыйк тәбәгалекләрен (тугрылыкларын. – **Ред.**) белдереп, патшага телеграм җибәрәләр вә шул телеграмнары бәрабәренә Петрда утыра торган берәр министр көчегеннән «эспасибо» алсалар, бик зур эш эшләгән кебек үзләрен җуаталар иде. Ач татар чиновниклары губернатор тирәсенә барып, мөселманнарның эшләре өстеннән: «Безнең татарлар арасында революционерлар появитсә итә башлады. Ваше привосходительсто, бундый явлениеләрне тамырыннан бетерергә, зачинщикларны ябарга кирәк», – дип донос биреп, иң алама шпионлык хезмәтен итә башлады.*

«Азат Себер» газетасы мөхәррире Муса Юсупов

Чехословаклар килеп чыкканга кадәр бу адәм калдыклары шул писарьлекләрен дәвам иттеләр! Әфитсәрләре – гаскәри шура, учительләре Милли идарә тирәсенә җыелып, тышларын кызыллы-яшелле буяуга буяп, тамакларын туйдырып килделәр. Колчак килеп чыгу белән бу кешеләр, Колчак алдына килеп, верный подданлык күрсәтә башладылар. Зуррак морзалары, Колчак тирәсенә килеп, башкорт, кыргыз, казакъ ярлысын берьюлы һәм ваклап сатар өчен консуллык вазыйфасын үти, әфитсәрләре: «За веру и за Родину», – дип, татар солдатларын тәпәли, чукынчык мулласы, епископ Әндрий белән бергә кочаклашып, татар-башкорт партиясеннән, «Святой крест» полкы янында, пәйгамбәр полкы – «Яшел әләм» төзи, неграмотный учитель прапорщиклары гәзитә чыгарырга башладылар». 2 нче номер.

Төрле форматта, атнага бер-ике тапкыр чыга. Бу гәзиткә нигез салучы Фәхри Әхмәтов булып, соңыннан идарәсе Новониколай шәһәренә күчерелгәч һәм гәзит тә РКПның Себер бюросы янындагы татар-казакъ бүлеге һәм Себер ревкомы нашир әфкяре булып әверелгәч, аңар Муса Юсупов мөхәррирлек итте. Хәзерендә җаваплы мөхәррире – Сарим Фәхри».

Әдәбият:

1. Абакиров М.Ш. Татары Новосибирской области. – Новосибирск: Сибирское книжное издательство, 2012. – 264 с.
2. Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты: альбом (1905-1925). – Казан: Гажур, 1926. – Б.109.

*Текстны **Мөдәрис Абакиров** һәм*
***Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Безнең мирас №6 июнь 2019

Камышлы хатирәләре

Минвәгыйз Зәйнетдинов*

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КПССның КУЙБЫШЕВ ӨЛКӘСЕ КАМЫШЛЫ РАЙКОМЫ һәм ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ РАЙОН СОВЕТЫ ОРГАНЫ

ЮГАРЫ УҢЫШ ӨЧЕН

30 нчы чыга
№ 141 (2704)
ЧӘРШӘМБЕ
23
НОЯБРЬ
1960 ел.
Бәясе 15 тиен.

ХАЛЫК СУДЛАРЫНА САЙЛАУЛАРГА ХӘЗЕРЛЕК

Агитация-масса эшләре конкрет алып барыла

Безнең район буенча

Осталык үсә бара

18 ноябрьдә район Культура йортында яшьләр кичәсе булды. Анда Культура йортының үзешчән драма түгәрәге драматург Гөлшат Зәйнәшеваның «Сәер мәхәббәт» дигән ике пәрдәлек пьесасын куйды.

Беренче күренеш үк пьесаның яхшы хәзерләнүен, уйнаучыларның рольләр өстендә бик тырышып эшләүләрен күрсәтте. Рольләр барысы да тулы ачылды. Айзирәк һәм Рәхим Камали рольләрен башкаручы М. Салахова һәм В. Зәйнетдинов иптәшләрнең оста уйнауларын аеруча билгеләп үтәсе килә.

Спектакльдә бердән-бер кимчелек бар. Ул да булса—Нәфисә белән Шәрәф

Сок елгасы үзәнлеге

---

* Минвәгыйз Зәйнетдинов –Камышлы драма түгәрәгенең 1959-1961 еллардагы җитәкчесе. Шуннан соң «Социалистик Татарстан» газетасының хәбәрчесе, «Татарстан» радиосы җитәкчесе, «Чаян» журналының җаваплы секретаре булып эшләде.

Минем өчен яшьлекне сагыну – Камышлыны сагыну. 1959 елның көзендә миңа, Казан Дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаган егеткә, юллама буенча Камышлының «Югары уңыш өчен» газетасы редакциясендә эшли башлагач, әдәбият-шигърият түгәрәге оештырып җибәрергә, «Үткер күз» исемле сатира-юмор почмагы ачарга насыйп булды. Аның беренче утырышында корректорыбыз Һава Сафина, Камышлыда яшәүче хуҗабикә Мәрьям апа Якупова һәм типография эшчесе Сәгыйт абзый Галиуллин гына катнашты. Тора-бара түгәрәккә йөрүчеләр, башлап иҗат итүчеләр саны ишәйде. Алар арасында шигырьләре газетада күренә башлаган, әле 16 яшен генә тутырган, бүген исә танылган публицист, «Бердәмлек»не чирек гасыр буена җитәкләгән баш мөхәррир Рәфгать Әһлиуллин да бар иде. Читтән дә, Самара өлкәсенең башка төбәкләреннән дә хатлар килә башлады.

Авыл яшьләре Сабан туена әзерләнә. Камышлы, 1961 елның язы

«Югары уңыш...»ның ул заманда өлкәдә татар телендә нәшер ителүче бердәнбер басма икәнлеге күпләргә мәгълүм булса, редакция каршында шигърият түгәрәге эшли башлавы турындагы яхшы хәбәрне бөтен өлкәгә Сәет Сәмигуллин таратты. Ул Камышлы кешесе, газетада фотолары, язмалары белән даими катнашучы актив хәбәрчебез иде. Аның «Литературный кружок» дигән хәбәре өлкә «Волжская коммуна» газетасында 1960 елның 19 маенда басылып чыкты. Шуннан соң Камышлыга хатлар килү ешайды. Кошки районының Иске Фәйзулла (Иске Җүрәй) авылында яшәүче Гакыйль Сәгыйровның да иҗат җимешләрен ала башладык. Алар, түгәрәктә укылып һәм хупланып, газетаның айлык «Әдәби сәхифә»сендә басылалар иде. Хәзерге Елховка районының Теплый Стан (Тупли) авылыннан кебек хәтерлим, Нәби Туплейский дигән авторыбыз редакциягә поэма кебегрәк күләмле әсәрен дә юллаган иде. Аны, бераз эшкәртеп һәм кыскартып, шулай ук «Әдәби сәхифә»дә бастырып чыгардык.

Редакция «бобигы» белән командировкага бару.
1960 елның җәе

***

Камышлы театры турындагы беренче хәбәрне мин район типографиясендә эшләүче полиграфист Сәгыйт абзый Галиуллиннан ишеттем. Без аның белән һәр көнне очрашып сөйләшә торган идек. Сәгыйт абзыйның: «Спектакльләрдә мин дә уйнадым. Инде олыгаеп барам. Сәхнәдә сез, яшьләр уйнагыз, ә без тамашачы булырбыз», – дигән сүзләре әле дә хәтеремдә.

Бу фикер-идеяне мин дә хупладым һәм чынлап торып эшкә керешергә булдым. Сәхнә, артистлар тормышы белән азмы-күпме танышлыгым булуын да искә төшердем шулчак. Казан дәүләт университетын тәмамлаганда «Ш.Камалның «Козгыннар оясында» драмасының сәхнә тарихы» дигән темага диплом эше язып, аны «бишле»гә яклаган идем. Язарга материал туплаганда танылган режиссерлар Ш.Сарымсаков, Г.Ильясов, мәшһүр артистлар Х.Әбҗәлилов, Х.Уразиков, Н.Гайнуллин һ.б. белән очрашырга, истәлек-хатирәләрен ишетергә насыйп булды. Күп тапкырлар аларның исән чагында сәхнәдә уйнаганын күрү бәхетенә дә ирештем.

Үзешчән шагыйрә Мәрьям апа Якупова белән очрашу. Камышлы, «Югары уңыш өчен» газетасы редакциясе, 1960 ел, март

Без өчәүләп (Д.Әхмәтгалиев, Җ.Бәдретдинов, М.Зәйнетдинов) сәхнәдә җыр сузабыз

Шулар мине эшкә рухландыргандыр да инде. Репертуар сайлый торгач, драматург Кәрим Әмиринең «Зәңгәр күл» исемле пьесасына тукталдык. Ул заманда Камышлының район мәдәният йорты, «Яңа тормыш» колхозы идарәсеннән астарак, сөзәк тау битенә урнашкан агач бинада иде. Кичләрен, яшьләр белән бергә шунда җыелып, репетицияләр үткәрә башладык. Мин фәкыйрегез – оештыручы, режиссер сыйфатында. Спектакль ике-өч айдан әзер дә булды, без аны 1959 елның 13 декабрендә тамашачыга тәкъдим иттек.

1960 елның көзендә без икенче постановканы да өлгерттек һәм сәхнәдә уйнадык. Бу хакта редакциянең җаваплы секретаре «Югары уңыш өчен» газетасында (18 ноябрь саны, 1960 ел) «Осталык үсә бара» дип язып та чыккан иде. Хәбәр әллә ни зур булмаганлыктан, аны тулысынча диярлек китерәм:

«18 ноябрьдә... Культура йортының үзешчән драма түгәрәге драматург Гөлшат Зәйнашеваның «Сәер мәхәббәт» дигән пьесасын куйды.

Беренче күренеш үк пьесаның яхшы хәзерләнүен, уйнаучыларның рольләр өстендә бик тырышып эшләүләрен күрсәтте. Рольләр барысы да тулы ачылдылар. Айзирәк һәм Рәхим Камали рольләрен башкаручы М.Салахова һәм М.Зәйнетдинов иптәшләрнең оста уйнауларын аеруча билгеләп үтәсе килә...»

Автор, спектакльдәге кайбер кимчелекләргә дә тукталып, хәбәрен: *«Гомумән, драма түгәрәге членнарының башкару осталыгы үсә бару безне бик шатландыра. Киләчәктә тагын да уңышлырак спектакльләр булыр дип ышанабыз»,* – дип тәмамлый.

Әйе, андый спектакль дә туды. Гамир Насрыйның «Яшел эшләпә» дигән комедиясен сәхнәләштердек. Төп рольне стиляга егетне үзем башкардым. Хупҗамал һәм башка рольләрдә уйнаган сәхнәдәш дусларымны, кызганыч ки, берсен дә хәтерләмим. Спектакльне без Камышлының үзәк урамында урнашкан яңа мәдәният йорты сәхнәсендә уйнадык.

Шунысын да әйтим: һәр постановка районның күпчелек татар авыллары сәхнәләрендә күрсәтелде. Яшьлек елларыбызны, вакытыбызны Камышлыда исраф итмәдек. Район газетасына, әдәби түгәрәккә, «Халык театры» исемен алачак иҗат коллективы уңышларына үзебездән бераз өлеш кертканбездер, дип уйлыйм. ■

РИЗАЭДДИН КАЗЫЙ САБАКТАШЫ ХӨСНУЛЛА АХУН

Самара өлкәсенең хәзерге Камышлы районындагы Иске Ярмәкнең берничә кешесе данлыклы Чыршылы (Чәшеле) мәдрәсәсендә укыган булса да, алар мөгаллим хезмәтенә алынмаган. 1888 елда, җыен карары нигезендә, Гәрәй Әһлиуллин, Сәләх Зәйнәгетдинов һәм Габделгани Габдерәшитовлар әлеге мәдрәсәгә мөгаллим сорап бара. Шулай итеп, уку йортыннан заманы өчен шактый алдынгы карашлы хәлфә Хөснулла Баһаветдин углын Иске Ярмәккә җибәрергә уйлыйлар.

ЧАБАК БАБАЙ НӘСЕЛЕ

Хөснулла ахунның нәселе **Чабак** исемле бабайдан башлана. XVI гасырның өченче чирегендә Чабакның улы **Тәүтил**, улы **Хөсәен** һәм оныклары **Әмир** (1745 елда туган), **Бәшир** (1747), **Зәбир** (1755), **Яһүдә** (1761), **Бәрки** (1764), **Зөлкәрнәй** белән Сембер губернасындагы Яңа Шәйморза авылыннан Самара губернасындагы Иске Үтәмеш авылына күчеп килә. 1795, 1811 еллардагы ревизия материалларында биш агай-эненең гаиләсе белән Иске Үтәмештә яшәве теркәлгән. 1816 елгы халык санын теркәү кенәгәсендә 70 яшьлек **Әмир бине Хөсәен** белән 68 яшьлек **Бәшир бине Хөсәен**нәрнең генә Иске Үтәмештә гомер итүе турында мәгълүмат бар. Башка кардәшләр Югары Чагадайга күчеп киткән, дип уйларга мөмкин.

Хөснулла ахунның бабасы **Мөхәммәдәмин Бәшир углы** (1773 елда туган) һәм әбисе Мөхәрәя (1776) гаиләсендә алты бала дөньяга килә: **Мәнихә** (1799), **Мөхәммәтрәхим** (1800), **Мөхәммәдъяр** (1804), **Габделкәрим** (1806), **Фәсхетдин** (1811-1816) һәм **Баһаветдин** (1816).

ШӘКЕРТ, МӨГАЛЛИМ, ИМАМ-ХАТЫЙП ҺӘМ АХУН

Хөснулла Баһаветдин углы 1857 елда хәзерге ТРның Чирмешән районы Югары Чагадай авылындагы урта хәлле гаиләдә сигезенче бала булып туа. Сигез яшенә кадәр авыл мәктәбендә өч ел белем ала. 11 яшендә, ягъни 1868 елда Чыршылы авылы мәдрәсәсенә – хәлфә Габделфәттах хәзрәткә укырга керә. Анда бер ел укыгач, әнисе Мәгъшия вафат була, әтисе икенче хатынга өйләнә. Зур гаиләдән (35 кашык ашый идек, дип искә алына; Мәгъшиядән туган **Насыйретдин, Садретдин, Дәүләтша, Батырша, Хөсәен, Идрис, Мингалим**; Шәмсиядән туган **Гыйләҗетдин, Фатыйма, Хәдичә, Миңнехәйрия, Тайбә, Хәнифә**) әллә ни ярдәм булмаганга, Хөснулла шәкерт җәй көннәрен Габделфәттах хәзрәтнең йортында хезмәт итеп үткәрә.

Хөснулла Баһаветдин улы Чыршылы мәдрәсәсендә булачак мәгърифәтче Ризаэддин Фәхреддин белән бергә егерме елдан артык, ягъни 1889 елга кадәр укый. Шәкертләр бередә Чыршылы волостенда писарь булып эшләүче Мухранов фамилияле бер кеше белән таныша. Ул аларга рус телен өйрәтә, А.Пушкин, Л.Толстой, К.Маркс, Ф.Энгельс китапларын да табып бирә. Озак та үтми, башка шәкертләр, көнләшеп,

Ризаэддин белән Хөснулла өстеннән мәдрәсә мөдиренә рус телен өйрәнәләр, дип шикаять яза. Нәтиҗәдә, русча укыганы өчен, Хөснулланы мәдрәсәдән чыгаралар. Туганнары, куылуны хурлык, дип санап булса кирәк, шәкерткә этисе янына кайтмаска куша. Янәдән писарь Мухранов ярдәмгә килә: Хөснулланы, үзенең ярдәмчесе итеп, 5 сум хезмәт хакына эшкә ала. Шәкерт аңа бер ел хезмәт итеп, эш кәгазьләре тәртибен дә өйрәнә.

Көннәрдән бер көнне Хөснулланың тормышында хәлиткеч вакыйга була. Чыршылы волостена патша хөкүмәтенең дуңгыз чумасы авыруына мөнәсәбәтле карантин турындагы мөрәҗәгате килә һәм аны отставкага чыккан солдат дөрес тәрҗемә итмичә, халыкның башын бутый. Имеш, патша хөкүмәте авыл кешеләрен чучка үрчетергә чакыра икән! Бу авылдашлар арасында гауга чыгара. Нәтиҗәдә, Габделфәттах хәзрәт Хөснуллага мөрәҗәгать итәргә мәрҗбүр була. Шәкерт, хатны төгәл тәрҗемә кылып, дары мичкәседәй шартларга торган халыкны тынычландыра. Шулай итеп, Хөснулла яңадан мәдрәсәгә хәлфә булып кайта.

1889 елда Хөснулла хәлфәдә сабак укый башлаган Сараҗ, Шиһап, Гариф, Зәки исемле шәкертләр дә Иске Ярмәккә күченә. Бирегә килер алдыннан аңа сабакташы Ризаэддин хәзрәт үзенең ике туган сеңелесе Нурҗиһан Хөснетдин кызы Рахманкулованы, никах укып, кияүгә бирә. Бу вакытта егеткә – 32, ә кызга 19 яшь була. Иске Ярмәк халкы яшьләргә алты почмаклы өй әзерләп бирә. Әмма Хөснулла бу өйне мәдрәсә буларак файдалана, ә үзе кеше фатирында яши башлый. Моның өстенә, Әхмәдһади Максудиның 50 данә «Мөгаллим әүвәл» китабын үз хисабына сатып алып, шәкертләренә тарата.

Җәдиди мәдрәсәгә шул елның көзендә үк 80 шәкерт кабул ителә. Бирегә, дин дәресләреннән тыш, тарих, җәгърафия (география), хисап һәм табигать фәннәреннән дә белем бирелә. Хөснулла хәзрәтнең шәкерте Харис абзый Галимов сөйләп калдырганнарга караганда, уку йортына шул заман өчен яңа күренеш дип саналган өстәлурындыклар, кара такта һәм акбур, тарих, география карталары кертелә.

Шулай бер көнне кара такта куллана, балаларны тәре ясарга өйрәтә (хисап фәнендәге плюс билгесе), диннән биздерә, дип, мөгаллим өстеннән кадими картлар шикаять яза. Дүрт айдан соң Богорыслан өязеннән килгән исправник мәдрәсәдә укыту яхшы икәнен әйтә, әмма мөгаллим булу өчен имам да булуы кирәк, дигән шарт куя. Нәтиҗәдә, авыл халкы Хөснулланы яңа гына салынган өченче мәхәллә мәчетенә имам-хатыйп итеп сайлап куя. Нибары ике кыш укыган шәкертләрнең тиз арада укырга-язарга өйрәнүенә ата-аналар таң кала.

1891 елда Ризаэддин Фәхреддинне Уфага казый итеп эшкә алалар. Шул елларда булса кирәк, Хөснулла хәзрәт, Диния нәзарәтенә барып, мөфти Мөхәммәдьяр Солтанов, казыйлар Гыйниятулла Капкаев, Ризаэддин Фәхреддин, Хәсәнгата Габәшиләр хозурында имтихан тапшыра һәм имам-хатыйп, мөдәррис шәһадәтнамәсе ала. Алга китеп булса да шуны әйтик: 1912 елда Хөснулла хәзрәткә ахун дәрәҗәсе дә бирелә.

1893 елда Хөснулла хәзрәт Иске Ярмәк мәдрәсәсенә янкорма – таштан ашханә салдыра һәм аш пешерү өчен 5-6 казан куйдыра. Мәдрәсәдә укучылар авылның җәмәгать эшләрендә дә катнаша башлый. Бу елларда Хөснулла ахун мәдрәсәсе Оренбург һәм Самара губерналарында иң алдынгылардан санала. Бирегә укырга Әсәкәй, Богорыслан, Иске Мәчәләй авылларыннан аеруча күп килгәннәр. 1903 елда Хөснулла хәзрәт хатын-кызлар өчен дә мәктәп салдыра. 1910-1911 елларда мәдрәсәдә рус классы ачыла. Ахунның олы улы Габделхәмитнең, Богорысланнан укытучы шәһадәтнамәсе алып кайтып, мәдрәсәдә рус теле укыта башлавы авыл мәгарифенә яңа сулыш өрә. 1912-1913 елларда уку йорты земство карамагына күчә, хөкүмәт биредә эшләүчеләргә

хезмәт хакы түли башлый. Эшләү чорында, мәдрәсә йөзләп имам һәм мәзин, 150-200ләп мөгаллим-хәлфә әзерли.

Мәдрәсә ябылганнан соң, хәзрәтнең иллеләп укучысы төрле төбәкләргә таралып, совет оешмаларында бухгалтер, счетовод, кассир, район башкарма комитеты белгечләре булып хезмәт куя. Райком секретаре Зөфәр Ганиев, язучы Халикъ Садри, профессор, политэкономия укытучысы Шәһит Җәләевләр – Хөснулла ахун шәкертләре.

ХӨСНУЛЛА АХУН – ГАМӘЛЕ БЕЛӘН ОСТАЗ ШӘХЕС

Хөснулла хәзрәт авыл халкының хуҗалык, көнкүреш эшләренә зур яңалыклар алып килә. Элегрәк игенчеләр арыш, арпа, тары, борай иксә, хәзрәттән күреп, йомшак сортлы бодай да чәчә башлыйлар. Шуның өстенә, Иске Ярмәк халкы, югары уңыш бирә торган бу бодайны күрше-тирә авылларга да сатып, табыш ала. Алар, бик канәгатьләнеп: «Безнең Ярмәк кырларыннан алтын чыга», – дип, горурланып сөйли торган була. Нурҗиһан абыстай исә хатын-кызларны бодай онынннан ак күмәч һәм бавырсак пешерергә өйрәтә. Хөснулла ахунда яшәүче асрау кыз авылда иң оста бавырсак пешерүче булып таныла.

1889 елда Иске Ярмәк авылында 238 йорт була, шунда 1329 кеше яши. 1890 елның 19 апрелендә – язгы сабанга чыккан көннәрдә 120 йорт яна. Йортлар, әлбәттә, бурадан салынып, түбәсе салам белән ябылган була. Шушы коточкыч хәлдән соң, Хөснулла хәзрәт янгынга бирешмәслек – диварларына балчык аралаш ком, вак таш, шлак кушып, иңе 9 м 20 см, буе 16 м 50 см озынлыктагы өй сала. Фундаментка тау ташларын 1 м 20 см киңлектә түшәп, өй диварын 60 см калынлыкта эшләтә. Хәзерге көндә сәүдәгәрләрнең кирпечтән салган йортлары сүтелеп бетсә дә, Хөснулла хәзрәт төзеткән йорт саклана. Аңа кадәр авыл халкы йортны өмә ясап күтәрә, Хөснулла хәзрәт, беренчеләрдән булып, эш хакын акчалата түли.

Әлбәттә, зур хуҗалыктагы эшләрне хәзрәт белән абыстай үзләре генә алып бармаган. Кунакчыл, заманы өчен мәгърифәт үзәгенә әйләнгән әлеге йортта, Денис авылыннан килеп, Харшидә әби белән Әһлиулла бабай Гарифуллиннар хезмәт иткән. Харшидә әби, оныгы Кәримә апа биргән мәгълүматларга караганда, көненә 18 мәртәбә самовар куя торган була. Табынны шулай еш әзерләү йортка киңәш сорап яки кунак булып килүчеләрнең күплеге хакында сөйли. Шул исәптән, хезмәтчеләр дә гаилә әгъзалары, хәзрәт һәм абыстай, аларның балалары белән бер табын артына утырып, сый-нигъмәттән авыз иткән.

Йорт салыр өчен урман ерак һәм кыйммәт, ә янгын хәвефе тагын кабатлану ихтималы булу сәбәпле, Хөснулла хәзрәт ярмәклеләрне саман кирпеч сугып өй салырга өйрәтә. Саман кирпечтән мәдрәсә дә төзетеп куя. Соңрак, Сок елгасы буенда кызыл балчыктан сугылган кирпечне утта яндыра торган кечкенә завод та булдыра. Кызганыч, Беренче Бөтендөнья сугышы башлану белән, кызыл кирпечкә ихтыяҗ кими, завод та эшләүдән туктый һәм инде яңадан тернәкләнеп китә алмый.

Хөснулла хәзрәт авылдагы гореф-гадәтләргә дә йогынты ясый. Элек егет белән кызның очрашуы зур гаеп саналып, аларны эләктерә калсалар, йөзләренә көл ягып, кулларын бәйләп, урамның бер башыннан икенче тарафына йөртү йоласы булган. Аларны озатып баручы халык «кара йөзләр»гә таш аткан, төрле мәсхәрәле сүзләре кычкырган... Еш кына әлеге хурлау мәрәсимен «мәхәббәт өчпочмагы»нда үзен кимсетелгән дип санаган, ягъни кыз тарафыннан кире кагылган егет туплаган төркем оештырган. Хөснулла ахун бу гадәт белән дә көрәш башлый, вәгазь кыла, тыя-кисәтә... Ул урамда күренү белән, мәсхәрә кылучылар шунда ук тарала торган була.

Хөснулла ахун һәм Нурҗиһан абыстай кызлары Кәримә белән

Хөснулла хәзрәт авыл халкын төрле нахаклардан яклаучы да булган. Моңа аның газетада җавап буларак басылып чыккан бер хәбәре дәлил: *«Вакыт»ның 108 нче номерында өяземездә булган Ярмәк авыл халкын яманлап бер мәктүб дәреҗ ителмештер (хат басылды). Бу мәктүбтә язылмыш шәйләр дөрест дәгелдер. Бу карья халыклары йирләрен иҗарәгә (арендага) вирмәй (бирми), үзләре сачәләр. Һәр йортта*

икешәр тимер сабан бар, ындырларда иске кибәннәр күп. Үзләренең өч җамигъларын (мәчетләрен) үзләренең байлыклары илә бина иттеләр (төзеделәр) вә буның өчен дә 12 мең сум мәсъраф (акча) тоттылар. Ярмәктә ошбу кадәр гәзитә алынып укылынып: ике «Тәрҗеман», өч «Вакыт», өч «Өлфәт», бер «Казан мөхбире», бер «Йолдыз», бер «Азат халык», бер «Фикер», бер «Таң», бер «Санкт-Петербург», «Сельский вестник». Бәзем (безнең) волостьта 7 гадед (данә) «Вакыт» алыныр, шуның өчен, әгәр дә бу сүзем хата булса, хатамны бәян итеп, «Вакыт»та язсыннар. Ахун Баһаветдин углы».

XIX гасыр дәвамында төбәктәге күпчелек татар авыллары Байтуган волостена караса, Иске Ярмәк исә мордвалар күпләп яши торган Иске Сосна волостена кергән. Рус телен камил белгән Хөснулла ахун 1897 елда үткәрелгән халык санын алу вакытында Вескан, Байтуган, Иске Сосна волостьларында оештыручы-инструктор булып эшли. Нәтиҗәдә, төбәктә халык санын алу эше шактый уңышлы һәм тыныч шартларда уза. Шул елда ук, Хөснулла ахунның тырышлыгы белән, Иске Ярмәк авылы татарлар күпләп яши торган Байтуган волосте карамагына күчә.

Хөснулла ахунның мәгълүм сәбәпләр аркасында гамәлгә ашмаган проектлары да кала. Мәсәлән, хөкүмәт хисабына 16 мең сумга төшәчәк (сыер бәясе 3 сум) земство мәктәбенә рөхсәт алса да, уку йорты төзелми. Аңа каршы килүчеләр: «Әгәр дә бу мәктәп була калса, балалар руслашачак һәм халык динсез калачак», – дип әйтә. Сок елгасы аша земство хисабына салыначак күпер дә хыялда гына кала. Каршы тарафтагылар фикеренчә, күпер төзелсә, күрше Дубино авылындагы руслар Ярмәккә ешрак киләчәк, имеш.

Хөснулла ахун заманының акыллы, укымышлы имамнарыннан санала, газета-журналлар алдырып укый. Аеруча, Оренбургта сабакташы Ризаэддин Фәхреддин чыгара торган «Шура» журналы һәм Фатих Кәрими мөхәррирлегендә дөнья күргән «Вакыт» белән даими танышкан. Үзе дә вакытлы матбугат битләрендә мәкалә-хәбәрләр бастыргалап, мәшһүр имам-голәмәләр белән аралашып яшәгән. Бу уңайдан, дусты Гыйльман ахун вафатыннан соң, аның углы, мөхәррир һәм язучы Фәтих Кәримигә җибәргән кайгынамәсе игътибарга лаек. Хат 1906 елда «Вакыт» газетасында басылган.

«Хөрмәтле Мөхәммәдфатих әфәнде – Сезгә Богорыслан өязе Иске Ярмәктә имам вә ахунд Хөснулла Баһаветдин углыннан.

Богорыслан шәһәрендә имам Мөхәммәдгариф әфәндегә йибәрелмеш намәңезгә юлыгып, әткәгез Гыйльман ахун хәзрәтләренең дарелбәкая рихләт әйләдекен (вафат булуын) ишеттек. Рәхмәтулла галәйһи.

Бу сөекле дустымның вафатына гаять кайгырдык. Буның кеби бөек голәмәләремезнең гомере кыска булмакы безләргә көенеч өстенә көенеч булды. Сезләрнең ятим калдыкыңыз читтә торсын, безнең моталәгамезчә (уйлавыбызча), җөмлә голәмәләремез (барча укымышлыларыбыз) ятим калды, дип хөкем итәмез. Алар өчен бу хөрмәтле затымыз шундаен кемсәнәләрдән иде. Бик хөрмәтле вә тугры сүзле, һичбер риясыз вә һичкемнән өркемәеп, курыкмаеп, тугры вә хак сүзне агызыннан җәүһәр вә энҗе кеби сачәр затлардан иде.

Ислам дине өчен вә ислам кардәшләремез өчен, вә ислам кардәшләремезнең фәкыйрьлекләренә вә косурлы (кимчелекле) урыннарына моның кеби кайгырган затны нә голәмәдән вә нә дә имам вә остазлардан һич күрмәдем вә ишетмәдем.

Моннан Оренбург шәһәренә киттеке соңында күрешә алмадым. Монысы безләрдән зур косур (кимчелек). Сезләрне аның варис хакыйкыйсы белеп, Сездән истигъфар (гафу) вә игътизар (үтенү) кылабыз. Иншаллаһ, зиярәтенә барачакмыз. Җомга кич, июнь алтысында вафат улыб, җомга көн гүр иясе уларак, шәһадәт савабына васыйль

улмыш (ирешүче) икән. Бу кемсәнәгә хәер-дога әйләмәккә гомеремезнең ахырына кадәр бурычлымыз.

Богорыслан өязе Иске Ярмәк карьясендә (авылында) ахун вә мөдәррис Хөснулла Баһаветдин углы. 24 нче июньдә, 1906 нчы сәнә».

КИҢӘШЛЕ ЭШ – ТАРКАЛМАС!

Хөснулла янына еш кына киңәш сорап та килгәннәр. 1914 елда башланган Беренче Бөтендөнья сугышына карата ул тискәре мөнәсәбәтен белдерә, халыкның кан коюына бик борчыла. Олы улы, мөгаллим Габделхәмитне дә башка авылдашлары белән фронтка озатырга мәҗбүр була. Ул анда өч мәртәбә яраланып, 1918 елның 1 февралендә генә Иске Ярмәккә кайта.

Әүвәлгеләр сөйләвенә караганда, Хөснулла хәзрәт патша режимына да каршылык белдерә. Авылга Февраль революциясе турындагы хәбәр килеп ирешү белән, үз мәдрәсәсе диварында эленеп торган Николай II портретын идәнгә атып бәрә һәм аяклары белән таптый. «Җитәр инде син мәлгуньгә кан коярга!» – дип, нәфрәтен белдерә.

Октябрь революциясе турындагы хәбәр килеп ирешкәч тә гади халыкны тынычландыра: «Илдәге үзгәрешләр бәхет алып киләчәк, хәерчеләр бетәчәк, большевиклар зыян китермәс!» – дип сөйли торган була. Яңа хакимиятнең уңай якларын гына күрергә өнди. Хәтта большевиклар тарафыннан мәдрәсәне ябуны да тыныч кабул итә.

Хөснулла ахун Гражданнар сугышы чорында да төшенкелеккә бирелми. Бөгелмә өязендә көчәйгән сәнәкчеләр, үзләренә иярченнәр эзләп, Камышлы тарафына вәкилләр җибәрә. Камышлы картлары, ризалык бирү алдыннан, берничә егетне Хөснулла ахун янына җибәрәләр. Ахун исә аларга совет хөкүмәтенең өч уңай ягын атый: «Крестьянга 22 дистинә җир бирде; бөтен ятим-ябаганы үз канаты астына алып, приют, балалар йортлары булдырды; гыйлеме булмаган бар халыкны парта артына кертеп утыртты», – ди. «Менә шушы чараларга каршы сезнең җитәкчеләрегез нинди лозунг белән халыкка мөрәҗәгать итәргә уйлый?» – дип сорау да бирә. Әлбәттә, вәкилләр моңа җавап кайтара алмый. Нәтиҗәдә, камышлылар сәнәкчеләр хәрәкәтенә кушылмый һәм мәгънәсез кан коюлардан котылып кала.

Хөснулла хәзрәт Иске Ярмәктә дуңгыз фермасы һәм аракы кибете ачтыруга да каршылык белдерә. Ул Богорыслан шәһәренә киткәч кенә, аның китүеннән файдаланып, мәкерле максатларына ирешәләр. Хәзрәт ачлык елларында фәкыйрьләргә төшке аш ашатуны да оештыра. Юкәле тау агачларын халык утынга ягар өчен кисәргә тотынгач та, тимәгез, биредә тарихи урын, изгеләр тавы, дип, пычкы, балта белән менүчеләрне туктата. Шулай итеп, әлеге тарихи һәм табигый һәйкәл хәзерге көнгәчә сакланып кала.

БОГОРЫСЛАН, ЯНӘДӘН ЯРМӘК…

1918 елда хәзрәт Уфа шәһәрендәге Милләт мәҗлесендә Богорыслан өязе вәкиле буларак катнаша. Революциядән соң мәдрәсәсе ябылгач, 1922 елда каенесе, ахун Гариф Хөснетдинов (Ризаэддин Фәхреддиннең туганнан туган энесе) Франциягә күченү сәбәпле, Богорысланга укытырга китә. Үз йортын, медпункт ясагыз, дип, авыл советына гариза язып калдыра. Әмма аңа Богорысланда мәдрәсә оештырып җибәрү насыйп булмый, 1927 елда хәзрәтне Оренбург каласына чакырып, имамлык хезмәтеннән үзе теләп баш тартуы хакында гариза яздыралар. Шул көннәрдә ул ашханәдә күренекле галим, язучы, Галимҗан Ибраһимов белән очраша. Язучы аннан:

«Хәзрәт, син бик гыйлемле шәхес, ни эшләргә ниятең инде хәзер, бәлки яңа властька хезмәткә керерсең?» – дип сорый. Хөснулла ахун олуг әдипкә болай дип җавап бирә: «Юк инде, Галимҗан! Мин җитмеш ел дәверемдә бер юлдан барган килеш икенче юлга баса алмыйм инде. Аллаһы Тәгалә үземне дә, гаиләмне дә ярдәмсез калдырмас әле!»

Дөрестән дә, Хөснулла ахун һәм аның гаиләсе әллә ни фәкыйрьлеккә дә, башка имамнар кебек репрессия хәвефенә дә дучар булмый. 1928 елда ул янәдән Иске Ярмәккә кайта. Җирле хакимият аңа үз йортында яшәргә рөхсәт бирмәү сәбәпле, ахун Ярый Әхмәтҗановның саман кирпеч өендә яши.

Камышлы төбәгендә 1930 нчы елларда колхозлар тиз генә оешып китә алмый. Иске Ярмәктәге Бауман исемендәге колхоз да, тирә-як авыллардагылары да озак тормый, таркала. Коммунистлар күпме генә тырышсалар да, эшне оештырып җибәрә алмый һәм... моның сәбәбен Хөснулла хәзрәттән күрәләр. «Бездә ахун тора, шуңа халык колхозга керми», – дигән сылтау уйлап табалар. Прокурор, хәзрәтнең өенә килеп өч сәгатьтән артык сөйләшкәннән соң, Хөснулла ахунга халык белән аралашуны чикләү турындагы карар чыгара.

***

Хөснулла Баһаветдин углы 1937 елда 80 яшен тутырып бакый дөньяга күчә. Җәсәде Иске Ярмәк авылы каберстанында, 1935 елда 65 яшендә вафат булган хатыны янәшәсенә җирләнә.

Хөснулла ахун һәм Нурҗиһан абыстайның **Габделхәмит (1895-1970), Исхак (1897-1934), Исмәгыйль (1902-1979), Рәшит (1906-1969), Сәгыйть (1918-1941)** исемле угыллары була. Габделхәмит, Исхак, Рәшит әтиләре һөнәрен дәвам итеп, укытучы, мәктәп директоры булып эшли. Кызлары **Кәримә (1909-1983)** Ташкентта татар газетасы хезмәткәре Рәхмәт Чурагуловка кияүгә чыгып, өч ир һәм ике кыз бала үстерә.

Бу нәсел кешеләре арасында галимнәр дә бар. Мәсәлән, Исмәгыйльнең кызы **Рәя Байкова** – философия фәннәре кандидаты, Габделхәмитнең оныгы **Рөстәм Туйкин** – тарих фәннәре кандидаты, торыны **Булат Хәмитов** – авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты, Кәримәнең улы **Булат Чурагулов** М.Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университеты профессоры, химия фәннәре докторы дәрәҗәсенә ирешә.

Дин әһеленең йорты совет чорында халыкка хезмәт итүен дәвам итә. Анда колхоз идарәсе, ачлык елларда ятим калган балаларны тукландыру пункты, даруханә, соңрак госпиталь, мәктәп урнаша. 1989 елда бу йортны Хөснулла ахунның торыны Булат Хәмитов, җирле хакимияттән ике «Жигули» маркалы машиналык хак түләп, сатып ала һәм хосусыйлаштыра.

Заманында Иске Ярмәк, тирә-як авыллар халкын аңлы-мәгърифәтле иткән, үзләренең гадилеге, самимилеге, балаларны нык яратуы белән һәрвакыт изгелек эшләргә омтылган инсаннарның җаны мәңгелек җәннәттә булса иде. Һәммәбез дә намаз саен аларны яхшы гамәлләре белән искә алып, рухларына дога кылырга бурычлыбыз.

Мәкаләне басмага
Габдулла хәзрәт Мөхәммәдкәрим,
***Булат Хәмитов** һәм **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Рафаэль БАҺАВЕТДИНОВ: *«Без рухи-әхлакый хәзинәләрне сакларга тиеш!»*

Камышлы районы 1991 елның мартында күршедәге Келәүле районыннан аерылып чыккан. Районда 10912 кеше яшәсә, шуның 80 проценттан артыгы татар милләтеннән, аннан кала руслар – 9,3 процентны тәшкил итә һәм чуашлар – 5,1 процент.

БАЙ ТАРИХЛЫ КАМЫШЛЫ

Тарихчылар әйтүенчә, Камышлы районындагы иң борынгы авыл Татар Байтуганына 1533 елда Казан ханлыгының көньяк-көнчыгыштагы биләмәләрен ныгыту һәм тынычлыгын тәэмин итү өчен хан тарафыннан җибәрелгән старшина Ярмөхәммәд Туйбакты тарафыннан нигез салынган. Ә Камышлы авылына 1580 елда хәзерге Башкортстаннан күчеп киләләр. Элегрәк Сок елгасы үзәнлегендә сазлык булган, камышлар да күп үскән. Район гербында тикмәгә генә камыш сурәтләнмәгән инде. Иске Ярмәккә 1737 елда нигез салына. Бирегә Уфа, Казан һәм Пенза губерналарыннан 12 гаилә күчеп килә. XVIII гасыр азагында авылда татарлар белән бергә гарәп, башкорт, чуаш, хәтта поляклар да яши. 1781 елда Иске Ярмәктән ике гаилә Сок елгасының каршы ярына күчеп төпләнгәннән соң, Яңа Ярмәк авылы барлыкка килә. Балыклы авылына 1733 елда Казан губернасының Арча өязеннән күчеп килгәннәр, диләр.

Галимнәр Камышлы районында 21 археологик ядкяр барлыгын ачыклаган. Байтуган һәм Камышлы авыллары урынында безнең эрага кадәр II меңьеллыкта ук кеше яшәгән, дип санала. Алар үзләреннән бай археологик мирас калдырып киткән. Иске Ярмәк, Яңа Ярмәк, Чулпан һәм Яңа Усман авылларында да курган-каберлекләр бар.

Рафаэль Камил улы Баһаветдинов – Самара өлкәсенең Камышлы муниципаль район хакимияте башлыгы

Яңа Усман авылындагы күкертле водород (сероводород) скважинасы, Камышлы «Мацеста»сы, Шарлак һәм Озын Тау чишмәләре, Аю коесы, Каратал-Чагылы тавы, Яңа Усмандагы ташландык карьер, Кызыл Ярдагы имәнлек, Камышлы карурманы, табигать һәйкәле буларак, дәүләт тарафыннан саклана. Иске Ярмәктәге Юкәле Тау борынгыдан изге урын булып саналып килсә дә, аның түбәсендә Сабан туйлары уздыру гадәте бар иде. Аллага шөкер, берничә ел инде бу бәйрәм хәзер башка җирдә үткәрелә, Юкәле Тау артында агачлар утыртылды. Авыл халкы Татарстанның Лениногорск районындагы Керкәле авылыннан берәр тоннадан артык авырлыктагы дүрт яссы таш алып кайтып, аларны кабер ташы рәвешендә шул изге җиргә урнаштырды, төрле сугышларда корбан булган борынгы бабаларга багышлап истәлек язулы мәрмәр такта куелды. Хәзер анда, изгеләр хөрмәтенә һәм ата-бабаларга багышлап, корбаннар чалына, Коръән укыла.

Гомумән, төбәктәге кайсы гына калкулыкны, елга үзәнен, камышлыкларны, өч йөзәр еллык нарат урманнарын, имәнлекләрне, чишмәләрне алма – алар барысы да кешелекнең бай тарихы белән үрелгән гүзәл табигать һәйкәлләре. Мондый матур табигатьтә яшәгән кешеләрнең дә күңеле саф һәм иҗади яктан бай булырга тиеш.

***

Камышлы – Самара өлкәсендә үзгә район. Беренчедән, ул өлкә күләмендә татарлар тупланып яши торган бердәнбер төбәк. Икенчедән, өлкәдә иң озын гомерлеләр безнең районда. Милләттәшләребез тәртипле тормыш алып бара, моңа тел, гореф-гадәт, дин дә йогынты ясый. Шунлыктан, башка районнар белән чагыштырганда, бездә 90 яшьтән узган әби-бабайлар күбрәк. Өченчедән, биредә татарларның шактый үзгә, традицион мәдәнияте бар. «Дисәнә», «Чишмә» фольклор, «Наз», «Серпантин» бию, «Кояшкай» вокаль төркемнәре, Камышлы халык театры, «Ак каен» фольклор халык ансамбле һәм аның балалар төркеме генә дә ни тора! Язучы һәм инженер **Габделхаликъ Садри**, шагыйрьләр **Әнвәр Давыдов, Зыя Ярмәки** һәм **Рөстәм Мингалим**, «Әлифба» китабының авторы **Сәләй Вәгыйзов**, гармуннар ясау остасы **Гали Гәрәев**, Рейхстагка Җиңү байрагы кадаган **Миргасыйм Габидуллин**, мәшһүр юмористыбыз **Рәшит Шамкай** кебек шәхесләр Камышлыны бөтен татар дөньясына танытты.

«ЯФРАКЛАРЫ ЯШЕЛ АК КАЕННЫҢ...»

«Ак каен» халык фольклор ансамбле 1970 елда Иске Ярмәктә оеша. Аның исеме үк җырлап тора – «Яфраклары яшел ак каенның...» Якташыбыз Зыя Ярмәкинең бу шигъри юлларын белмәгән татар баласы бик сирәктер, мөгаен. Иҗади төркемнең башында Гамил һәм Гөлсинә Галиуллиннар, Альберт һәм Мәрьям Мифтиевлар, Тәбрис Вәлиәхмәтов, Румия Юсупова кебек талантлы һәвәскәрләребез тора. Соңрак аларга Наил һәм Оркыя Галимуллиннар, Әсгать һәм Сәрия Сәгыйровлар, Әлфия һәм Мөхтәр Баһаветдиновлар килеп кушыла. Ансамбльне озак еллар дәвамында Фәния Гайсина җитәкли. 1989 елда аңа «халык ансамбле» статусы бирелә. Хәзерге вакытта Динар Гарипов, Роза Маслахова, Линар Хәйруллин, Илфат Абдрауфов кебек талантларыбыз – ансамбльнең йөзек кашы.

«Ак каен» тарафыннан менә ничә еллар инде «Нәүрүз», «Сабан туе», «Кич утыру», «Печән өмәсе», «Сөмбелә», «Туй уйнату», «Никрутка озату», «Боз озату», «Сагыз кайнату» кебек традицион йола күренешләре сәхнәләштерелә. Күп йола һәм гореф-гадәтләр элекке әби-бабалардан язып алынган истәлек-хатирәләр нигезендә яңартылып башкарыла. Ансамбльнең төрле төбәкләргә гастрольләрен, «Түгәрәк уен» Бөтенроссия татар фольклор фестивальләрендә һәм халыкара бәйгеләрдә ирешкән

«Ак каен» ансамбле башкаруында «Ярмәк вагы» биюе

казанышларын саный китсәк, бик озакка сузылыр иде. 2013 елда ансамбльнең җитәкчесе Наил Галимуллин өлкә губернаторының «Профессионал года» дипломына һәм премиясенә лаек булды.

Гомумән, «Ак каен», аның уникаль «Ярмәк вагы» биюе – безнең генә түгел, ә бөтен татар халкының горурлыгы! «Ярмәк вагы»н «Никрутлар биюе» дип тә атап йөрткәннәр. Егетләрне, патша хезмәтенә китәр алдыннан, җитезлекләрен тикшерер өчен, камчы аша сикертә торган булганнар. Әлеге бию шуннан барлыкка килгән, дигән фикер бар. Хәзерге вакытта «Ярмәк вагы» Гали Гәрәев ясаган гармунда Әсгать Сәгыйров уйнаган көйгә башкарыла. Районда нинди генә бәйрәм үткәрелмәсен, аның азагы «Ярмәк вагы» биюе белән бетә. Элегрәк, һәр авылда да диярлек, төрле

«Ак каен» ансамбле җитәкчесе Наил Галимуллин

мәҗлесләр вакытында тәнәфескә чыккач, «Ярмәккә типтерү» булган. Хәзерге вакытта «вак бию» татар дөньясына таралды. Хәтта Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле артистлары да өйрәнеп, үз репертуарларына кертте, әмма алар аны ярмәклеләр кебек дөрес итеп башкара алмыйлар.

Атаклы гармуннар ясау остасы, Иске Ярмәктә яшәгән Гали Гәрәев истәлегенә багышлап оештырылган «Уйнагыз, Гали гармуннары!» төбәкара фестивален үткәрүдә дә «Ак каен»ның роле зур. Рөстәм Вәлиевнең Гөлшат Зәйнашева сүзләренә иҗат ителгән «Самара, Камышлы, Ярмәк...», Фәтхерахман Әхмәдиев белән Абдулла Сәләхетдиновлар язган «Ярмәк вальсы» да алар башкаруында киң танылу алды. Фольклор ансамбле – үткәнне хәзерге буынга кайтарып бирү дигән сүз. Бу юнәлештә армый-талмый хезмәт итә торган ансамбль оешуга киләсе елда 50 ел тулачак.

100 ЕЛЛЫК АВЫЛ ТЕАТРЫ

Камышлы халык театры – безнең тагын бер олы горурлыгыбыз! Быел ул 98 нче сезонын ачты. Тиздән аның 100 еллыгы! Гомумән, татар дөньясында театрлар күп, әмма район җирлекләрендә мондый бай тарихлы иҗат коллективлары бармак белән генә санарлык.

1920 нче елларда Камышлы үзешчәннәре үзләре үк язган «Серле шалаш» исемле әсәрне мәктәптә сәхнәләштергән. Бу елларда кечкенә генә мәктәп бинасына тамашаны карарга килүчеләр сыймый да калган, дип сөйлиләр. Спектакль кабат-кабат куелган. Аннары «труппа» күрше авылларга «гастрольләр туры»на киткән. Менә шулай итеп, Камышлыда халык театрына нигез салынган. Бу эшләр авыр ачлык, хуҗалыкларны күмәкләштерү, репрессия шартларында барган, шулай да халык театрга, сәхнәгә омтылган. Хәтта Бөек Ватан сугышы чорында да артистлар эшчәнлекләрен туктатмаган, халыкның күңелен күтәргән.

1970 елда, Әнгам Атнабаевның Бөек Җиңүнең 25 еллыгы уңаеннан сәхнәләштерелгән «Ул кайтты» исемле әсәре театрга зур уңыш китерә. Театр шуның белән СССР күләмендә таныла башлый, фестивальләрдә бер-бер артлы казанышларга ирешә. Ә 1972 елда иҗат коллективына «үзешчән халык театры» исеме бирелә. Бу вакытта театрның режиссеры булып Камышлы хастаханәсенең баш табибы Атлас Тухбатов эшли. Камышлы үзешчән халык театрының шуннан соңгы уңышлары са-

«Минем җинаятем» спектакленнән (Юныс Әминов әсәре) бер күренеш

«Карт гашыйк» спектакленнән (Сәет Шәкүров) бер күренеш. 1978 ел

нап бетергесез күп. Алар татар драматургиясенең барлык классиклары әсәрләрен дә сәхнәгә куйды, дип әйтсәм, ялгышмамдыр, мөгаен. 1997 елдан театрга Гүзәлия Шакирова җитәкчелек итә. Камышлы халык театрының 2015 елда 95 еллыгын зурлап билгеләп үткән идек, хәзер исә, 100 еллыгына әзерләнәбез.

БЕЛЕМ «ӘЛИФБА»ДАН БАШЛАНА

2016 елда Татар Байтуганы авылында бар гомерен татар теле белеме, аны укыту методикасы үсешенә багышлаган, гыйлемнең тәүге ачкычы булган «Әлифба»ны иҗат иткән мөхтәрәм шәхес, Арча педучилищесы мөгаллиме Сәләй ага Вәгыйзовның

Сәләй Вәгыйзов музее. Татар Байтуганы авылы

Мөхтәсиб һәм төбәк тарихын өйрәнүче Габдулла хәзрәт Мөхәммәдкәримов

Камышлы авылы күренеше

истәлегенә музей-комплекс ачылды. Музейны оештыруда һәм хәзер аның төбәк тарихын өйрәнү, тәрбия үзәгенә әйләнүендә Нурания ханым Абзалованың роле зур. Экспонатлар туплаган вакытта Г.Тукай исемендәге Арча педагогика көллиятенең, Сәләй аганың улы Камил абыйның ярдәме чиксез булды. Матди ягын тәэмин иткәне өчен, Татарстан хөкүмәтенә, ТР Президенты Рөстәм Миңнехановка рәхмәтлебез.

Әлеге музей оешканчы, Сәләй Вәгыйзовның Татар Байтуганыннан булуын, аның фәнни-иҗади эшчәнлеген юньләп белүче дә сирәк иде. Хәзер исә яшь буынны олуг педагог рухында, аның үрнәгендә тәрбияләргә бөтен мөмкинлекләр дә бар. Без рухи-әхлакый хәзинәләрне сакларга һәм тагын да арттырырга тиеш. Киләчәк буыннар алдындагы изге бурычыбыз бу. Ә Сәләй Вәгыйзов белән без – Камышлы төбәге халкы горурланабыз. Горурланмаслык та түгел: хатыны Рәмзия ханым Вәлитова белән язган «Әлифба» китабы 40 мәртәбә меңнәрчә тираж белән басылган. Хәзерге көндә балалар башка «Әлифба»лардан укыса да, мөхтәрәм якташыбыз язганы иң камилләрдән, дип санала. Мондый дәрәҗәгә ирешкән татар китабы тагын бармы икән?! Сәләй аганың китабын укып үскән татар балалары чиксез күп. Алар бөтен Россия буйлап сибелгән, шуңа күрә дә музейга килүчеләрнең саны елдан-ел артыр, дип уйлыйм.

***

Электән үк районда халык үз телен, динен, гореф-гадәтләрен саклап, берләшеп яшәгән, актив тормыш алып барган. Аллага шөкер, һәр мәктәптә дә татар теле укытыла. Районда 13 мәчет эшли. Шуның өчесе – Камышлыда. Камышлы һәм Иске Ярмәк авылларындагы мәдрәсәләргә йөрүче балалар дин сабагын да өйрәнә. Мөхтәсибебез **Габдулла хәзрәт Мөхәммәдкәримов** – Иске Ярмәкнең мәгърифәтчесе, имам-хатыйп, мөдәррис, төбәк тарихын өйрәнүче, халык ансамбле артисты һәм күп балалы гаилә башлыгы да... Гомумән, талантлы, булдыклы имам ул!

Камышлы – авыл хуҗалыгы районы. Мин бирედә эшли башлаганда – 2000 нче еллар башында колхозлар таркалып беткән иде, хәзер исә фермер хуҗалыклары аякка басып килә. Киләчәктә авыл хуҗалыгы кооперативлары оештырып, барлык фермерларны берләштереп, сәүдә урыннары ачарга һәм җитештергән азык-төлекне шуның аша сатарга ниятлибез.

Район үзәге Камышлыда 2013 елдан Өлкә авыл Сабан туен оештыру традициясе бар иде. Быел исә бирედә, ямьле Сок елгасы буенда Бөтенроссия авыл Сабан туе узачак. Бәйрәм көнендә ТР Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов һәм Самара өлкәсе губернаторы Дмитрий Игоревич Азаров катнашында шагыйрь, тәрҗемәче һәм журналист, ТАССР Язучылар берлегенең җаваплы сәркатибе булып эшләгән Әнвәр Давыдов бюстын ачарга уйлыйбыз. Сабан туена 50 меңләп кунак көтелә. Камышлы ул – татарлар яши торган үзәк җир: Оренбург, Ульяновск, Татарстан, Башкортстан күршедә генә. Җаек, Саратов, Пенза төбәкләрендә яшәүче милләттәшләребез дә бездән әллә ни ерак түгел. ■

Безнең мирас №6 июнь 2019

Әйт, авылым, кайда соң моң?

Эльмира Шәвәлиева

Гомәр, Госман, Гали, Шакирә, Мәймүнә, Нурсәхи, Кәримә, Әминә, Нурсалих – болар XX гасыр башында Камышлы районының Иске Ярмәк авылында яшәгән Әбүбәкер һәм Бисал Гәрәевләр гаиләсендә туган тугыз баланың исемнәре. Шуларның бары тик өченчесенә – 1912 елның 24 июлендә туган Галигә генә татар тарихына кереп калырга насыйп була.



Гали Гәрәев үзенең остаханәсендә

Бу баланы, бик моңлы булып үскәнгәдерме, әллә кәсепле булсын өченме, элеккеге Мәтеби, хәзерге Иске Усман авылында яшәүче тальян гармуннар ясау остасы Җаниәхмәткә өйрәнчеклеккә бирәләр. Шулай итеп, бала 12 яшеннән гармун ясау нечкәлекләренә өйрәнә башлый һәм ике ел эчендә һөнәр иясе була.

Егет Мәтебинең иң матур кызларының берсенә, Шәяхмәт мулла кызы Минкамалга гашыйк була. Алар Минкамал белән матур гына тормыш корып җибәрәләр.

Камышлыда яшәүче Әкълимә апа Насыйрова Гали белән Минкамалның кушылуын хәтердә болай яңарта: *«Минем әти белән Минкамалның әтисе бертуганнар иде. Гали дә безгә туган тиешле булганга күрә, ул әтиемнән яучы булып баруын сорады. Барды, баруын, тик кызның әтисе аны: «Тормыш башларга йорты гына да булмаган гармунчыга дип кыз үстермәдем мин», – дип борып җибәрә. Ә икенче көнне үзе килеп: «Күпер төбендәге таллыкта иртәнгә кадәр гармун моңланды, бөтен авылны елатты. Яшьләрнең рәнҗеше төшәр, Аллам сакласын. Кызымны, бәхилләп, Галигә кияүгә бирәм», – дип әйтә.*

Минкамал апа белән Гали абый, тормыш авырлыкларына карамастан, бик матур һәм кызыклы гомер кичерделәр. «Гали абый, бик тә шаян кеше иде, моңын гармун телләренә салып калдырды. Гармунын кулына алса, хәтта кошлар да тынып кала иде».

«Гали, зур оста булып танылгач, ясаган 16 телле тальянын миңа да бүләк иткән иде. Мин аны әле дә саклыйм. Заказ буенча ясаган тальян гармуннарының берсен Әндиҗан шәһәрендә күрергә насыйп булды. Шулай ук Америкага, Финляндиягә, Германиягә дә гармуннарын артель аша җибәргәнен беләм», – дип искә ала Әхтәм ага Госамов.

Сугыш башланганда Гали гаиләсе белән Ульяновск шәһәрендәге корал ясау заводында эшли. Аңа тылда калу өчен бронь бирелә һәм ул шунда 1945 елга кадәр хезмәт куя. 1939 елда туган улы Ахъяр, 1943 елда туган Искәндәр кыска гомерле була. Ә 1950 елда туган Мәмдүдә (Ташкентта яши), 1956 елда туган Әсфәндияр (Самарада яши) һәм кече уллары Җәгъфәр (Камышлыда) бүген дә исән-сау.

Сугыштан соң Гали Гәрәев туган авылы Иске Ярмәккә кайта һәм гаиләсе белән берничә ел кеше фатирларында яши. 1960 нчы еллар башында гына авыл уртасында аның өр-яңа өе калкып чыга. Шифер башлы, челтәрле тәрәзәле бу йорт авылда берәү генә булып, күз явын алып тора иде.

Гармун ясау сәләтен югалтмаган ир бөтен вакытын яраткан эшенә багышлый. Ләкин Советлар илендә һәр кеше дә хөкүмәт эшендә булырга тиеш иде бит! Гали Минкамалын Келәүледәге инвалидлар артеленә эшкә урнаштырып һәм үзе дә шунда язылып, тальян гармуннары ясау эшенә ныгытып керешә. Кайбер гармуннарын ул артель аша, икенчеләрен авылдашларына һәм тирә-як авылларда яшәүчеләргә сата. Галинең даны еракларга таралгач, аңа үз гармуннарын почта аша Россиянең төрле почмакларына, хәтта чит илләргә дә җибәрергә туры килә. Уфа шәһәрендә яшәүче бертуганы Нурсәхи аны чимал белән тәэмин итеп тора. Ә Шакирә сеңлесенең улы Наил Гали абзыйсы янында бөтерелә, гармун ясау һөнәре белән кызыксына башлагач, оста аны ярдәмче итеп ала. Егет армия сафларында хезмәт итеп кайткач та, җәйге кыр эшләре тәмамланган араларда, абзыйсына гармуннар ясарга булыша.

1960-1965 елларда тальян гармуны модада иде бит. *«Хатлар аша килгән заказлар күп булса да, ел дәвамында барысы да гармунлы булалар, гармун бер ай эчендә ясалып бетә иде. Нота грамотасын белмәгән Гали абзый, үзе ясаган уен коралының яңгырашын, дөрес көйләнгәнен тикшерү өчен, кояш баешында капка төбенә чыгып утыра да, уйнап җибәрә иде. Димәк, Гали тагын бер гармун ясаганын аңлый иде авыл халкы»*, – дип искә ала бүгенге көндә Иске Ярмәктә яшәүче туганнан туганы Наил абый.

Элек Губерна Думасы депутаты булган Гомәр Вәлитов та бу мизгелләрне

күңелендә саклый: *«Минем әти Гали абыйның өе каршындагы янгын каланчасында авылны янгыннан саклый иде. Оста, яңа гармунын алып чыгып бераз уйнагач: «Зөфәр, тавышы ничек, яхшы яңгырыймы?» – дип сорар иде».*

Әйе, мәгълүм җырдагы кебек, гомерләр бик тиз уза икән шул. Безгә бакча күршесе генә булган Гали абыйның остаханәсенә классташым Әсфәндияргә ияреп минем дә кергәләгәнем булды. Ул вакытларда гармун остасы балаларга тылсымчы булып күренә иде. Чаршау артындагы кечкенә генә почмакта таралып яткан тимер, агач, ситсы кисәкләреннән ничек итеп шундый матур яңгырашлы гармун ясап була да, аның телләренә баскаласаң, ничек итеп шундый гаҗәеп музыка туа? Бу минем өчен әле дә ачылмаган сер булып кала.

Иске Ярмәкнең иң оста гармунчысы Гали Гәрәев

Гомумән, безнең төбәктә яшәүчеләр – тальян гармунга гашыйк кешеләр. Районыбызның һәр авылында кимендә ун гармунчы бар, дисәк тә ялгышмабыз. Бик күп йортта ата-баба истәлеге булып хромка, тальян гармуннары саклана, кайберләрендә хәтта скрипкалар да бар әле. Иске Ярмәк авылының «Ак каен» татар халык фольклор ансамбле, 50 ел эчендә, Россиянең бөтен төбәкләрендә танылган «Ярмәк вагы» биюен Гали гармуны көенә генә башкара. Татарстан Республикасының

Гали Гәрәев тальяны белән җырлап урам әйләнгән мизгел

Гали Гәрәев өенә мемориаль такта кую тантанасы. Рәсемдә: сулда утырган — Әсфәндияр Гали улы Гәрәев

халык, Россиянең атказанган артисты, якташыбыз, мәрхүм Рөстәм Вәлиев, атаклы Гали гармуннары белән иң абруйлы сәхнәләргә чыгып, тальянны дөнья күләмендә дә танытты.

Гали Гәрәев 1976 елның 17 августында бакыйлыкка күчте. Иске Ярмәк авылының «Ак каен» халык ансамбленең музыка җитәкчесе, баянчы, мәрхүм Гамил Галиуллин һәм «Ялкынлы яшьлек» ансамбле җырчысы, Самараның мәдәният-сәнгать институтын тәмамлап, Камышлы районының мәдәният бүлеге җитәкчесе булып эшли башлаган Гөлчәчәк Гайсина (Гатауллина) башлангычы белән, Иске Ярмәктә «Уйнагыз, Гали гармуннары!» фестивале 2000 елдан даими үткәрелеп килә. Аның статусы нинди булганын хәзер тәгаенләп әйтә алмыйм, тик авылга бик күп гармунчыларның Гали гармуннарын күтәреп кайтуларын хәтерлим. Кайберәүләре хәтта икешәр, өчәр гармун алып килгән иде. Берничә дистә гармунчының урам тутырып Гали гармуннарында уйнап барганын, шулай мәдәният йортына да килеп керүләрен, сәхнәгә чыккан һәр гармунчы үз кулындагы гармунның ничек ясалуы яисә кемнәндер сыер бәясенә сатып алынуы турында сөйләгәннәрен, Гали абый турындагы истәлекләре белән уртаклашуларын онытып буламыни?!

Кеше китә, җыры кала, диләр. Бүген Гали Гәрәев ясаган тальян гармуннар илнең бөтен төбәкләрендә яшәүче моң сөюче гаиләләрдә, чит илләрдәге шәхси музейларда саклана. Ә аның Иске Ярмәктәге өе диварында Татарстанның Мәдәният министрлыгы грантына Өлкә татар милли-мәдәни автономиясе ясаган мемориаль мәрмәр такта эленеп тора. Авылдашлары хәзер бу йортта мемориаль музей оештыру турында уйлыйлар. ■

ӘМИР ГӘРӘЕВ: «ТАТАР МӘДӘНИЯТЕНЕҢ БАЙЛЫГЫ – БЕЗНЕҢ ГОРУРЛЫГЫБЫЗ!»

ТАТАРЛАР – ИҢ БАЙ ТАРИХЛЫ ҺӘМ МӘДӘНИЯТЛЕ ХАЛЫК

2011 елгы халык санын алу мәгълүматларына караганда, Новосибирск өлкәсендә 24 меңнән артык татар яши. Шуның 12 меңе – Новосибирск шәһәрендә. Биредә татарларның ике этник төркеме бар – чат һәм бараба татарлары. Бараба татарлары нигездә Куйбышев, Бараба, Кыштау, Каргат, Венгер һәм Чан районнарында яши. Географик яктан алар яшәгән урын – тарихи Бараба даласының бер өлеше. Хәзерге көндә 4 меңнән артык бараба татары исәпләнә. Чат татарлары – Новосибирск шәһәрендә, өлкәнең Колыван районында, Обь елгасы буендагы Йорт-Акбалык һәм Йорт-Оры авылларында гомер итә. Элек Черный мыс, Красный яр, Кындыз авылларында да көн күргәннәр. Хәзер руслар гына яши торган Чыңгыз авылына да алар нигез салган. Бүген 1500

ӘМИР ГЫЙМАДИСЛАМ УЛЫ ГӘРӘЕВ – Новосибирск өлкәсенең татар милли-мәдәни автономиясе җитәкчесе, Новосибирск шәһәре һәм Новосибирск өлкәсе милли-мәдәни автономияләр ассоциациясе һәм милли оешмалар рәисе, «Электрон приборлар фәнни тикшеренү институты» ААҖ генераль директоры урынбасары, чаңгы спорты буенча спорт мастеры, ике мәртәбә СССР призеры, Новосибирск өлкәсенең чаңгы спорты федерациясе рәисе.

чамасы чат татары бар дип санала. Новосибирск шәһәренә нибары 125 ел гына булса, өлкәдәге татар авыллары моннан 500, 1200 еллар элек үк барлыкка килгән.

Идел буе татарларының безнең якларга күчеп килүе XVII гасырның беренче чирегендә үк башлана. Алар XIX гасырда, Столыпин реформасы чорында, Беренче Бөтендөнья сугышына кадәр аеруча күпләп киләләр. Идел буендагы колхозлаштыру елларында кулак буларак туган илләреннән сөрелгән казан һәм мишәр татарлары да бар. Үземнең дә әти ягыннан бабам Столыпин реформасы чорында Кемерово өлкәсендәге Кышлау авылына Туймазы якларыннан килсә, әнием ягыннан бабам 1930 нчы елларда, күмәкләштерү башлангач, Башкортстан җирләрен калдырып, Анжеро-Судженскига килеп төпләнергә мәҗбүр була. Күчеп килүче казан татарлары нигездә волость үзәкләренә, чат һәм бараба татарлары авылларына урнаша. Алар Бараба даласына язма мәдәният, әдәби татар теле, үзгә фольклор, гореф-гадәт алып килә. Җирле татарлар белән кушылмый калу очраклары да булган. Мәсәлән, Колыван районында Казан исемле авыл бар. Аның халкы Казан губернасыннан килеп, Йорт-Акбалык авылында яшәргә теләгән. Әмма, чат татарлары аларны кабул итмәү сәбәпле, казанлылар җиде чакрым читкә китеп, Казан авылына нигез салган. Бу ике авылда яшәүче милләттәшләребезнең гореф-гадәтләре, хуҗалык итү рәвешләре дә бер-береннән шактый аерылып тора. Чат татарлары тормышында Обь елгасы зур роль уйнаса, казанлылар кое суы эчәләр. Тара елгасы буендагы Кыштау авылында да нигездә Идел-Урал татарлары яши. Хәзер анда ике мәчет бар.

2006 елда Новосибирск өлкәсендә мөселманнарның Диния нәзарәте теркәлде. Ул үзенә Новосибирск шәһәрендәге 4 мәчетне, Бараба, Искитим, Колыван, Кыштау, Убинск һәм Чан районнарындагы, Бердск һәм Татарск шәһәрләрендәге мәхәлләләрне берләштерә. Һәр мәчеттә дә дини эшләрне милләттәшләребез алып бара. Сигез мәктәптә татар теле укытыла. Өлкә милли-мәдәни үзәгендә татар теле курслары эшли. Әмма болар гына бик аз. Аеруча бараба һәм чат татарлары теленә юкка чыгу куркынычы яный. Уңай күренешләр дә юк түгел. Кыштау районындагы Усман мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Якуп Вахитов укучылары ике ел рәттән татар

УМничКА
- это творческие занятия музыкой, театрализацией, изобразительной деятельностью, прикладным творчеством...
с 2-х лет
28-29 августа
с 17.00-20.00

POLIGISTOR SABIROV | VK.COM\POLIGISTOR

теле буенча халыкара һәм төбәк олимпиадаларында җиңүче булды. Мөгаллим үзе «2019 елның иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы» Бөтенроссия конкурсында җиңү яулады. Ул, югары белемле татар теле һәм әдәбияты укытучысы булуы өстенә, Кыштау мәчетенең югары белемле имам-хатыйбы да әле. Шул ук вакытта күп бала атасы да...

НОВОСИБИРСК – ТАТАР ГАЛИМНӘРЕНЕҢ ВАТАНЫ

1989 елда татар иҗтимагый үзәге оешты. Татар җәмәгатьчелеге башлангычы белән Новосибирск өлкәсендә 1990 елда «Новосибирск өлкәсе татар мәдәни үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе барлыкка килә. Хәзерге көндә аның директоры – минем ярдәмчем, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре Рауза Шамил кызы Тихомирова. 2000 нче елларда «Новосибирск өлкәсе татар милли-мәдәни автономиясе» оештырылды. Йорт-Акбалык, Муса, Убинское, Аул-Тандов, Тармакуль, Воробьево, Кыштау авылларында аның филиаллары эшли. Автономиянең беренче президенты профессор, физика-математика фәннәре докторы Эдуард Хәйретдин улы Гыймади иде. Кайчандыр ул Новосибирскига Казаннан Академшәһәрчек оештырырга килгән була.

Гомумән, татар галимнәренең Новосибирск, Себер төбәкләрендәге фән һәм техника үсешенә керткән өлешләре бәһасез. Бөтен дөньяга танылган галимнәрдән СССР ФАнең Космик тикшеренүләр институты директоры, физика-математика фәннәре докторы, астрофизик **Роальд Зиннур улы Сәгъдиев**, «Халыкара томографик үзәк» институты директоры, химия фәннәре докторы **Ренад Зиннур улы Сәгъдиев**, Е.К.Завойский исемендәге Казан физика-техника институты директоры, физика-математика фәннәре докторы **Кев Миңнулла улы Салихов**, РФАнең Океанология институты директоры, физика-математика фәннәре докторы **Роберт Искәндәр улы Нигъмәтуллин**, атом-төш физикасы белгече, техник фәннәр докторы, профессор **Рөстәм Әбли улы Сәлимов**, Кемероводагы Күмер һәм күмер химиясе институты директоры, химия фәннәре докторы, профессор **Зинфер Ришат улы Исмәгыйлев**, техник фәннәр докторы **Тәлгать Сөнгатулла улы Юсупов**, физика-математика фәннәре докторы, профессор, теплофизик **Равил Газиз улы Шәрәфетдинов**ларның тормыш юлы һәм фәнни эшчәнлекләре Новосибирск белән бәйле. Шунысы куанычлы: бу галимнәрнең күбесе – татар рухлы, милли мәдәниятебезгә, тарихыбызга битараф булмаган шәхесләр.

БЕЗНЕҢ БУРЫЧ – ТАТАР МӘДӘНИЯТЕН САКЛАУ ҺӘМ ПРОПАГАНДАЛАУ

Әйтеп үткәнемчә, өлкәдә татар халкының берничә этник төркеме яшәгәнлектән, мәдәни мирас та шактый бай. Әйтергә кирәк, Новосибирскидагы татар мәдәниятенең байлыгы – безнең горурлыгыбыз. Без аның турында башкаларга белгертергә омтылабыз. Күптән түгел, Йорт-Оры авылында чат татарларына багышланган музей-комплекс салынды. Шунда ук мәчет, Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга мемориаль һәйкәл дә төзелде, Мәскәү тракты буенда буыннар агачы аллеясы утыртылды. Хәзер бу авылга туристлар килеп, чат татарлары тарихы, тормышы белән кызыксына ала. Гомумән, без чат һәм бараба татарларының үз телләре белән горурлануын, милли җырларын башкаруын телибез.

Новосибирскида 15 ел дәвамында төбәкара Сабан туйларын үткәрәбез. Күршетирәдә яшәүче милләттәшләребез дә бездән әллә ни ерак түгел. Омск, Томск, Кемерово, Алтай, Красноярск татарлары да Новосибирскида уза торган милли бәйрәмебезгә күпләп килә.

2007 елдан «Сабан туй дусларын җыя» дигән исем астында Өлкә халыкара спорт һәм мәдәният бәйрәмен уздыру да традициягә кереп китте. Новосибирск өлкәсендә 120ләп милләт вәкиле яши. Сабан туенда берничә милләтнең хуҗалык-көнкүреш тормышы күрсәтелә. Бәйрәм ел саен төрле шәһәрләрдә уза. Быел исә ул, Новосибирскидагы Федераль Сабан туеннан соң, Татарск шәһәрендә узачак.

Өлкәнең һәр авылында, шулай ук Йорт-Орыда да даими рәвештә Сабан туе үтәчәк. Бирегә туристларны да җәлеп итәргә уйлыйбыз. Сабан туйларында һәр районда яшәүче төрле милләт вәкилләренә үзләренең милли йолаларын, традицияләрен күрсәтергә мөмкинлек бар, әмма алар бәйрәмнең төп хуҗалары татарлар икәнен онытырга тиеш түгел. Кайбер районнарда Сабан туена башка милләт кешеләре, аеруча урыслар кәләпүштән килә.

Ел саен сентябрь азагында Новосибирск шәһәрендә Себер татар яшьләре фестивале үтә. Узган ел Омск, Томск, Барнаул, Кемерово, Екатеринбург, Красноярск, Лесосибирск, Иркутск, Улан-Удэ, Чиләбе, Төмән, Пермь, хәтта Тула шәһәрләрендә һәм Казакъстан Республикасында яшәүче яшьләр Новосибирск шәһәренә җыелды. Быел ул уникенче мәртәбә үткәреләчәк. Казан, Себер, Казакъстан педагоглары өч көн дәвамында вокаль, хореография, актерлык осталыгы, тарих, дин, татар теле

һәм әдәбияты буенча мастер-класслар уздыра, лекцияләр укый. Яшьләр өчен төрле тренинглар, спорт ярышлары, көрәш, КВН, экскурсияләр оештырабыз. Әлбәттә, кунакларны чат татары утарына – Йорт-Орыга да алып барабыз. Хәтта бер кеше генә килеп, татарларның традицион мәдәнияте турында белеп, татар энергетикасын алып кайтып, үзләрендә нидер башкара икән, без тикмәгә генә эшләмәгән булып чыгабыз. Бирелдә танышкан егет-кызларның татар гаиләләрен корып җибәрүләре – фестивальнең шулай ук матур бер нәтиҗәсе.

Быел Новосибирскида X Төбәкара «Себер йолдызлары» татар мәдәнияте фестиваль-конкурсы узды. Бу чараны ике елга бер мәртәбә оештырабыз. Бирелдә Иркутск, Кемерово, Омск һәм Томск өлкәләре, Казакъстан Республикасыннан татар фольклор, вокаль, инструменталь төркемнәре – барлыгы 300ләп артист чыгыш ясады. Томск шәһәренең Татар мәдәни үзәгеннән 48 кеше килгән иде. Кемерово өлкәсенең Прокопьевск, Анжеро-Судженск, Новокузнецк, Юрга, Яшкинский районнарыннан килүче милләттәшләребез дә уңышлы гына чыгыш ясады. Ерактагы Иркутск өлкәсенең Хореты, Оса, Олой, Маниловское, Хохорск авылларыннан да килүләре куандырды.

«Себер чәйханәсе» төрки милләтләрнең халыкара дуслык фестивален оештыру да күркәм традициягә әйләнде. Узган елның 30 ноябрь һәм 1 декабрь көннәрендә ул сигезенче мәртәбә оештырылды. Мәгълүм ки, Себер – татар халкы белән бергә, башка тугандаш төрки халыкларның – якут, хакас, шор, казакъ һәм алтайларның да тарихи ватаны. Фестивальдә Новосибирск шәһәреннән, Алтайдан, Татарстан һәм Саха-Якутия Республикаларыннан, Иркутск һәм Кемерово өлкәләреннән, Томск шәһәреннән килгән галим-тюркологлар, декоратив-гамәли сәнгать осталары, һөнәрчеләр, профессиональ һәм үзешчән сәнгать осталары катнашты. Хәтта Иркутск өләкәсенең Нижнеудинск районындагы Алыджер авылында яшәүче бик аз санлы халык – тофалар да килгән иде. Фестивальнең беренче көнендә «Себер-Төньяк Азия төрки халыкларының мәдәни мирасы» дигән темага IV фәни-гамәли конференция оештырылды. «Төрки халыклар гүзәле» конкурсында татар, тува, якут, шор, алтай һәм чуваш милләтеннән сигез кыз катнашты. Фестивальнең соңгы көнендә төрки телле иҗат коллективлары гала-концерт, «Бөек хан Күчемдә кунакта», «Себер җәүһәрләрен саклаучылар» дигән театраль тамашалар куйды.

2014 һәм 2017 елларда Новосибирск шәһәрендә Себер федераль округы татарларының съездларын уздырдык. Анда Себердә яшәүче татарларның тарих, тел, мәдәният, мәгариф, матбугат чаралары торышы, милләтара һәм динара мөнәсәбәтләр, бизнес һәм фәннең милләт үсешенә йогынтысы, татар җәмәгатьчелеге арасында яшьләргә карата сәясәт һәм спортка мөнәсәбәт кебек мәсьәләләр турында фикер алышулар булды. Беренче корылтайда ук «Себер татарлары ассоциациясе» төбәкара иҗтимагый оешмасы төзелде. Киләчәктә Новосибирск федераль округында Татарстанның вәкиллеге булсын иде, дип телибез. Шуның нигезендә, Татарстан белән хезмәттәшлекне тагын да киңрәк җәелдерсәк иде.

Шулай ук өлкә күләмендә «Татар егете, «Татар кызы», «Супер әби», «Әти, әни һәм мин – татар гаиләсе», «Минем татар авылым» фестиваль-конкурслары, Тукай укулары даими рәвештә үткәрелеп килә. Бишенче мәртәбә «Себер сандыгы» татар балалар профиль үзәге эшләде. Өлкә татар мәдәни үзәге каршында «Сандугач» татар җыры клубы, «Мирас» вокаль ансамбле, сабыйлар өчен татар сәнгате студиясе, егет-кызлар өчен «Алтын йолдыз» татар яшьләр клубы эшләп килә. Гомумән, Новосибирск шәһәрендә татар мәдәниятен, динен, тарихын өйрәнер өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар, дип әйтергә була. ■

КҮҢЕЛЕ ПАКЬНЕҢ ЭШЕ ДӘ АК

Тәлгат Галиуллин

Халкыбызның гаять үзенчәлекле бер төркеме – борынгы заманнардан Себер киңлекләрендә көн итүче татарларның тарихы, этник составы, тел-лөгать үзенчәлекләре, бигрәк тә рухи мирас – авыз иҗаты, дастан-әкиятләре, бәетмөнәҗәтләре, мәхәббәт һәм йола җырлары турында мәгълүматны иң тирән һәм ышанычлы чыганактан – күренекле тел галиме, фольклорчы, филология фәннәре докторы, профессор Фәрит Юсуповның 2012-2018 елларда нәшер ителгән китапларыннан таба аласыз. Гомеренең төп өлешен себер татарларының иҗади мирасын өйрәнүгә багышлаган шәхеснең үз тормыш юлы да дастаннарга торырлык, саный-атый китсәң, искитмәле: Алабуга педагогия институтының чит телләр факультеты деканы, милли мәктәпләр институты директоры, Төркия Мәгариф министрлыгының өлкән киңәшчесе, КДУ-КФУның татар факультетында профессор, студентларның яраткан мөгаллиме, Мәдәният министрлыгының Традицион мәдәниятне өйрәнү үзәгенең әйдәп баручы хезмәткәре. Нинди генә олы дәрәҗәләргә ирешүенә карамастан, аның мөкиббән китеп өйрәнү чыганагы, мәхәббәте үзгәрешсез кала: ул – себер татарларының рухи-мәдәни мирасын – авыз иҗатын язып алу һәм фәнни-гамәли әйләнешкә кертү. Олуг хәзинәне туплау юлында аны шул якның тымызык суыклары, ком бураннары, күлләр арасында качып утырган утрауларда урнашкан авылларны көймәләрдә эзләү, ат, трактор арбасында йөрү газаплары да туктата алмый. Биштәрен аркасына аскан, кулына магнитофонын тоткан, себер татарлары белән сөйләшеп-сөйләндереп баручы кешене күрсәгез, ул – 80 яшьлеген уздырырга әзерләнеп йөрү урынына, дус-ишләреннән, хезмәттәшләреннән «качып киткән» Фәрит Юсупов булыр имди.

ЯШЬЛЕГЕМДӘ ЯШЬНӘРМЕН

Хәзерге яшьләр өчен «теге заман» саналган 1956 елны Татарстанның төрле районнарыннан, Оренбург өлкәсеннән, Чуашстаннан килеп, гаҗәеп зур конкурс үтеп, 1944 елда ачылган татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керү бәхетенә ирештек. Ул елларда

әле ата-ана ярдәме, мал, акча биреп керү кебек төшенчәләр юк иде кебек (һәрхәлдә, без сизмәдек). Ышанычың-таянычың бары тик мәктәптә алган белемең генә булган чор. «Бәхетеңне» компьютер төймәләренә басып кына табып була торган мәкерле елларның, моңлы, ямьле яңгырашлы телебезнең мәктәп, югары уку йортлары системасыннан алып ташлануы кебек караңгы көннәрнең киләчәген күз алдына да китерә алмый идек әле.

Башка елларда бүлеккә егетләр күбрәк керсә, 1956 елда кызлар талантлырак булып чыкты. Кабул ителгән 25 талибның җиде бөртеге генә ир-ат җенесеннән булды. Шулай да сыйныфка без «хуҗа» булырга тиеш, дип, укулар башлануга, кәнәфи бүлешә башладык. Аксыл-сары чәчле, түгәрәк, бетчәлерәк битле, ифрат хәрәкәтчән, беренче партага, укытучыга якынрак утырырга яраткан Илдар Әүхәдиевне староста итеп тәгаенләдек, үзебезне үк журналына нәкъ дөресен язып куйганга, хәтта дәрескә йөрмәгән өчен стипендиядән коры калдырганга «чиновник» дигән кушамат тактык. Гарәп телен яхшы үзләштергән «чиновнигыбыз» соңрак, гарәп илләрендә эшләп, анда да «үз кеше» булып китте.

Бер ел мәктәп комсомол эшендә тәҗрибә туплап килгән, «р» хәрефен яһүдиләрчә әйтүче Шәүкәт Сәйфетдиновка сыйныф комсоргы булырга Ходай үзе фатихасын биргән диярсең. Эшче сыйныфы дәрәҗәле чорда Свердловск өлкәсендә алюминий комы эретеп кайткан Тәлгат Галиуллинга исә профсоюз эше эләкте. Балык Бистәсе егете Әнвәр Мөхәммәтҗановның юанычы – иске булса да, тальянкасы бар, ул аны ким-хур итеп, ач калдырмаячак. Флюс Нуриәхмәтов үзен Тәкәнеш военкомы кызы дип тәкъдим иткән, группаның иң чибәр кызы Галия Хәсәновага гашыйк булып, аның күзенә чалынырга тырышып, чалбар балакларын тарайттырып, ботинкалары астына күннәр өстәтеп, стиляга «булып китте». Безнең «хакимият» бүлешүләрдән бер студент – хәзерге Яшел Үзән районына кергән Карагуҗа авылы егете, уртачадан аз гына калкурак, чандыр гәүдәле Фәрит Юсупов кына, көлемсерәп, читтәрәк торуны мәгъкуль күрде. Аның зыялы токымнан икәнлеге үз-үзен тәртипле тотышыннан, зәвыклылыгыннан сизелеп тора иде. Шимбә һәм ял көнендә ул туган авылына кайтып килә. Без, бер бүлмәдә яисә күршедә яшәүчеләр аның сәфәреннән канәгать,чөнки ул әнисе яныннан буш кул белән килми: бәрәңгесен, ипиен, ара-тирә маен, каймагын да ташый. Кысмырлык галәмәте юк үзендә, каяндыр соңрак кайтып, ач калып, сорамыйча алсаң да, берни сизмәгәндәй, елмаеп кына куя. Офицер әтисе сугышта һәлак булып, әнисе ике улын берүзе үстергән гаилә үзе дә артык мул яшәмәгәндер, дип фаразлыйм хәзерге акылым белән.

Фәрит исемле группадашыбызга бездән ике курска өлкәнрәк укыган, шигырьләре матбугатта күренә башлаган әдәби түгәрәк старостасы Нурмөхәммәт Хисамов егетебезгә вәкарьлек белән (шуңа хакы булганлыкны ул соңрак та раслады), ихластан, күп мәгънә салып, «әлифбадан төшкән», дигән бәя бирде. Иллә дә мәгәр, күрәзәчелек сеңдерелгән булган икән үзенә Хак Тәгаләбездән. Фәрит гомеренең бер кыйтгасын татар шивәләрендә (диалектларында) аерым хәрефләрнең әйтелешен өйрәнүгә багышлады. Мәсәлән, аның аспиранты Мәдинә Саттарова «А» хәрефенең төрле диалектларда яңгыраш үзенчәлекләрен өйрәнеп, кандидатлык диссертациясе яклады. Без, вакытның кадерен белмичә, тансы-мансыга әрәм иткәндә, Фәрит инглиз, төрек телләрен өйрәнде. Беренче курс ахырында үзенең гомерлек шөгылен тапты: күренекле галимә Диләрә Тумашевага ияреп, Себергә экспедициягә чыгып китте һәм әле дә аннан «кайтып кергәне юк»...

Гафу үтенәм, бер ифрат үзенчәлекле егетебез, соңыннан шагыйрь булып киткән Равил Сәйфетдинов турында онытa язганмын. Ул тумышы, бөтен булмышы белән шигърият кешесе иде. Сыйныфыбызның барча 17 кызына мәхәббәттә аңлашып (дөресрәге,

шигырь багышлап), үз бердәнберен табып, туган төбәге атаклы Мулла Иле авылында озак еллар урта мәктәп директоры булып эшләде, соңрак шунда ук мулла вазыйфасын үтәде. Матур, тезмә сүздән аерылмады, аны безнең чорның Кандалые (мулла-шагыйрь) дип атасаң да арттыру булмастыр.

ҺӘРКЕМНЕҢ ҮЗ ЯЗМЫШЫ

1961 елда университет дипломнарын «кулга төшергәч», тормыш җиле төрлебезне төрле якка очырды. Тумыштан ифрат талантлы Оренбург төбәге егете Рим Кәримов Алабуга пединститутында берничә ел укытып, гаиләле булып, радиокомитет кешесе булып китте, озак еллар дәвамында баш мөхәррир вазыйфасын яратып башкарды. Шәүкәт үзен комсомол, аннан партия оешмасы органы – «Коммунист Татария»гә багышлады, мин, берничә ел дарелфөнүн белән Тел, әдәбият һәм тарих институты арасында «буталып» йөргәннән соң, 20 елга Алабуга педагогия институтына барып төкәндем. Әнвәр, тальянкасын кыстырып (мин аның турында «Һавада «татарин» дигән шук та, моңсу да хикәямдә бәян иткән идем), туган ягында укытучылык эшенә тәвәккәлләде.

Гафу, гафу, укучым. Г.Исхакый әйтмешли, «сүземез» «үтә күренмәле» гәүдәле, елмаюлы йөзле Фәрит турында иде ләбаса! Ул себер татарлары телен, тарихын, иҗатын өйрәнүне бер дәкыйкага да туктатмыйча, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтындагы фәнни эшенә хилафлык китермичә, кандидатлык диссертациясен яклады.

1971 елда мине Алабуга педагогия институтына ректор итеп сайлагач, төрле яклардан, бигрәк тә Казаннан галимнәрне чакырып, институтны дәрәҗәле укытучылар белән ныгыту эшенә керештем. Фәритнең студент елларында ук инглиз телен яхшы ук үзләштерүен исемә төшереп, аны уку-укыту шөгыльләре искечәрәк куелган чит телләр факультетына декан итеп чакырдым. Инде гаиләле кешегә фатир мәсьәләсен дә хәл иткәч, бик теләп риза булды һәм Милли мәктәпләр институтына директор итеп күчергәнче («акыллы башлы» кеше бер мин генә булмаганмын икән), бик теләп, яратып, кем әйтмешли, «җир җимертеп» эшләде, кара алтын табучылар, төзүчеләр, замана дилбегәсен кулларында тотучылар белән уртак тел табып, кызыл үгез тиресен хәтерләткән кирпечтән салынган бинаның дүртенче катын лингафон кабинетлары, бүлмәләрне заманча җиһазлар белән шыплап тутырды. Хәзер дә алар, элеккечә, студентларга, укытучыларга хезмәт итә.

Алабугага күчеп килергә ризалашканда ук ул үзенең бер шартын калкытып куйды: «Һәр җәйне берәр айга Себергә экспедициягә чыгып керү кирәк булыр», – диде. Мин, әлбәттә, ризалаштым, хәтта юлын булса да түләргә, башкача ярдәм итәргә дә тырыштым.

Дөрес, Фәриткә Алабугада озак эшләргә ирек бирмәделәр, әүвәл аңа Казанда, аннары Төркиядә ихтыяҗ булды. Төрек мәмләкәте белән мөнәсәбәтләр җайга салынып, Татарстанда төрек гимназияләре ачылган чорда аны Мәгариф министрлыгына киңәшче итеп җибәрәләр. Төркиядә ул сигез ел (үзе алты гына, ди) чамасы эшләп, ялга кайткан-да да Себерен онытмыйча шунда барып, халык иҗаты җәүһәрләрен туплауны дәвам итте. Хатыны – шәфкать туташы Әлфинур да аның бу мавыгуын аңлады, белүемчә, иренә каршы килмәде.

ҮЗЕҢНЕКЕ – ҮЗӘКТӘ

Үзем белән бәйле, киләчәгем хәл ителгән, юбилярның турыдан-туры катнашы булган бер истәлекле вакыйганы читләтеп үтә алмыйм. Чөнки бу хатирәдә аның кешелеклелеге, дуслыкка тугрылыклы булуы, халык иҗатын туплаучы өчен иң кирәкле

Фәрит Юсупов экспедиция вакытында студентлар һәм себер татарлары белән

сыйфат – төрле буын кешеләре белән аралашу, җайлый-майлый белү үзенчәлеге тулы көчкә ачыла. Әлеге вакыйгада аның, егетлеге өстенә, мәрхәмәтле, ярдәмчел булуы да ачык күренә.

Әлеге дә баягы, үткән гасырның җитмеш тугызынчы елы. Үзебездә Докторлык диссертацияләрен яклау советын ачарга Мәскәүдән рөхсәт булмау сәбәпле, бабаларыбыз 1917 еллар хикмәтенә чаклы кул арбасы белән әлифба китаплары, «хәрефләр» тартып йөреп, «әлиф-би-ти-си»гә өйрәткән халыклар галимнәренә баш иеп, йөзеңә ясалма елмаю чыгарып барасы була. Хезмәтемне Алма-Атада раслатырга йөрим. Каткат барып кайтып, бөтен шәкли процедураларны үттем инде, яклау көннәре якынлаша. Бер катлаулы мәсьәлә ачыкланып җитмәгән: Югары аттестация комиссиясе (ВАК) таләбе буенча, чит төбәктә якласаң, советка бер бәяләүче (оппонент) һәм өч әгъзаны – үз милли әдәбиятыңнан белгеч-докторларны кертү таләбе.

Үзем Казанга кайтып йөри алмыйм, Алма-Атада эшләрем бихисап. Башны кашып, кәпәчем белән киңәшкәннән соң, Фәрит дуска шалтыратып, хәл-әхвәлне аңлатып бирдем, яклау өзелмәсме икән, дип, борчылуымны сиздердем. Ул, аз гына уйлап торды да: «Хафаланма, мәсьәләне аңладым, үзем оештырып, алып килермен!» – диде. Мин, вәгъдә бирү капчык ташу түгел, күпкә җиңел, ә чынлыкта, гамәлдә нәрсә буласын бер Аллаһ кына белә, дип уйлап куйдым. Чөнки ул чорда әдәбият белеменнән докторлар бер кул бармаклары җитәрлек санда гына иде (хәзер дә аларның күплеге белән мактана алмыйбыз). Фәннәр Академиясе президенты Мансур Хәсәнов вакыт таба алмаячак. Хатип Госман безнең өчен бик югарыда торучы һавалы галим иде. Тәнкыйть мәкаләләре буенча, Гали Халит ярларына сыеша алмаган язгы ташуны хәтерләтә иде. Киң күңелле Мөхәмәт ага Гайнуллин гына шик уятмый. Ул ерак юлга чыгудан да куркып тормый. Юктыр, булмастыр, шундый сәфәргә ризалашмаслар, дип өзгәләнеп, үземә урын тапмый йөргән мәлдә кунакханәмдәге телефон «телгә» килде. Шалтыратучы Фәрит булып чыкты: «Сәлам, дустым! Дүртесенә дә самолетка билет алдым. Иртәгә сәгать унда очабыз», – ди.

Барысы да төп-төгәл (соңрак «татар десанты» Алма-Атада дип көлешеп тә йөрдек) вакытында килеп тә төштеләр, мине яклатып та кайттылар. Бу очракта Фәритнең ярдәмчеллеге яшьлек дусларына ихлас тугрылыгында гына чагылмый, ә өлкәннәрне өлкән күреп, яшьләрне үзенчә бәяләп, кешеләр белән сөйләшә һәм сөйләштерә белү

сәләте, зыялылыгы да чагыла. Әгәр шундый ягымлы, сүзчән һәм кеше холкын сиземләү сәләтенә ия булмаса, биш калын томга кергән халык иҗаты әсәрләрен язып ала алыр идеме?! Мин үзем дә, фольклорчы, берничә ел Илбарис Надиров белән экспедицияләргә чыккан кеше буларак, берәр җыруны җырлату, әкиятне сөйләтү өчен күпме үгетләп, әүвәл үзең җырлап, сөйләп утырасыңны күз алдына китерәм. Фәрит Юсупов тупланмаларына кергән җыр, бәет, мөнәҗәт, әкият һ.б. әсәрләрне саный, укый башласаң, исләрең китәрлек.

СЕРЛЕ САНДЫК АЧЫЛА БАШЛАДЫ

Төркиядә хезмәтен тутырып кайтып, шактый вакыт КДУ-КФУның татар филологиясе факультетында профессор вазыйфасын (докторлык диссертациясен Мәскәүдә яклый) башкарып ятканда, Ф.Юсупов озак еллар өйрәнгән, элгәрләре һәм үзе язып алган әсәрләре тупланган «серле сандык»тан бикне алсын өчен махсус диярлек, Мәдәният министрлыгы каршында Традицион мәдәниятне өйрәнү һәм үстерү үзәге ачыла һәм аны әйдәп баручы гыйльми хезмәткәр итеп чакыралар. Шунда эшләгәндә ул себер татарлары тарихына, фольклорына мөкиббән галим булып таныла. 2012-2018 елларда, бер-бер артлы диярлек, кемнеңдер сайланмаларына торырлык саллы-саллы китапларын нәшер итә. Үзенә чаклы язып алынган җәүһәрләрне фәнни күзлектән барлап чыгып, үзе тапкан вариантларны кертеп, Себер халкының рухи мирасын өйрәнүне яңа баскычка күтәрә. Бу юлда Ф.Юсупов өч принципны маяк итеп ала. Беренчесе – әлеге юнәлештә хезмәт иткән, аңа чаклы халык иҗатын телдән язып алып, фәнни-гамәли калыпка салуда зур хезмәт куйган шәхесләргә ихтирамлы һәм рәхмәтле булу. Бер мәҗмугасының башында ул өч исемне «чәчәк бәйләме» уртасына куя. «Себер татарлары халык авыз иҗаты мирасын җыючы һәм фәнни өйрәнүче мәшһүр галимнәр Василий Васильевич (Вильгельм Фридрихович) Радлов, Хәмит Хөснетдин улы Ярмөхәммәтов (Хәмит Ярми), Флора Ваһап кызы Әхмәтова-Урманченең якты истәлекләренә багышлыйм», – дип яза.

Инешне «ерып җибәргән» иң тәүге китабында ул күренекле немец галиме, телләрен өйрәнеп, ярты гомерен себер татарлары арасында уздырган фидакарь шәхес В.В.Радловның « Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дунгарской степи. Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменских татар» дигән хезмәтен хәзерге транскрипциягә салып, безнең чорда да кыйммәтен югалтмаган олы хезмәткә фәнни, төгәл бәя биреп, аны галимнең юбилеена бастырып чыгара. Академик, гыйльми тюркологиябезгә нигез салган В.В.Радлов XIX гасырның икенче яртысында себер татарларыннан язып алган халык иҗаты үрнәкләрен 1872 елда Санкт-Петербургта бастырып чыгара һәм аның бу хезмәте тиз арада алман теленә дә тәрҗемә ителә. Галим, авылдан-авылга, йорттан-йортка йөреп, халык теленнән 41 әкият, 29 җыр һәм бәет, 16 дастан яисә алардан өзекләр, 23 риваять, ышанулар, йолалар язып ала. Ф.Юсупов бу хәзинәне барлап, тикшереп, җыентыкларына кертә. Аның фикеренчә, В.В.Радлов мирасында иң кыйммәтлесе – дастаннар. Ошбу лиро-эпик төрне мәгънәви яңгырашлары буенча Радлов тәкъдим иткән бүленеш хәзергәчә хәрәкәттә: тарихи дастаннар, алыплар турындагы дастаннар, мәхәббәт дастаннары.

Шул төр халык иҗаты җәүһәрләре арасында XIV-XV гасырларда Каспий буйларында, Кырым, Көнбатыш Себер киңлекләрендә, хәзерге Казакъстанда, Алтын Урда биләмәләрендә барган дөньякүләм вакыйгаларны, Идегәй, Туктамыш, Аксак Тимер кебек тарихи шәхесләр катнашында барган сугыш-тартыш, мәкер-хыянәт кебек хәлләрне тасвирлаган «Идегәй» дастаны – халкыбызның даһи иҗат җимеше. Радлов әсәрнең тулы нөсхәсен себер татарларыннан язып ала. 2014 елда нәшер ителгән «Себер татарлары» (дастаннар, бәетләр, мөнәҗәтләр) тупланмасында «Туктамыш хан», «Туктамышның саубуллашуы» дип аталган шактый саллы өзекләр урнаштырылган.

Ф.Юсупов җыентыкларының икенче мөһим үзенчәлеге – ышанычлы тарихи-фәнни чыганакларга таянуы. Галим расланмаган бер генә фикерне, үзе тикшермәгән текстны (кем язып алган булса да) мәҗмугаларына кертми. Барысы да әлифбадагы, санау таблицасындагы мисле төгәл булырга тиеш. Ф.Юсупов, себер татарлары тарихын, тел үзенчәлекләрен фәнни өйрәнүгә зур өлеш керткән Д.Тумашева, Г.Фәйзрахманов, Ф.Вәлиев, Д.Исхаков кебек татар галимнәренең хезмәтләре белән беррәттән, итальян рус, алман, төрек, фин һ.б. телләрдә иҗат ителгән эзләнүләргә, фикерләргә дә таяна. Аны ышандыра алмасалар, бәхәскә керә, үз гөманын калкытып куя.

АЯНЫЧЛЫ ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Көнбатыш Себер тигезлегенең төп халкын тәшкил иткән төрки телле халыклар утрак тормыш белән гомер-гомергә шунда, ягъни хәзер Төмән, Омск, Тобол, Новосибирск, Кемерово (татарның күмер сүзеннән алынган) шәһәрләре урнашкан урыннарда яисә якын-тирәдәге авылларда һәм күбрәк Иртыш, Тобол, Ишим, Чулым, Тура, Обь кебек зур елгалар буенда яши.

Географик яктан бер-берсеннән шактый ерак араларда, бер ишесе күлләрдәге утрауларда гомер итә. Фәнни әдәбиятта аларны төмән, тара, тобол, бараба, ишим-чулым, саз арты кебек төркемнәргә бүләләр.

Себер татарлары гомер сөргән Себер тигезлеге, Алтай, Төньяк Казакъстан кешелек цивилизациясе барлыкка килгән тарихи төбәкләрнең берсе санала. Аерым алганда, Том елгасы үзәнендә палеолит һәм неолит чорларына караган казылма истәлекләр табылуы мәгълүм. «Күп санлы курганнар – шуның «җанлы» шаһитлары», – ди Ф.Юсупов. Бу якларда яшәгән төрки телле халыклар терлек үстергән, иген иккән, аучылык белән шөгыльләнгән, тимер, алтын һәм көмеш белән эш иткән. Үзара тату яши белмәү, хакимият бүлешү өчен туктаусыз барган сугышлар өстенә, урман-кырлары чит мәмләкәтләрне кызыктырып торган себер татарлары нәрсә генә күрмәгән! Кырыс, әмма мул табигатьле, үзләре дә төрле кавемнәрдән торган, бу яктан Кавказ Дагыстаныннан калышмаган себер татарларына бер халык булып оешып җитәргә ирек тә бирмәгәннәр. Тарихчылар гоманынча, һун җайдаклары Тобол һәм Бараба киңлекләрендә кылыч һәм сөңге белән «тәртип» урнаштырып киткән. Гаярь һуннарны VI гасырда Бөек Төрки, җиденче йөзләрдә Уйгыр каһанлыгы алыштыра. Ә инде IX гасырда Кыргыз каһанлыгы оешып җитә, аңа да киңлекләр кирәк була. Көчлеләр гасырлар дәвамында тупланган байлыкны талыйлар да китәләр, ә җирле халык янәдән аякка басып яшәвен дәвам итә.

1394-1395 елларда Себергә татар-болгар һәм Урта Азия аша ислам дине үтеп керә башлый. Җирле халыкның күпчелеге мәҗүси булса, бер өлеше күк алласы Тәңрегә табынып, читтән килгән яңа динне кабул итүгә ашкынып тормый. Алтын Урда хакимнәренең ерак кардәшләре Ибак һәм бигрәк тә Күчем ханнар халыкны бер зиһиният-идеология йогынтысында берләштерүдә, төрле кабиләләрдән оешкан халыкны бер ояга туплауда исламның уңай якларын бәяләп, яңа дин ягына авышалар.

Ислам диненең себер татарлары арасында таралуына суфыйчылыкның нәкышбәндия тарикате һәм Күк Урда ханы Шәйбан җибәргән 1270 җайдак, Бохарадан килгән 336 шәех мөһим этәргеч бирә. Дөрес, җирле халык белән «аралашканнан» соң, «димчеләрнең» 66сы гына исән кала. Дин өчен шәһит киткәннәрне соңрак буын татарлары «изгеләр, әүлиялар» дип саный. Казан, аның артыннан Әстерхан ханлыклары яулангач, Себер ханлыгына да яшәү кыенлаша, авыр, фаҗигале финал якынлаша. Рус империясенә дә Себер киңлекләре кирәк була башлый. Ә бит бу төбәк чукындыруны, руслаштыруны кабул итмәгән, ислам шәригатен тоткан татарлар өчен сыену, яңа тормыш башлап җибәрү урыны да булган. Ибак, аеруча Күчем хан идарә иткән елларда

Урта Идел, Урал ягы татарларының Себергә гаиләләре белән күчеп утыруы көчәя. Төрле этник кавемнәрнең аралашуы, кушылуы нәтиҗәсендә, Себер төркиләре, кабатланмас лөгать, яшәү үзенчәлекләрен саклап, татар халкы дип аталган этносның аерылмас өлешен тәшкил итәләр. Мәгәр Сибернең төп халкына да, күчеп килгәннәргә дә үзләре теләгәнчә, тыныч тормыш белән яшәргә бирмиләр. Бу яктагы урман, су байлыклары рус сәүдәгәрләрен үзенә тарта. Төмән, Тобол һ.б. кальгалар салына башлый. Строгановлар тимер, алтын, көмеш эшкәртү заводларын корып, шуларны җирле халыктан саклау өчен, казак атаманы Ермакны чакыра. 1581 елда алар Күчем хан биләмәләренә бәреп керәләр. Каты сугышлардан соң, 1585 елның 6 августында Ермак үтерелә, әмма аның урынына башкалары килә. Ханлык 16 ел дәвамында азатлык өчен көрәш алып бара. Күчем туганнарын, улларын югалта, тик бирешми. 1601 елда карт, сукыр, яралы хан куштан нугайлар тарафыннан үтерелә. Мөстәкыйльлеген саклап калу өчен көрәштә себер татарларының 90 проценты һәлак була.

МИЛЛӘТНЕҢ ҮЗАҢЫ – АНЫҢ ИҖАТЫНДА

Һәр халыкның тарихы, холкы, фикерләү рәвеше, шигъри теле аның авыз иҗатында эз калдыра. Инглиз, алман, рус һ.б. милләтләрнең дастаннары, сагалары, былиналары, җырлары шуны раслый. Фольклор – һәр халыкның «визит карточкасы». Себер киңлекләрендә яшәүче милләттәшләребезнең үзләренә генә хас тарихи дастаннары – «Әбел-Касыйм», «Бури хан», «Атулы Батыр», бәетләре, җырлары булса да, «Йосыф-Зөләйха», «Таһир-Зөһрә», «Бүз егет», «Сәйфелмөлек» кебек дастаннар – уртак байлык, «Кузы Көрпә», «Шаһсанәм вә Гариб» кебек сөю-сәгадәт газапларына багышланганнары исә башка төбәкләрдә дә очрый.

Героик дастаннардан «Алпамыш»ның әллә ничә төрле нөсхәләре язылып алынуы мәгълүм. «Алып», «Алып-батыр», «Алып кеше» – Алпамша, Алпамыш, Алтмамыш... Аларның эш-хәрәкәте маҗаралы: алыплар, гади кешеләрнең башына да кермәслек батырлыклар кылып, хакыйкать тарафдары, уңай зат буларак сурәтләнәләр.

Ф.Юсупов экспедицияләр вакытында татар халык эпик поэзиясенең, аерым алганда «Сәйфелмөлек», «Алпамыш», «Кузы Көрпә», «Йелек батыр», «Бүз егет» һәм башкаларның нөсхәләрен, аларның үсеш-үзгәрешен, телдән төшеп калу эволюциясен күзәтә.

Халык үзенең батырларын, аның мәнфәгатьләрен кайгырткан затларын сайлап ала белгән. Себер татарларының, аз санлы булсалар да, иркен таралып, җәелеп утыру сәбәпле, ханлыклары да, табигый ки, хакимнәре дә күп булган. Шулар арасыннан ул азатлык өчен көрәшкә гомерен багышлаган Күчемне аерып алган. Аңа берничә истәлек, риваять багышланган («Күчем хан», «Бараба» һ.б.). Халык үзенең яклаучысына югары бәя бирә: «Уналтынчы йөзләрдә булырга тиеш, себер татарларының ханы Күчем булган. Ул үзе көчле, акыллы, хәйләкәр кеше булган».

Ф.Юсупов үзенең тупланмаларында халыкның мәңгелек хыялларын, якты тормыш, яхшы кешеләр турында күзаллауларын үзенә кояш нурларыдай җыеп алган әкиятләргә – себерчә «йомаклар»га һәм кече жанрларга – мөнәҗәт, бәет, җырларга зур игътибар бирә.

Дастан, әкият һәм риваятьләрне Ф.Юсупов, нигездә, В.Радлов чыганакларыннан алса, бәетләрне Ф.Әхмәтова язмаларында тапса, соңрак фәнни әйләнешкә кергән мөнәҗәтләрнең исә үзе һәм студентлар белән язып алынганнарын тәкъдим итә. Экспедициягә үзе белән алып чыккан кешеләрнең исем-фамилияләрен күрсәтеп баруында да аның акыллы, эчкерсез, кешелекле, намуслы шәхес булуы күренә.

Ислам диненең шигъри юлдашы, халык иҗаты белән язма шигърият бердәмлеге булган, әүвәл гарәп-фарсы телләрендә туып, төрки дөньяга (бигрәк тә татарларга,

өлешчә башкортларга) тирән үтеп кереп киткән мөнәҗәт себер татарларының рухи-мәдәни мирасында мөһим урын тота. Мөнәҗәтләрнең асылында суфичылык фәлсәфәсе белән баетылган дини лирика ята. «Мөнәҗәт» гарәпчәдән тәрҗемәдә Аллаһка табынуны, таянуны, ярлыкау вә ярдәм сорап мөрәҗәгать итүне аңлата. Ислам диненең йогынтысы көчлерәк чорда әүвәл Урта Идел, Урал тарафларында киң таралып, XIV гасырдан, халыкның төп өлеше исламны кабул иткәч, мөнәҗәтләр себер татарларының рухи дөньясына да үтеп керә.

«Ышанам бер Аллага», «Бердер Аллаһым минем», «Ярдәмеңне бир, Аллаһым», «Рәхим-рәхмәтең кыл, Расулуллаһ» кебек мөнәҗәтләр татарлар яшәгән барлык төбәкләрдә дә табыла. Ф.Юсупов ялгыз картлык, карыйлык, ата-ана белән балаларның аерылышуы һәм туган илдән читтә яшәү сагышы, якыннарны сагыну кебек хис-кичерешләргә мөнәсәбәтле мөнәҗәтләр себер татарларында аеруча киң таралган, ди. Мәсәлән, «Аерылмагыз балалардан», «Аерылдым туганнардан», «Кайттым-җиттем туган илгә...», «Торып сахраларга чыксам» һ.б. Бу төр мөнәҗәтләрнең өстенлек итүе Себер халкының сибелеп яшәве, кайберләренең Идел-Уралдан читтә көн итүләре белән дә аңлатыла торгандыр.

Нигезендә моң, сагыш, юксыну, югалту, хәсрәт, сызлану мотивы булган әсәрләр Идел-Урал һәм Себердә яшәүче татарларны аеруча якынайталар. Уртак югалту – Тукай үлеме («Тукайга бәет»), төрле сугышларда үлгәннәргә мәрсия («Безне герман аерды», «Хан мәчете бәете», «Суга баткан Гайшә бәете», «Гайшә мескен бәете» һ.б. бәетләрне милләттәшләребез яшәгән һәр төбәктә тыңлый аласың. Минем фикеремчә, безнең якта бик ишетелмәгән «Берсендә – йолдыз, берсендә – кубыз», «Ике ир бала бәете», «Наполеон һәм Миңнулла» бәетләре Себер якларында иҗат ителгән.

Ф.Юсупов себер татарларының җырларын туплап, сәнгати үзенчәлекләрен өйрәнүгә дә зур әһәмият бирә. Ул элгәрләренең себер татарлары җырларын бәяләгән хезмәтләрен ихтирам белән телгә ала.

Себер татарларының үз йола җырлары, туган як моңын сеңдергән тезмәләре булса да, «Саҗидә», «Агыйделкәй», «Ай, җаным, җанашым», «Әйдүкә», «Юлбикә» кебек Идел-Урал якларында таралган җырларны да анда яратып башкаралар.

Халык иҗаты әсәрләренең барысында да кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең сафлыгы, садәлеге, явызлыкның җиңелүе, мәхәббәтнең мәңгелеге, ихласлыгы, җилдавылларга бирешмичә шатландыруы алга сөрелә. Халык олы җанлы шәхесләрен, дөреслек-хакыйкать өчен көрәшчеләрен онытмый, аларны дастаннарында, әкиятләрендә, җырларында олылый. Халык иҗаты җәүһәрләре, үз чиратларында, татар халкының характерына, матурлык, тормыш яме турында күзаллавына, үз-үзен тотышын кмилләштерүгә, туганлык, милли мөнәсәбәтләрнең ныгуына тәэсир ясаганнар. Шул байлыкны җыеп, туплап яңа буыннар өчен саклап калу – фидакарьләр бурычы. Күңелләрдә якты уйлар, киләчәккә ышаныч тудырып, рухи мирасны халыкка кайтаручы олы шәхесләрнең берсе – Фәрит Юсупов. Ул, себер татарларын аерым милләт дип пычрак суда балык тотарга маташучылардан аермалы буларак, Себердә яшәүче милләттәшләребезне татар халкының аерылмас, тирән тамырлары белән аңа береккән бер өлеше, дип бәяли.

Җыеп әйткәндә, аның мәҗмугалары күп нәрсә, аеруча безнең катлаулы чорда, төрле төбәкләрдә көн күрүче милләттәшләр арасында бердәмлекне ныгыту ихтыяҗы турында уйландыра. Ошбу китаплар, себер татарлары арасында халыкның үз теленнән язып алынган үрнәкләр булу белән беррәттән, күпчелек фольклор әсәрләренең бөтен милләтебез өчен дә уртак икәнлеген, һәр төбәкнең рухи-мәдәни казанашы халкыбызның уртак байлыгы булуын исбатлый. ■

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНА – 100 ЕЛ

Сусау ләззәте

Газинур Морат

Ирләр булыйк – ир булгач та,
картайгач та...
Рәдиф Гаташ

Шагыйрь халкының күңел шәрифләре тумыштан ук ритм-рифма стихиясенә көйләнгән була торгандыр. Аларның фикер йөртү рәвеше дә әлеге ике алтын кыса арасында ихтыярсыз чәбәләнеп йөргән Пегас колынының хәл-халәтенә тәңгәлдер. Табигатьтән үк шагыйрь булып яралган сабый калебендә тәүге шигъри тезмәләр әнә шулайрак бөреләнәдер дип беләм.

Дөресен әйткәндә, бала чагында, башлангыч сыйныфларда укыганда, мин үзем шигырь белән бөтенләй дә дус түгел идем. Укытучы апабыз, өй эше итеп, шигырь ятлап килергә кушып та җибәрсә, бусы инде миңа бөтенләй дә ялыктыргыч, кирәксез бер шөгыль кебек тоела иде. Шуның зыкымыдыр, күрәсең: шушы яшькә җитеп, үзем язган бер генә шигырьне дә яттан сөйли алмаудан гаҗизмен. Шуңа күрә гомер буе куен кесәсендә «шпаргалка» йөртүдән башка чара калмады. Аның каравы, Рүзәл Мөхәммәтшин кебек яшьләрнең үз шигырьләрен һәрвакыт күңелдән укып кинәнүен сокланып та, бераз көнләшеп тә тыңлап-күзәтеп торырга яратам. Нишлисең,

«шпаргалка»сыз шагыйрьнең чыгышы да күпкә тәэсирлерәк килеп чыгучан шул...

Кыскасы, 70 нче еллар башында, баш мие ялкынсынып, яшәү белән үлем арасында җан тартышканчы, минем шигырь белән алыш-биреш юк дәрәҗәсендә иде.

Һәм дөньям, көтмәгәндә-уйламаганда, капылт кына үзгәрде дә куйды: бар вөҗүдемне шигырь язып карыйсы килү теләге биләп алды. Билгеле, бик тә аңлаешсыз теләк иде ул минем өчен. Әмма үзе күңелне берөзлексез бимазалап та тора башлады. Ул чакта әле безнең өйдә шигырь китаплары юк та иде шикелле, ә менә озак еллар дәвамында җыйнала килгән «Казан утлары» журналының әрдәнәләп өелеп торуын бик яхшы хәтерлим. Шигырьнең әлифен дә белмәгән килеш, мин, 11-12 яшьлек үсмер малай, әнә шунда басылган шигырьләрне укырга керештем. Яшермим, дәреслекләр буенча исемнәре шактый ук таныш шагыйрьләрне ара-тирә сикертебрәк тә узарга тырыштым. Аңлашыла, бала күңеленең үзенчә яңалык эзләргә тырышуы да булгандыр инде бу. Эзли торгач, яңалык дигәннәре дә тәки табылды бит, рәхмәт төшкере. Моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән Рәдиф Гатауллин атлы 30 яшьлек шагыйрь абый белән мин беренче тапкыр әнә шулай, «Казан утлары» сәхифәсендә очраштым. Гаҗәеп самими лирик шигырьләр, сөйгән ярына атап язылган ихлас, садә хат-багышлаулар... Үз борыны да кызлар исен тоя башлаган үсмер малайга тагын ни кирәк?! Өстәвенә, ул шигырьләрнең формасы да без күнеккән рәвештә түгел, ә иркле шәкелдәрәк иде. Бусы минем үземне аерата нык җәлеп итте, чөнки ритм-рифмалары дүртьюллык строфалардагы кебек күзгә бигүк бәрелеп тормагач, беркатлылыгым белән, андый шигырьне язу җиңелрәккә туры килер, дип уйладым. Дөрестән дә иң беренче тәҗрибәләрем нәкъ уйлаганча – «иркле» булып чыкты да. Ләкин шигърият үзе мине тәмам ирексезләп, әсир итеп өлгергән иде инде. Мин аңардан аерылып китмәскә булдым. Авыл китапханәсеннән Рәдиф Гаташның «Гөлләр су сорый», «Кояшлы утраулар» дигән, куен кесәсенә җайлы гына кереп утырышлы шигырь мәҗмугаларын чәлдереп чыгып, йотлыгып укый башлагач, әлеге ышанычым тагын да ныгый төште. Аннары буа тәмам ерылды инде: Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Роберт Әхмәтҗанов, Гәрәй Рәхим, Рөстәм Мингалимов, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов, Разил Вәлиевләрнең дә тәүге җыентыклары минем өстәл китабына әйләнеп китте.

Әкренләп район газетасында беренче шигъри караламаларым да басыла башлады. Аларга ул чакта «Хезмәт даны»нда хезмәт куючы Шаһинур Мостафин фатиха бирде. Үзе әйтмешли, мең рәхмәтләр аңа. Ә менә «Социалистик Татарстан», «Татар-

стан яшьләре» газеталарына, ни тырышып та, үтеп кереп булмады. Шулай да алардан трафарет җаваплар килгән чагында да кош токтандай очынып йөри идем. Бастырмасалар да, игътибар иткәннәр бит әле, дигән беркатлы уй шулай очындырган инде, күрәсең. Әлеге редакцияләрнең, гомумән дә, шигырь белән бигүк дус булмаганын ул чагында каян белим соң?!

Шигырь җене ныклап кагылып өлгергәнгәме, 10 нчы сыйныфны тәмамлаганда, минем алда, кайда укырга барып карарга икән, дигән сорау тормады да. Әлбәттә, безнең ише сары томшыклы «даһи»ларның урыны университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегендә генә була ала иде. Мин яраткан, үз иткән каләм әһелләренең дә бик күбесе нәкъ менә шунда гыйлем эстәп йөреп, шәп шагыйрьләр, язучылар дәрәҗәсенә ирешкән ләбаса. Кем белә, бәлки, миңа да бәхет елмаеп куяр...

Менә безне, инша язар өчен, университетның төп бинасындагы алагаем зур бер бүлмәгә кертеп утырттылар. Без исә, бер урынны алты абитуриент дәгъвалап, өч теманың берсен сайлап, икеме, өчме сәгать эчендә имтихан алучыбыз Мөхәммәт Мәһдиев үзе тел шартлатырлык инша язып өлгертергә тиеш идек. Мин, азмы-күпме фантазиягә исәп тотып, иректе теманы сайладым – «Күңелем Ленин белән сөйләшә» дип атала иде ул. Хәзер инде Ленин белән ниләр хакында гәпләшкәнем исемдә түгел, ә менә иншага Рәдиф Гатауллинның иректе шәкелдә язылган «Алибилар булмас» дигән шигыреннән озын гына бер өзекне эпиграф итеп куйганымны әле дә хәтерлим. Аның да үз хәйләсе бар иде, билгеле: янәсе, бу малай, Сибгат Хәкимнең «Күңелем Ленин белән сөйләшә» дигән киң билгеле әсәрен санга сукмыйча, дәреслекләргә дә кермәгән яшьрәк бер шагыйрьнең шигырен файдаланып, оригиналь булып кыланасы иткән.

Шулай да имтихан алучыларыбыз иншаны «бишле»гә бәяләгән иде...

Икенче семестрда хәлфәбез Зәет Мәҗитов безнең төркемдә махсус курс алып бара башлады һәм барыбызга да үз күңеленә хуш килгән берәр яңа әдәби әсәргә яки китапка рецензия язарга йөкләмә бирде. Миңа бу юлы да сайланып торасы булмады – Рәдиф Гатауллинның әле генә дөнья күргән «Йолдыз җиле» (1976) дигән китабы турында белгәннәремне яздым да Зәет абыйның кулына тоттырдым. Озак та үтмәде, укытучыбыз: «Сине Рәдиф абыең «Казан утлары»на чакыра», – дип, мине тәмам өнсез итте. Бактың исә, ул, үземә әйтмичә генә, теге язманы журнал редакциясенә илтеп биргән дә, аны бастырып чыгарырга ук уйлаганнар икән. Шулай итеп, «Казан утлары» журналы редакциясенең эш бүлмәсендә миңа шагыйрьнең үзе белән дә очрашу куанычы насыйп әйләде.

Шуннан соң без инде Рәдиф Гаташ белән гел бер орбитадарак әйләнә башладык. Дөресрәге, ул яшьләрне үз орбитасы тирәсенә сыендырды.

«Мин үз артымнан кемнеңдер килгәнен тыңларга яратам. Кайвакыт аяк тавышы синнән шактый еракта, аннан якыная төшә кебек, аннан бөтенләй янда...» – дип язган Сибгат Хәким яшь шагыйрьнең «Гөлләр су сорый» дип исемләнгән тәүге китабына сүз башында. Рәдиф абый үзе дә, нәкъ остазы үрнәгендәгечә, яшь каләмдәшләренә карата һәрвакыт хәерхаһ, ярдәмчел, киң күңелле, игелекле була белде. Чынлыкта бу дөньяда остазлык кылу маһирлыгына ирешү – адәм баласы өлешенә туры килгән иң олы мәртәбә түгелме икән әле ул?!. ■

«ТАТМЕДИА» республика матбугат
һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы,
Татарстан китап нәшрияты,
«Безнең мирас» журналы редакциясе

ТАССРНЫҢ ҺӘМ ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНЫҢ 100 ЕЛЛЫКЛАРЫНА БАГЫШЛАП, «ХӘТЕРГӘ УЕЛГАН КИТАП» ИСЕМЛЕ КОНКУРС ИГЪЛАН ИТӘ

КОНКУРСНЫҢ МАКСАТЫ – татар китап мирасын пропагандалау, республикабызда телләрне саклау һәм үстерү, яңа авторларны табу, алар белән хезмәттәшлек итү.

Конкурс 2019 елның 1 апреленнән 2019 елның 15 декабренә кадәр үткәрелә.

Конкурска үзегез бик тә яратып укыган, тормышыгызда мөһим роль уйнаган, хәтергә уелып калган яки сез «өстәл китабы» буларак файдалана торган китап турында татар телендә язылган очерк, эссе, мәкалә кабул ителә. Күләме А4 форматында 12 нче кегельдә 2 биттән дә артмаска тиеш.

Конкурста катнашучылар үзләренең эшләрен «Безнең мирас» журналына 2019 елның 2 нче ярты еллыгына яки 2020 елның 1 нче ярты еллыгына язылу турындагы квитанция фотосын (скан вариантын) беркетеп, yanamiras@mail.ru электрон почтасы адресына «КОНКУРСКА» дигән сүз белән җибәрергә тиеш.

Конкурска юлланган эшләр Татарстан китап нәшриятының генераль директоры һәм «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире раслаган жюри әгъзалары тарафыннан бәяләнеп, җиңүчеләр 2019 елның 1 декабрендә игълан ителә.

Җиңүчеләргә акчалата премияләр, Татарстан китап нәшриятыннан китап алу өчен сертификатлар, «Безнең мирас» журналы редакциясеннән конкурста призлы урын алучыларга сертификат һәм барлык катнашучыларга дипломнар биреләчәк.

Барлык материаллар да «Безнең мирас» журналында яки http://beznenmiras.ru/ сайтында басылачак.

Конкурс турындагы мәгълүмат **http://beznenmiras.ru/** сайтына урнаштырыла.

Безнең мирас №6 июнь 2019

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов

ЯПОНИЯ

ЯПОНИЯГӘ КИЛЕП ҖИТҮ

20 ноябрь көнне иртән иртүк безне йокыдан каюталар хезмәткәре уятты. Бөтен юлчыларга да чәй бирделәр. Яңа гына таң атып килә, пароход Цуруга портына кереп бара иде. Мин палубага чыктым. Бергәләп кичәге көнне үткәргән «китапханә» дусларыбызның барысы да бүген кабат матроска әйләнгәннәр, эш киемнәрен кигәннәр дә хезмәтләрен башкаралар иде.

Монда да пароходыбыз бозларны ера-ера ярга якынлашты. Ике йөз адым эчтәрәк туктап якорь ташлауга, «Хозан Мару»га таба бер яхта белән бер көймә якынлашты. Баскычларны төшерүгә, безгә: «Рәхим итегез!» – диделәр. Каюта юлчыларын – яхтага, палуба юлчыларын көймәгә алдылар. Безнең янныбызга әйберләребезне дә төяделәр. Биредә пристань кебек берни дә юк, гади причалга якынлаштык. Багажларыбызга кул да тидермибез. Бездән бер тиен акча сораган кеше дә юк. «Җиргә аяк басты»

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

түләве, пароходтан ярга чыгару акчасы, беркем берни сорамый. Ниһаять, түзмәдем, үзем сорадым. «Бу яхта белән ярга чыгарган өчен акча алмыйсызмыни?»

Берсе, елмаеп, җавап бирде: «Без юлчыларны җирдән алдык, җиргә кабат бастыру – безнең бурыч. Таможня капкасыннан чыкканнан соң, кая телисез – шунда, ничек телисез – шулай китә аласыз».

Пристаньда паспорт сораган кеше дә булмады. Багажларыбызны караучы да булмады. Бары тик бер хезмәткәр: «Сигаретларыгыз бармы?» – дип кенә сорады. Арабыздагы бер инглиз кешесенең ике пакет сигареты бар икән, күрсәтте, аңа да берни әйтмәделәр. Шул аңлашылды: бик күп булса, сигаретны илгә алып керү тыела икән. Таможня капкасыннан чыгарга дип торганда, бер яшь егетнең: «Тимер юл белән юлын дәвам итәчәк кешеләр игътибарына: поезд кузгалып китәргә 40 минут вакыт бар», – дип кычкырганы ишетелә иде.

Багажымны, таможня капкасына килгәч, кире алдым. Пароходта ничек кулымнан алдылар, нәкъ шул хәлдә китереп бирделәр. Бөтен юлчылар да багажларын шул рәвешле кире алды. Бераз гаделлек һәм салкын акыл белән фикер йөртеп әйтеп карыйк әле: Европаның кайсы җирендә мондый мәдәният очрата алабыз? Юлчы багажы пароходтан ярга кадәр бушлай ташылсын – бу кайда бар? Арабыздагы Европа гашыйклары «Парижда да шулай!» яки «Лондонда да болай!» дия алалармы? Ихтимал, бередә кайберәүләр: «Бу яхта акчасы инде: алдан-алы, пароход билеты сатканда ук алынгандыр», – диярләр. Моны мин дә уйладым, ләкин алай түгел, чөнки Владивостоктан Цуругага рус пароходында палубадагы урын – 9 сум, беренче класс 28 сум тора, икенче класс бөтенләй юк. Ул мин сөйләп киткән аш табынына җыелу дигән нәрсә дә юк. Соңыннан рус пароходы белән килгәннәр белән күрешкәндә, боларның барысын да сораштым. Ә япон пароходында палубадагы урын – 8 сум, икенче класс – 18 сум, тагын әле ул теге аш табыны, аннан соң менә бу – юлчыларны һәм багажларын бушлай ярга чыгару. «Без юлчыларны коры җир өстеннән алдык, коры җир өстенә бастырабыз», – бу бик мантыйклы фикер.

Таможняны үтүгә, ике зур көпчәкле арба тарткан кечерәк кенә кеше яныма килеп басты. Әйберләремне арбасына төяде. Аннары миңа:

– Үзегез дә менеп утырыгыз, – диде.

– Мин алай әйберләр янына менеп утыра алмыйм.

– Алайса, теләсәгез, җәяү барыгыз, станция ерак түгел, – диде.

Башка юлчыларны күзәтәм: багажларын төяп бетерүгә, үзләре дә менеп утыралар. Тик минем, ничектер, моңа күңелем риза була алмады. Шулкадәр әйбер дә төя, инде үзең дә менеп утыр. Аннары арбаны минем кебек үк кеше тартып барсын.

– Бу болай булмас, минем өчен башка бер арба чакыр, – дидем. Чакырды, менеп утырдым. Шулай арбага кеше утыртып ташучыларга «рикша» яки «гүрүмә» диләр икән. Тимер юл станциясенә таба кузгалып китәбез дип торганда – 18 яшьләрендә бардыр – бик матур киенгән бер яшь егет миңа русча: «Теләсәгез, Сезне озатып куйыйм», – дип эндәште. Шунда гына башыма барып җитте: тел белмим бит, бергә барсак, файдасы тими калмас шул. «Әйдә, алайса», – дидем. Әйтеп тә бетермәдем, әйберләрем төялгән арбага менеп тә утырды. Таможнядан унбиш-егерме адым җир киткән идек, сул якта, бакча эчендә торган зур пушкага күзем төште. Егет тә бер миңа, бер пушкага карады, көлемсерәде. Арбаларны тартып баручы кешеләр, ат кебек чабып диярлек, бик кызу баралар. Шул арада станциягә дә килеп җиттек. Мине озатып баручы ул егеткә: «Бу арбачыларга күпме

түлим икән?» – дип сорадым. «20 тиен бирсәгез, бик риза булырлар. Фәкыйрь кешеләр...» – диде.

Бирәдәге станция кечкенә генә бер җир. Билет саталар. Тик поезд-фәлән әлегә күренми.

Ул арада егет миңа: «Теләсәгез, әйдәгез, теге юлда күренеп калган пушканы карап киләбез. Сугыш вакытында Русиядән әсир төшкән пушка ул», – диде. Мин барырга телим, ләкин әйбер күп, авыр. Аннары вагонда урын да алып каласы бар. Егет, моны аңлагандай: «Борчылмагыз, сезнең әйберләрегезгә беркем дә тимәс. Вагонда да урын һәрвакыт була. Билет бирделәр, урын да бирерләр», – диде.

Киттек. Искиткеч зур пушка. Петербург янындагы Кунпин заводында ясалган тупларның берсе, ди. Егеттән: «Моны ник монда куйганнар? Бу кечкенә генә бер җир, шәһәр-фәлән дә түгел», – дип сорадым. Ул миңа: «Әйе, кечкенә генә авыл, ләкин чит илләрдән һәр көн менә бүгенге кадәр кеше килә. Иң беренче булып күзләре төшәчәк нәрсәнең бирәдә булуы бик мөһим. Күпме порт бар, һәммәсендә дә менә шушындый бер пушка тора. Хәтта бөтен ил буйлап, авылларның күбесендә нинди дә булса бер сугыш ядкяре, милләтнең батырлыгына дәлил булырлык бер истәлек куелган», – дип җавап бирде.

Ун минут та үтмәгәндер, кабат Тишабә станциясенә килдек. Станциядә юлчылар күбәйгән, поезд да килгән. Егет шунда ук йөгерде, күземнән югалды. Биш минут та үтмәгәндер, килеп: «Рәхим итегез, урыныгыз әзер», – диде. Вагонга кереп урнашкач, хәзерләнгән хатларым бар иде, шуларны егеткә биреп: «Зинһар, шуларны почтага бирегезче», – дидем. (Бирәдә шуны искәртеп үтәргә телим: почта – юбин, ящик – баку, марка – кетди, һичберсе чит ил сүзе түгел, игътибар итегез!)

Егет мине вагонга урнаштырды, вактөяк әйберләремне йөк вагонына тапшырды. Әйберләр җыеп бәйләнмәгән дә иде, шулай булса да йөк вагонына алдылар, барып җиткәч, берсе генә дә югалмаган хәлдә кире кулыма тапшырдылар. Менә, әгәр игътибар итсәк, милләтнең ышанычлылыгы беренче адымда ук, кечкенә генә бернәрсә аша да мәгълүм була ала. Русиядә, таралган нәрсәне түгел, сандыкка тутырылган әйберләрне дә – әгәр шартларына туры китереп, ныгытып бәйләнмәгән булса – кабул итүләре мөмкин түгел. Нигә? Ышаныч юк, чөнки әйберләр һичшиксез югалачак. Безнең төрекләрдә дә, Хиҗаз тимер юлында, сәүдәгәрнең зур итеп җыеп төйнәлгән йөге югала – тимер юл идарәсе моңа җаваплы түгел, японнарда исә, юлчының кулыннан кулчатыры (зонты) югалса да, тимер юл идарәсе җаваплы. (Аерма бик аз ... – *Габдерәшит Ибраһимов искәрмәсе*).

Моннан тыш, һәр юлчының 60 кило йөген бушлай ташыйлар, Русиядә исә, түләүсез ташыла торган йөк 13 укка[1] тәшкил итә. Болар һәммәсе дә халыкка уңайлык тудыру өчен эшләнгән нәрсәләр.

Аерылышыр алдыннан, егет: «Хәзер Сез Йокохамага китәсез. Дүрт сәгатьләп юл үткәннән соң, Майбара станциясендә күчеп утырырга кирәк булачак. Станциягә башта тиз йөрешле поезд киләчәк, әгәр тагын 1 йен түләп, бу поездга утырсагыз, бүген кичкә Йокохамага барып та җитә аласыз. Әгәр аның артыннан киләчәк юлчы поездын көтсәгез, ул алты сәгатькә соңрак барып җитә, Йокохамага иртәгә генә барып җитә аласыз. Безнең Японияда һавалар бик үк җылы түгел, бераз суык була», – диде.

Аерылганда, мин егеткә 50 тиен рус акчасы бирдем, егет карап та тормады, кесәсенә салды, аннары ике-өч тапкыр иелә-иелә саубуллашты. Карагыз инде: үзе йөк ташучы сыйныфыннан булган

[1] Укка – 1,282 килограммга тигез авырлык үлчәү берәмлеге (тәрҗ. иск.).

бу яшь кеше иленә килгән чит-ят кешегә нинди матур мөгамәлә күрсәтә.

Инде килеп, кеше боларны күреп, үлчәп карагач: «Соклангыч кешелеклелек!» – димичә кала аламы?! Безнең Русиядә йөкчеләр русларның үзләренең дә җаннарын алалар, чит-ят кешегә түгел, хәтта үз халкының бөек кешеләренә карата да әдәпсезлек итүләре мөмкин.

Поезд кузгалып китте. Вагонда европалы өч кеше бар, калганнары барысы да японнар. Өсләрендә миңа бик сәер булып күренгән киемнәр, күбесенең аякларында ак оекбаш белән ачык башлы, ачык артлы аяк киемнәре. Юлчыларның барысы да, безнең мөселманнар намаз кылганда ничек утыра – менә шулай утырдылар, ярты сәгать тә үтмәгәндер, барысы да – кулларында китап, газета – укуга талдылар. Вагоныбызны бераздан юл йөри торган китапханә дип атарга мөмкин иде. Тәрәзәләргә карап баручы ике европалы белән мин генә идем.

Юлның ике ягында да игътибарны җәлеп итәрлек манзара: сәер күренешле авыллар, тау башларындагы карлар, басу-кырлардагы яшеллек, күк йөзенең сафлыгы. Ноябрь башы, ә безнең өстә җәйге киемнәр. Аллаһының җире өстендә ник бер карыш буш калган җир кисәге күренсен?! Гел кыр, гел басу. Боларга юл буе игътибар итеп барам. Поездның тизлеге 35 км булырга тиеш, шуннан да артык түгелдер. Вагоннар тар һәм бик озын, тик чайкалмый да, селкенми дә. Болар да игътибарымнан читтә калмый. Билет тикшереп йөрүче дә юк. Бер сәгать, дигәндә, поезд беренче станциягә килеп җитте. Шау-шулы станция. Газета сатучылар: «Шимбон! Кокомин шимийон!

Ниҗи, ниҗи шимбон! Май ниҗи шимбон!» – дип кычкыралар, бар халык, поезд тәрәзәләреннән сузылып, газета сатып ала. Газетадан башка да нәрсәләрдер сата иделәр, нәрсә икәнен генә әйтә алмыйм.

Янымда утыручыларның берсе бер тартма һәм кәгазьгә төрелгән бер нәрсә чыгарды. Кечкенә генә чүлмәк кебек бернәрсә һәм ул чүлмәкнең өстендә каһвә чынаягына охшаш бер савыт та бар иде. Иң башта кәгазь төргәкне ачты – анысы балык икән. Агач тартмадагысы пылау булып чыкты. Күршем боларны ашаганнан соң, чүлмәкне алды: анысы чәй икән, чынаягы белән бергә. Юлчылар өчен махсус хәзерләнгән. Үзенең исе дә китми, ашап-эчкәннән соң, барысын җыйды да тәрәзәдән ыргытты. Шундый гына, искитәрлек җире булмаган нәрсәләрдән никадәр акча эшлиләр. Менә бу ягы бик әһәмиятле. Юлчылар өчен никадәр уңайлык тудырылган. Берәүнең дә вакыты әрәм булмый. Поезд да станциядә бары өч-биш минут кына тора. Бөтен Япониядә һәр станциядә шулай. Юл ризыгында шулпалы ашка кадәр бар, бераз кыйммәтрәк, ләкин хәтта бик матур бокаллар белән дә сатыла.

Кондукторлар юлда күзгә дә чалынмыйлар. Бары тик поезд станциягә килеп җитүгә, кулларына чүпрәк тоткан кондукторлар вагонның, тәрәзә пыялаларының тышкы яктан тузанын сөртәләр – әйтерсең лә бөтен вазыйфалары шул! Юлчылар да бик күп, вагон эчендәге арулык та искиткеч. 14-15 яшьләрдәге бер яшь егет – вагон эчендәге арулык сакчысы, юлчылар арасыннан берәү берәр нәрсә ташласа, шунда ук килеп ала, кемгә нинди ярдәм кирәк – шунда ук килеп хезмәт күрсәтә. (Чәйлек тә өмет итми. – *Габдерәшит Ибраһимов искәрмәсе.*)

Сәгать уннар тирәсендә поезд Майбара станциясенә килде. Барлык юлчылар да башка поездга күчеп утырырга тиешле икәнне әйттеләр. Без дә тиз генә вагоннан төштек. Экспресс поездның бер сәгатьтән соң киләчәген игълан иттеләр. Әйберләремне станциядә калдырдым да бераз Майбараны карармын дип киттем.

ЯПОН АВЫЛЫ МАЙБАРА

Биредә беренче тапкыр япон авылы күрәм. Авыл станция яныннан ук башланып китә. Станциядән чыгуга, авыл урамына карап торган мәйдан ачылып китә. Мәйдан уртасында кечкенә генә пыяла будка сыман бернәрсә тора. Карыйм: эчендә телефон бар. Кечкенә генә авылда телефон күрү мине бик гаҗәпләндерде, чөнки мин Русиядә телефоны булмаган бик күп шәһәрләр күрдем.

Авыл урамына кердем. Бер катлы кечерәк кенә өйләр, аларның урамга караган ягында гел кибет, арткы ягында яшәү урыны. Авылны бер башыннан икенче башына йөреп, карап чыктым: почта бар, телеграф бар, мәктәп тә бар. Урамнардагы арулык – искиткеч! Урамнарга су сиптергәннәр. Кеше, шушындый авыл күргәннән соң, шаккатмый нишләсен?! Бөтен авылда кибете булмаган ник бер өй булсын?! Урамнар – шәрык урамнары: тар, озын, өйләр бер-беренә тоташкан, нәкъ Истанбул өйләре кебек. Барысы да агач өй. Түбәләре – чирәп, өй эчендә дә, кибетләрдә дә артык әйбер юк: бер үрелгән чыпта һәм бер чүлмәккә охшаш мангал тора. Шул кечкенә генә авылда да күзгә ташланырлык нәрсәләр бар иде. Барысы да кибетләрендә газета укыйлар. Өсләрендә безнең элеккеге татар киеменә охшаган озын күлмәк, хатын-кыз киеме белән ирләрнең киеме әллә ни аерылмый. Барысы да билбау бәйлиләр икән. Хатын-кызлар билбавы күбесенчә ефәк һәм киң. Ирләрнең чәчләре кырылган, баш киеме дә кимиләр.

Сәгать унбер туларга биш минут калган иде, станциягә килдем. Ике минут та үтмәгәндер, тиз йөрешле поезд килеп тә җитте һәм без вагонга мендек. Бераздан Майбарадан Йокохамага таба кузгалып та киттек.

Тиз йөрешле поездда барабыз: тимер юлның төзеклегенә, вагоннарның матур-

лыгына сокланам, поездның тизлегенә аптырап карыйм. Биредәге юлчылар да шактый дәрәҗәле кешеләргә охшап торалар иде.

Минем исә, үз-үземә җаһиллегемнән зарланып барудан башка чарам юк. Тел белмим. Бөтен кеше укый. Берәү дә минем киемемә дә, кыяфәтемә дә сәерсенеп карамый. Барысы да үзләре белән мәшгуль, башка бернигә дә игътибар итмиләр.

Безнең Русиядә булсамы?! Яки берәр Европа илендә булсамы?! Бар кешенең күзе ул мескен юлаучыга төбәлгән булыр иде, әле бәлки мыскыллап көләрләр дә. Шәрык мәдәниятендә исә, кешелеклелек бар. Минем игътибарымны җәлеп иткән тагын бер нәрсә булды: туалетлардагы арулык һәм су булу. Болар, гадәттә, мөселманнарда гына була торган иде. Вагоннарда юлчыларга комачау итәрлек берни дә юк.

Кичке сәгать унда Йокохамага килеп җиттек. Вагоннан төштем. Станция капкасына килеп җитүгә, багажга тапшырылган әйберләремне дә китереп бирделәр. Аннан бер рикша тотып утырдым. Әйберләремне башка бер рикшага бирдем дә шәһәргә таба кузгалып киттек.

Рикша шулкадәр кызу бара ки, бары тик ат кына шулкадәр тиз бара алыр. Урамнарда җәяү йөрүчеләр дә бар, рикша белән баручы, кайтучылар да аз түгел. Шәһәр урамнары электр утлары белән яктыртылган. Шул ук вакытта, Европа илләрендәге кебек төнне көнгә әйләндерерлек үтә якты фонарьлар да юк, гел 16 шәм көчендәге фонарьлар, төнлә йөрү өчен, болар гаять матур яктылык бирәләр.

Рикша белән нәкъ 40 минут барганнан соң, бер япон өе янында туктадым. Бу Европа ысулындагы отель түгел, шул ук вакытта гади генә өй дә түгел иде. Йорт хуҗасы килгән кешегә бүлмә бирә икән. «Минем өчен мондый җир кулайрак та булыр», – дип, бирегә урнашырга уйладым.

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе*

Дәвамы бар ■

ЯРМӘК ӘДИБЕ Г.-ХАЛИКЪ САДРИ

Айсылу Имамиева

Г.-Халикъ Садри (Габделхаликъ Гариф улы Садретдинов) 1890 елның 4 августында Самара губернасының Богорыслан өязе (хәзерге Самара өлкәсенең Келәүле районы) Иске Ярмәк авылында игенче гаиләсендә туа. Бик яшьли ятим калып, чит кешеләр кулында тәрбияләнә һәм кечкенәдән үк хезмәт белән көн күрә башлый: башта авылда, аннан соң Уфа, Баку, Самара, Оренбург кебек шәһәрләрнең төрле остаханәләрендә, нефть промыселларында эшли, авылдагы көтүче малайдан югары квалификацияле эшче-машинист, механик булып җитешә. Уфада чагында бераз вакыт «Галия» мәдрәсәсендә дә укый.

1917 елгы Февраль инкыйлабы вакытында Г.-Халикъ Садри, большевиклар ягында торып, революцион көрәш хәрәкәтенә кушыла. Октябрь көннәрендә Самара шәһәрендә Совет хакимиятен урнаштыру һәм Идел буен акгвардиячеләрдән азат итү өчен барган сугышларда катнаша. 1918 елның маенда Самарада татар телендә чыга башлаган «Киңәш» исемле газетада эшли, аннан соң, 1919-1922 елларда, партиянең Самара губерна комитетында татар-башкорт секциясе рәисе була. 1920 елда ул, татар халкы вәкилләреннән берсе буларак, Мәскәүдә Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын игълан итү турындагы тарихи Закон проектына кул кую тантанасында катнаша.



1925-1928 елларда Г.-Халикъ Садри Казанда Татар коммунистлары университетында (ТКУ) укый, аны тәмамлагач, озак еллар Казанның «Спартак» аяк киемнәре фабрикасында һәм башка сәнәгать оешмаларында җитәкче урыннарда эшли, актив җәмәгать эше алып бара. Бу чорда ул уйлап табу һәм хезмәтне рациональләштерү өлкәсендә дә нәтиҗәле эшли, шул мәсьәләләр буенча фәнни-популяр характердагы дистәгә якын брошюра язып бастыра («Электромонтер», 1926; «Электрик серләре», 1928 һ.б.).

Ватан сугышы елларында Г.-Халикъ Садри, полк хәрби комиссары буларак, фронтның алгы сызыгында көрәшә, яралана, сугыштагы батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз, II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары һәм медальләр белән бүләкләнә.

Сугыштан кайткач, Г.-Халикъ Садри СССР Әдәби фондының Татарстан Язучылар берлегендәге вәкиле булып эшли. 1950 елда «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнә.

Г.-Халикъ Садриның әдәби иҗат эшчәнлеге 1917 елгы Октябрь инкыйлабына кадәр үк башлана, 1913 елда Уфа матбугатында аның «Тегермәндә» исемле беренче хикәясе басылып чыга. Иҗатының башлангыч чорында ул әдәбиятның барлык жанрларында диярлек каләм көчен сынап карый: шигырьләр, сәхнә әсәрләре, очерк һәм хикәяләр яза. 1919 елда иҗат ителгән «Унике ел төрмәдә» исемле пьесасы шул елларда сәхнәләрдә дә куелып йөри.

Г.-Халикъ Садри утызынчы елларда үзенең әдәби иҗат эшчәнлегендә төп урын тоткан проза әсәрләрен – «Ил батырлары» (1934), «Тимерче малае» (1935) һәм «Безнең таң» (1937) исемле повестьларын яза. Сюжетлары әдипнең үз башыннан үткән хәлләргә, үзе кичергән вакыйгаларга нигезләнгән бу әсәрләрендә автор революциягә кадәрге авыл крестьяннары һәм эшчеләр тормышын, алар арасыннан чыккан яшь геройларның, сыйнфый бәрелешләрдә чыныга-чыныга, иске тормыш тәртипләрен җимереп, яңа тормыш төзү өчен көрәшүләрен сурәтли.

Әдипнең сугыштан соңгы әдәби иҗатыннан «Йөзмә госпитальдә» (1950) исемле очерк-хикәясен, драматург Әнәс Камал белән берлектә язган «Юллар» (1950) дигән сәхнә әсәрен күрсәтеп үтәргә мөмкин. Шулай ук аның курчак театрлары өчен «Камал бабай әкияте» (1951) дигән пьесасы да уңыш казана.

Ул 1955 елның 8 мартында Казан шәһәрендә вафат була.

Г.-Халикъ Садри – 1939 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

***

«Безнең таң» повесте укучыны XX йөз башына алып китә. Ил, халык алдында торган зур үзгәрешләр, инкыйлаблар чоры... Автор алар хакында тарих китапларыннан укып, кеше сөйләгәннәрдән генә ишетеп белми. Ул үзе шул вакыйгалар үзәгендә кайнап яшәгән, аларда турыдан-туры катнашкан кеше. Шуңа да инкыйлабны, Гражданнар сугышын үз тәҗрибәсенә таянып тасвирлый. Бу исә әсәрнең кыйммәтен бермә-бер арттыра. Әлбәттә, аның әсәрләрендә социалистик реализм рухы чагыла. Шулай да Г.-Халикъ Садриның ил тормышындагы борылышларны үзенчә тоя белүе, аңлатып язуы укучыларны җәлеп итә. Әдип XX гасыр башындагы үзгәрешләрнең котылгысызлыгын, кирәклеген аңлаган һәм аларның тормышка ашуы инкыйлаб юлыннан киткәндә генә мөмкин дип ышанган. Бу – ул сайлаган юл. Әлбәттә, хәзер ничә дистә еллар узганнан соң без бу хакта төрле фикерләр әйтә алабыз. Әмма ул чорда яшәгән кешеләрнең зур максатлары булганлыгын һәм аларның үз идеалларын тормышка ашырырга өмет итеп яшәгәнлекләрен инкарь итә алмыйбыз. Аларны көрәшче рух, лаеклы киләчәк хакындагы хыял берләштергән. Игътибарыгызга «Безнең таң» повестеннан бер өзек тәкъдим итәбез.

БЕЗНЕҢ ТАҢ

Г.-Халикъ Садри

Дим.

Матур Дим суы.

Иркен, ямьле табигать эченә чыккач, чыдамадым:

– Их! – дип кычкырып җибәрдем.

Әйе, Дим буе матур, ямьле иде. Тик безгә анда нәрсәдер җитми кебек. Заһидә дә шулай ди. Ул Димгә карап сөйли, аның да сүзләрендә сагыш бар.

– Габдулла, кара инде, нинди матур борылып-борылып киткән, – ди ул, – әнә, дулкыннар берсен-берсе куып йөгерешәләр. Әнә, кара әле, Дим ярларын берәм-берәм барып юалар да кире төшеп югала баралар. Алар үзара шатланган төсле, үзара сөйләшеп көлешкән кебек. Тик нигәдер бөтен түгел, бер җире китек төсле...

Мин сүзсез генә табигатьне күзәтәм.

Әнә, болын. Их, андагы табигать! Әйтерсең, матур булыр өчен генә шулай төзелгән! Төрле-төрле чәчәкләр белән чуарланып, балкып торган болын матур да, моңлы да булып күренә. Анда-санда күренгән ап-ак шомырт чәчәкләре бакчаның гөле булып күзләрне иркәлиләр. Тал куаклары куенына яшеренгән сандугачлар өзлексез сайрап торалар. Якында гына «Кәккүк! Кәккүк! Кәккүк!» дигән тавыш ишетелеп, йөрәкнең әллә кай җирләрен өзеп җибәрә. Болын эчендә, чәчәкләр өстендә ак күбәләкләр куышып-куышып очып йөриләр...

– Матур... ямьле... ләкин моңлы, чынлап та, син әйтмешли, бер җире җитми! – дидем мин дә.

Заһидә бу сүзгә каршы авыр гына көрсенде:

– Безнең күңелләр китек, шуңа күрә шулай тоела. Без яшәргә телибез, ә безне тормыштан куалар. Әгәр дә синең тормышың шушы Дим буе кебек матур булса, күңелең күтәренке булса, син монда матурлык өстенә матурлык эзләргә генә чыгар идең. Ә без китек күңелне юатыр өчен генә чыктык бит!

– Шулай шул!..

Анда кемнәрдер ат белән чыккан. Матур куаклык буена үскән карт карама агачы төбенә ак чатыр корганнар. Чатыр эчендә ашыйлар, эчәләр, көлешәләр...

Яр буеннан барып көймәгә утырдык. Бу минем Заһидә белән бергә беренче мәртәбә көймәгә утыруым иде. Димнең көчле агымы теге якка туры гына чыгарга ирек бирмәде, шактый ук агып, икенче якка кыеклатып чыктык...

Көймәдән ярга төштек. Ярны менеп, кулымны Заһидәгә суздым да аның ак, йомшак кулыннан тоттым. Җитәкләшеп яр буенда бераз йөргәч, ап-ак чәчәкләргә төренгән шомырт агачы төбенә утырдык.

Заһидә минем алдыма ятып шомырт чәчәгенә кулын сузды, ләкин кулы җитмәде.

– Габдулла, әнә шул чәчәкне миңа өзеп бирсәнә! – диде.

Мин, үрелеп, өзеп бирдем. Башлап үзе иснәде, аннан соң минем борыныма куйды да:

– Нинди тәмле, иснәгәч, күкрәкләр иркенәеп киткән кебек була, – дип куйды.

Мин утырган җирдән генә, тирә-ягымдагы чәчәкләрне өзеп, букет ясарга тотындым, ә Заһидә, минем алдыма яткан килеш, күккә карап җырлап җибәрде:

«Дим буйлары да гына тугай-тугай,
Тугаенда сайрый бер тургай,

Иртә дә генә сайрый, кич тә сайрый,
Саргаеп ук үлсен, ди, бугай...»

Күңелем тулды. Заһидәнең күзләренә карадым һәм ике кулым белән биленнән кочаклап алдым. Заһидәнең күзләренә яшь килде.

– Дуслыкны бозасың киләмени? – диде ул, ачулы карап.

Мин ниндидер билгесез шатлыкны тою исереклегенә бирелгән идем. Заһидәнең ачулы карашыннан айнып киткәндәй булдым. «Чынлап та саф мәхәббәтебезгә тап төшерергә ярсынам бит, юләр», – дип уйлап куйдым да:

– Ярый, Заһидә, мин сиңа тимим, бу кадәр көчле ихтыярлы булганың өчен, кил, бер үбәм генә, – дидем.

Куаклык араларыннан чыктык. Матур Дим яры буйлап югарыга атладык.

Көн шулкадәр тын, шулкадәр матур – йомшак кына искән җилләр дә Дим буе һавасында бик нык сизеләләр, һаваның сафлыгын тоясың.

Шулай бара торгач, агачлар арасыннан көлешкән, сөйләшкән тавышлар колакка чалынып калды. Без, кинәт туктап, тыңларга тотындык.

– Күренмик, танышлар булыр, уңайсыз бит, – диде Заһидә.

Мин дә аның сүзен тыңладым. Читкә – болын эченә борылдык. Куаклар арасыннан үтеп, Димнең икенче тугаена таба барганда, агачлар арасыннан кинәт: «Габдулла, Габдулла!» – дигән тавыш ишетелде. Сискәнеп киттем. Әйләнеп карасам, бер куаклык янында Мостакыймов карап тора.

– Шул ич, шул, – дип аптырап калдым.

– Шул дигәнең кем соң? – диде Заһидә.

– Кем булсын, Мостакыймов!

Мостакыймов кулын бутап-бутап безне чакыра:

– Монда, монда килегез!

Уйлап та тормыйча, Мостакыймовка таба борылдык.

– Сез ни эшләп йөрисез, безне таба алмый йөрисезме әллә, без монда бит, барыбыз да монда! Тизрәк булыгыз, хәзер башлана! – дип, безне каршы алды.

Мин, берни дә аңламыйча:

– Нәрсә башлана, ничек барыгыз да монда? – дип сорадым.

– Нигә, син берни дә белмисеңмени әле? Мин бит сиңа язу калдырып чыккан идем, – диде Мостакыймов.

– Нинди язу, кайда?

– «Галия» мәдрәсәсенә калдырдым.

– Кайчан?

– Кичә.

– Һи, без аннан әллә кайчан куылып чыктык инде.

– Монда хәзер уен-көлке күләгәсе астында митинг – маевка башлана!..

Бу сүз безне шатландырып җибәрде. Мостакыймов артыннан куаклар арасына кереп киттек.

Без эшчеләр янына барып чыкканда, машинист Соткин, бер агач төбенә басып, ялкынлы тавыш белән:

– Хәзер төрле шәһәрләрдә эшчеләр забастовка алып баралар. Беләсез, тормыш чиксез авыр. Шуңа күрә эш ташлауны, хуҗалар алдына зур таләпләр куюны көн тәртибенең беренче планы итеп куярга тиешбез. Без үзебезнең теләккә эшчеләрне нык оештырган вакытта гына ирешә алабыз. Оешырга һәм көрәшергә кирәк! – дип сөйли иде.

Мин шунда иптәш Соткинның большевиклар партиясенең Уфа комитеты вәкиле икәнен белдем, бүгенге маевка да аның җитәкчелегендә оешкан икән. Бүген-иртәгә

таралачак прокламациянең дә проектын ул язган. Соткин тиз көндә баш күтәрергә чакырды.

Җыелышкан эшчеләр аның сүзләренә кушылганлыкларын белдереп шаулаштылар. Көчле «Марсельеза» тавышы кыска арада гына Дим буен яңгыратып алды.

Яңгырап җырланган җыр тирә-якта гөрләп торганда, кемдер кискен, ачы тавыш белән:

– Полиция! Казаклар! – дип кычкырып җибәрде.

Бер минут узмагандыр, эшчеләрнең күбесе Дим буе куаклыклары арасына сибелеп тә беттеләр. Ә калганнары гармун, гитара һәм балалайкалардан төзелгән оркестрга парлап-парлап биергә тотындылар. Соткин Кызыл байракны зонтик чехолы эченә яшерде дә таяк итеп таянды. Кайберләре ашамлык әйберләрен җиргә куйдылар, без дә яшел суган белән кабыклы бәрәңге ашап тамак ялгап алдык.

Заһидә белән без дә читтә карап калмадык. Толпа арасына кереп, Дим буен яңгыратып уйнаган оркестрга бии башладык.

Әллә остарак, матуррак биедек, безнең бию эшчеләргә бик ошады. Озак итеп кул чаптылар:

– Бис, бис, браво!.. – дип өзми дә куймый кычкыргач, икенче кат чыгарга мәҗбүр булдык.

Төрле уеннар уйнап, җырлап-биеп үткәрә торгач, көн дә шактый ук кичекте. Дим буена килеп таралган полицейскийлар, казаклар биюче-җырлаучы һәм төрлечә күңел ачучыларга килеп бәйләнә алмадылар. Тик, болын буена таралып, кичкә кадәр маевка эзләп, атларын кара тиргә батырып йөрүләре генә калды.

Кайтырга чыккач, Мостакыймов:

– Габдулла, икегез дә миңа, ярыймы? – диде. – Миңа кайтабыз, мин бүген Май бәйрәме кичәсе үткәрәм, Заһидәне җырлатырбыз, ә мин скрипкада уйнармын!

Без аңа иярдек.

Бу безнең күңелне күтәреп җибәрде. Бу вакыйгадан соң Уфада бер айга якын торып икебез дә урын таба алмагач, авылга кайтырга уйладык. Ул ел минем призывка караласы да елым иде.

Таныш эшчеләрдән, дус-ишләрдән юлга аз-маз акча табып, кайтырга әзерләндек. Һәм җыенып кайтырга чыктык.

***

Суыксу елгасы һаман бер көе ага да ага. Ул үз гомерендә бик күпне кичергән: матур болыннарында бик күп кешеләрнең рәхәтләнүләрен, бик күп, бик күпләрнең зар елауларын күргән.

Кайчак тын гына аккан ул, кайчак котырып-котырып үзенең текә ярларын ишеп-ишеп төшергән, җимергән. Язгы ташуларда бик күп күперләрне, тегермән буаларын агызып, әллә кайларга, әллә нинди җирләргә алып киткән...

Кайбер кешеләр аның матур-матур тугайларында печән чаптырган, печән җыйдырган. Бик күпләр шул матур тугайларга, котырып печән уңган болыннарга читтән генә карап кызыкканнар, читтән генә карап, моңлы тавышлары белән үзләренең кайгыларын җырлаганнар.

Әнә шул Суыксу буена мин тагын әйләнеп кайттым. Мине кайгы-хәсрәт белән озаткан Суыксу шулай ук кайгы-хәсрәт белән каршы алды да.

Мин кайтканда июнь башлары иде. Суыксу буе, нәкъ Дим буе кебек булып, яшеллеккә, матур чәчәкләргә төренгән.

Кошлар җыры, кәккүк моңы яңгырый. Әкрен искән җәй җилләре болын һавасын авыл өстенә китерәләр.

Канау буенда гәпләшеп утырган агайлар янына килгәч, исәнлек-саулык сорашкач, тирән сулап:

– Их, Ярмәкнең һавасы да һавасы... – дип куйдым.

Бу сүземә берәү дә кушылмады, авыр гына сулап куйдылар. Берсе авыр сулау белән генә калмады:

– Аның саф һавасын гына иснәмәсәң, башка нәрсәсе безгә тәтеми шул, – дип куйды.

Бу җәйнең матур озын көннәре гел Суыксу буенда үтте. Кояш күтәрелеп, көн кыздыра башлагач та, Суыксу болынының матур куаклары арасына чыгып, чәчәкләр белән тулы озын үлән арасына сузылып ятам да газета-журнал, яңа әдәбият укыйм. Күкрәкне киереп, иркенләп җырлыйм.

Җырларым, авылның икенче ягындагы Юкәле тауга бәрелеп, үземә яңадан кайтып ишетелә.

Көн эссесендә Суыксу ярына киләм... Ярдан карана-карана чишенәм дә, Суыксуның кайнап-кайнап аккан җиренә сикереп, чума-чума йөзәм. Ул үзенең салкынча суы белән көн эссесендә хәлсезләнгән тәнемә хәл кертеп җибәрә. Ләкин озак йөзә алмыйм, боярның балык тотучылары ирек бирмиләр, суның түбән ягыннан да, югары ягыннан да:

– Әй, балыкларны куркытасың, чык тизрәк! – дип кычкырып, кәефкә тап төшерәләр, күңел бозыла, йөрәк кузгала, ачу килә.

Ярмәк авылында, Суыксу буйларында йөргәндә, күңелем һәрвакыт урман каравылчысы өендә – Заһидәдә булды. Иртә торсам да, кичкә керсәм дә, һаман Заһидәне уйлыйм. Хәтта куаклык араларына чыгып әдәбият укыганда да Заһидә, күз алдыма килеп, күңелне үзенә тарта. Укый торган җөмләнең мәгънәсенә төшенә алмый кат-кат укып аптырап бетәм. Аптырагач, китапны бер якка куям да, Заһидә турында хыялланып, киләчәк көннәрне матур, ямьле итеп күз алдыма тезә башлыйм. Тик матур уйларны очларга өлгермим, солдатка алыну кылт итеп искә төшә. Матур хыялларның тузаны да калмый, аяк баскан җирем җимерелеп төшкән кебек була.

«Ничек калырга? Гомер бигрәк әрәм була бит!»

Шундый уйлар мине борчый. Ләкин аларга бирелмәскә тырышам: «Әйдә кадалмас ла!» – дип, кара уйларны күңелемнән куам.

Соңгы аерылышуда мин Заһидәгә берничә китап биреп, киләсе очрашуда ул китаплар турында сөйләшергә – фикер алышырга сүз куешкан идек. Очрашыр вакыт та җитеп бара... Мин сүз куешкан көнне җәяүләп Заһидәләргә барырга тиеш. Авылда Тавис абый җитәкчелеге астында оешкан яшьләр – Шаһит, Сафуан, Хәмитләр театр куярга әзерләнеп йөриләр икән. Мине дә үзләренә катнашырга чакырдылар. Тик хатын-кыз рольләрен башкару өчен кеше таба алмый аптырап беткәннәр. Мин бу эштә ярдәмгә килә алуымны аңлаттым:

– Мин табам, Тавис абый, менә дигәнне табам, урман каравылчысы Арслан бабайның кызы Заһидәне алып киләм, – дидем.

Алар бу сүзгә бик нык шатландылар.

Иртә белән Заһидәләргә китәргә карар биреп куйдым да кичен никрутлар белән урамга чыгып киттем. Гармунга кушылып җырлый-җырлый, түбән очка төшеп барабыз.

Су буенда карама,
Кисеп салдым чанага;
Кайгы-хәсрәт төшә икән,
Үсеп җиткәч, балага.

Без авыл очына җиткәндә, караңгы төшеп килгән чак иде. Басу капкасы ягында аркасына котомка аскан бер кеше күренде. Безне күргәч, яныбызга килде:

– Исәнмесез, егетләр! – дип, таныш тавыш белән кычкырып та җибәрде.

– Батыр абый! – дип барып кочакладым. Башкалар аны тиз генә таный алмый аптырап калдылар.

Бу хәл мине шулкадәр шатландырды, шулкадәр сөендерде ки, ни эшләргә белмәдем, бергә йөрергә чыккан иптәшләрем белән саубуллаштым.

– Егетләр, сез үзегез йөрегез инде, мин бүгенгә Батыр абый белән китәм, – дидем.

Батыр Ваһаповның төрмәдән котылып кайтып килүе икән.

Мин аны өенә кадәр озата бардым. Капка янына җиткәч, берсекөнгә генә күрешәчәгебезне белдереп, аның яныннан киттем...

Заһидәләргә барып кергәндә, өйләрендә Заһидәдән башка бер кеше дә юк иде. Заһидә ялгыз гына иңенә ачылган тәрәзә төбенә китабын куеп укып утыра. Ул мине күрмәс борын мин аны күрдем дә, агач араларына качып, аңа күренмичә генә баскычка таба уздым һәм, аяк очы белән генә басып, өйгә кердем. Заһидә сизмәде. Бик саклык белән генә якынлашып, ике күзен капладым.

Ул куркып китте:

– Абау! – дип кычкырып җибәрде һәм, мине танып алгач, иркәләнгән тавыш белән үпкәләргә тотынды:

– Габдулла, бу ни эшләвең инде? Егылып китә яздым бит! – дип кулын сузды, йөзе чыннан да ап-ак булганын күргәч, үзем дә куркытуыма үкенеп куйдым.

– Ялгыш, ялгыш, акыллым, болай куркырсың дип белмәгән идем, – дип, күкрәгемә кыстым.

Үземнең нәрсә өчен килгәнлегемне сөйләгәч, Заһидә шатланып китте:

– Була, Габдулла, була. Болай да синең авылны күреп кайтасым килә иде, – дип дәртләнеп куйды.

– Әти-әниләрең каршы килмәсме?

Заһидә бу сорауга аз гына да аптырап тормады.

– Театр куюны кем әйтә аларга? Кирәк булса, Заһитны да алып китәрбез, кунакка алырга килдем, диярсең. Театр куярга, дип, әйтсәң, картларның билгеле инде! – дип җавап бирде.

Арслан бабай урманда иде. Заһит белән Зәрига әби Усан авылына киткән булганнар икән, бик озак көттермичә кайтып керделәр.

Зәрига әби ишектән керүгә үк, Заһидә:

– Әни, Габдулла Заһит белән икебезне кунакка алырга килгән, ни эшлик, җибәрәсеңме? – диде.

– Кунакка? Җәяү бик авыр булмасмы соң? Авыр булмаса, барсагыз барырсыз шул. Ярмәкне күреп кайтырсыз.

Мин аны каршы килер дип куркыбрак тора идем, мондый уңай җавап алынгач, шатлыгым эчемә сыймады:

– Рәхмәт, Зәрига әби, рәхмәт, – дип, кат-кат рәхмәт әйттем.

Заһидәне күрдем исә, бөтен кайгыларым тарала да китә. Аларга бардың исә, көннең үткәнен сизми дә каласың. Кояш безгә үч итеп шулай тиз йөридер төсле тоела. Ни арада көн узгандыр, кич булып караңгы төшеп тә бара...

Ул кичне безгә йокы кермәде. Заһидә, Заһит, мин – өчәүләп таң атканчы сөйләшеп яттык. Заһидә белән без үзебез укыган политик китапларны ничек аңлавыбыз турында сөйләшә идек. Үзебез яшәгән тормыштан мисаллар да китереп сөйләгәч, Заһит та кызыксына, сораулар бирә, без аңа үзебезчә төшендерә идек. Таң атканда гына йокыга

киткәнлектән, иртә белән Зәрига әби үзебезне уята алмый аптырап беткән. Торсак, кояш төшлеккә җитеп килә. Тиз-тиз генә ашап-эчтек тә юлга чыктык. Урман эчендәге туры юл безне Ярмәккә таба алып китте.

Без авылга кайтып җиткәндә, театрга әзерләнүчеләр мәктәпкә җыела башлаганнар иде инде.

Чынлап торып театрга әзерләнә башладык. Безнең әзерләнгәнне Батыр абый да килеп карап торды. Мин кичә кич аның йөзенә бик дикъкать белән карамаган идем, бүген күреп исем китте: ябыккан, саргайган, битенә җыерчыклар чыккан.

– Нигә бу кадәр картайдың, Батыр абый? – дидем.

– Караңгы Россиянең сасы зинданнары шулай итте! – дип җавап бирде.

Барыбыз да аңа кызганып карап куйдык. Яхшы кешеләрне җәфа чиктерә торган патша хөкүмәтенә булган ачуыбыз артты.

Авылда сыйнфый каршылыклар көчәя бара. Кайсы гына ярлыга барма – зарлану, кемне генә күрмә – кайгы-хәсрәт ишетеп эчең поша.

– Фәлән кешенең самоварын, ястыгын язып чыкканнар...

– Налогны шушы атна эчендә түләп бетерергә, ди. Түләмәгән кешенең актык кәҗәсен алып чыгалар икән.

Ындыр арты Хәйретдин старостага:

– Үземне сатар идем, алучы юк, инде ни эшләргә кушасыз, – дигәч, актык кәҗәсен алып чыга башлаганнар. Ә Хәйретдин кәҗәсен, тоттырмас өчен, урамга куып чыгарган, шуның өчен аны җиде көнгә ябарга ясаганнар.

Авыл телендә шундый сүзләр йөри. Безнең театр куярга җыенуыбыз ишетелгәч, ул сүзләр өстенә тагын яңалары өстәлде.

– Биби малае Габдулла бөтенләй урыс булып кайткан. Китек якалы кыска бишмәт кигән. Ашаганда әгузе-бисмилла әйтми, ди. Аштан соң амин да тотмый, ди.

– Әле төятер уйныйлар, ди. Шул төятердә кызлар белән егетләр, халык алдында чыгып, кочаклашып үбешәчәкләр, ди...

– Тавис хәлфә шуның белән кешене агартам дип әйтеп әйтә, ди.

– Үткән төнне түбән оч ягында Юкәле тау үкергән. Мәчет башына кунып ябалак кычкырган. Озын күл суы улаган. Аны Котып хәлфә ишетеп, Ахун хәзрәткә сөйләгән. Ахун хәзрәт, бар да шул төятер бәласе, фетнә җәфасы, күзмә-күз, шәрран яра йөргәнгә кош-кортлар, җир-сулар да чыдамый башлады инде, дип әйткән, ди. Әйтсәң – сүз, төртсәң күз чыга, әйтә-әйтә дә арып беттем инде, төятер көнне авылны җир упмаса ярар иде, дип әйткән, ди...

Минем Заһидәне алып килүем бу гайбәтләрне тагын да куертып җибәрде. Авылның хәзрәт-муллаларына, Әхмәтҗан мәзингә, старшина-старосталарына, куштаннарына бер дә ярамады. Алар барысы да чынлап тотындылар.

– Габдулла көпә-көндез урман каравылчысының кызы белән җитәкләшеп йөри икән. Караңгы төшкәч, шул кыз белән мәктәп ишеге янында сөйләшеп торганнарын Котып хәлфә үзе күргән.

– Ул урман каравылчысы кызы да азып-тузып беткән бернәрсә икән. Маңгай чәчен Дубин марҗасыныкы кебек итеп кискән. Салам эшләпә киеп, бөтен чәчен ир-атка күрсәтеп йөргәндә йөзен дә чытмый. Ир-атка тәнен күрсәтеп йөрергә ничек оялмый икән. Хатын-кызга ике кулының бармак очларыннан башка җирен күрсәтергә ярамый бит инде, илаһым, нигә бу кадәр динне аяк астына салып таптыйлар икән. Шулар аркасында авыл харап була бит инде...

Без мондый сүзләргә игътибар итмәдек, һаман хәзерләнүебезне белдек.

Спектакль көне дә килеп җитте. Кулдан гына язып афиша тараттык. Спектакльне

карау буш иде. Соңгы репетициядән чыккач, Тавис абый, мин һәм Заһидә белән Заһит бергәләп Гөлгенә әбиләргә кайттык...

Берсеннән күреп икенчесе капка янына чыккан халык, аю биеткәнне күргәндәй, безне карый башладылар. Һәрберсе бер ачы сүз әйтеп калырга, Заһидәдән көләргә тырыша. Гариф хаҗи карчыгы, тәрәзәдән башын тыгып:

– Чәчен күрсәтеп йөрмәсә, башка кешедә чәч юкмы икәнни! – дип куйды.

Аннан башкалары эләктереп алды, чыдап кына тор.

– Укып йөрмәгән, чукып йөргәндер ул...

– Көпә-көндез җитәкләшеп йөрергә ничек оялмый икән?

– Бөтенләй марҗаларга охшаган бит! Мөэмин-мөселман кызына охшасам, мөселман кызы, дип әйтерләр, ди торгандыр.

Заһидә шабыр тиргә батты, Гөлгенә әбиләргә барып кергәч, «уф» дип көрсенеп куйды. Ни әйтергә белми аптырап, без көлешеп куйдык.

Гөлгенә әби дә кайгыга төште:

– Сез дә юкка гына мәшәкатьләнеп йөрисез. Барыбер эшегез барып чыкмас, Әһлулла мулла әйтә, ди, тәятергә бару – хәрам, аны барып карау – зур гөнаһ, дип әйтә, ди. Беркемгә дә барып карарга рөхсәт итмәгән. Үткән көнне шомлы бер төш күрдем, мәктәп тирәсен җир упмагае, андый бозык җиргә барып харап була күрмәгез, дип әйтеп әйткән, ди. Старшина да шуны куәтли икән: пристафтан рөхсәт алмаганнар, андый бисмилласыз китапны куярга безнең патша рөхсәт бирми икән, үрдниккә хәбәр иттем, дип әйткән, ди.

Заһидәгә карчыклар күлмәге кирәк иде. Гөлгенә әбинең дә күлмәге икәү генә булып чыкты. Аның да берсе – киндер. Таба алмый аптырап беттек.

Гөлгенә әби берничә карчыкка кереп чыкса да, буш кул белән кайтты. «Юк, юк, намаз укый торган күлмәгемне пычратыр хәлем юк», – дип кенә кычкыралар икән. Күлмәк таба алмыйча тәмам гаҗиз булгач, Заһидә ахыры Гөлгенә әбинең шул киндер күлмәген кияргә булды.

Кич җитте. Мәктәпкә бардык. Халыкны көтәбез. Беркем килми. Берничә малай килгән иде, аларны да ата-аналары кыйнап алып кайтып киттеләр.

Хатыны белән Батыр абый килде. Никрутлар гармун күтәреп килеп керделәр. Без һаман спектакльне башламый халыкны көтәбез. Беркем дә килмәгәч, бары белән канәгатьләнеп пәрдәне ачарга гына әзерләнгән идек, старшина, урядник һәм староста белән берничә куштан килеп керделәр.

Куштаннар, керүгә үк, кычкырышып килеп, безне кыйнарга итә башладылар. Ләкин мин курыкмадым, батыр тавыш белән урядник өстенә кычкырдым:

– Безне кыйнатырга алып килдегезме бу кешеләрне? Кулыгызны күтәрәсе булмагыз, курыкмыйбыз!

Урядник барыбызның да исем-фамилиябезне язып алды. Китапны, Тавис абый кулыннан алып, кыршылып беткән папкасына салды:

– Оештыручылар, энең белән син, диләр, иртәгә волостька минем янга барырсыз! – дип чыгып китте.

Спектаклебез шуның белән очланды. Старшиналар килеп кергәндә, Заһидә киенеп, битләрен гримлап ята иде. Ул тактадан гына тезеп ясаган сәхнә артына кереп качкан. Шуңа күрә исемлеккә аның фамилиясе керми калды.

Икенче көн таң аткач ук Заһидә белән Заһитны өйләренә озата киттем.

*Текстны басмага **Айсылу Имамиева** әзерләде.* ■

Безнең мирас №6 июнь 2019



ЙОЛДЫЗНЫҢ НУРЛЫ УЛЫ

Рабит Батулла

Бу мәкаләне язганга 17 ел узган да киткән. Рөстәм Мингалимнең вафатына да биш ел үткән, ул 77 яшендә бакыйлыкка күчте. Урыны җәннәттә булсын!

Ул исемнәр дә алды, Г.Тукай бүләге иясе дә, Халык шагыйре дә иде. Ул шәкертләрнең остазы да булды, ләкин шушы шатлыклар, сөенүләр килсә дә, Рөстәм, ялгызы калгач, моңга-сагышка бата иде. Миңа калса, ул туган авылының юкка чыгу кайгысын шулай авыр кичерде. Бу сагыш аның йолдыз кебек нурлы йөзен бозмый иде. Гүрең нурлы булсын, Йолдыз авылының нурын үзенә алган Шагыйрь Рөстәм Мингалим!

---

*Язма басмага кыскартып бирелде (ред.)

Мәшһүр шәхесләребезнең туган авылларына барган саен, зиярәтчеләрне уртак бер хис биләп ала. Бу хис – сагыш, һәр кеше, туган авылына кайткач, шундый хис кичерәдер, мөгаен. Сабый чактагы авыл үзгәргән, табигать фәкыйрьләнгән, изге йолалар онытылган, кешеләр дә алмашынган, зират – ташландык. Такташның Сыркыдысына баргач, сыкрап кайттык, анда Мокамайның эзе калмаган, анда Шәйхи карт каравыл торган авыл Советы юк, Такташ фамилиясе еш очраса да, Такташча сөйләшмиләр. Таракан авылы бөек сәнгатьче Кәрим Тинчуринны тудырган да үзе инкыйраз алдында тора.

Әгәр шагыйрьне тудырган авыл юкка чыкса, нишли икән аның шагыйре? Кайчандыр гөрләп торган авыл урынына, зиратын тракторлар белән сөреп, ашлык чәчелгән. Шул басуга карап торучыны сагыш баса, күңелдәге бер җеп өзелеп, анда хасталык пәйда була.

Рөстәм Мингалим туган Йолдыз авылы Русия харитасында инде күптән юк. Ул авыл җир астына да убылмаган, аны шүрәле дә каргамаган, янмаган да, бу матур авыл – гарип сәясәт корбаны. Йолдызны Совет аждаһасы йоткан.

Аның «чирәмле урамы да, казлары да, коедан чылдыр-чылдыр су алучы кызлары» да юк хәзер. Йолдыз авылы шагыйрь Рөстәм Мингалимне дөньяга тудырып, үзе үлгән.

Туган авылының инкыйразга дучар икәнен шагыйрь күңеле алдан ук сизенгән кебек. Шушы сагыш Рөстәм Мингалим иҗатының буеннан-буена дәвам итә:

Аэродром иде безнең авыл:
Казлар күтәрелде каңгылдап,
Бурәнәгә утырып сөйләштек бер:
Мин китәргә булдым авылдан.
Кайбер агайларга үпкәләдем, –
Булмагангадырмы әтиләр,
Безнең колакларны еш бордылар,
Авыр-авыр сүзләр әйттеләр...

Шагыйрь гомере буе авылының дәвамы булып яши:

Үтә идем бик кечкенә
бер ташландык авылдан.
Исәнме, – дим. Дәшмәде ул, –
теле кисеп алынган...
...Чырык-чырык, чорны мактап,
чыпчыклар оя кора...
Күзләре чокып алынган
карт кебек, мәктәп тора...

Рөстәмнең шигырьләре нигездә сагышлы булса да, алар җиңелчә елмаю, хәтта сатирик көлү хиссиятенә дә уранган. Инкыйразга йөз тоткан ташландык мәктәп, ташландык йортларның чормасына оя корып, «чырык-чырык чорны мактап» чыпчык халкы кайнаша. Бу – шагыйрьнең сатирик елмаюы, совет чынбарлыгыннан астыртын гына көлүе түгелме?! Такташ әйтмешли, тавыклар да «салам ояларга Совет өчен ап-ак йомыркалар салдылар».

Китәме үрдәге, –
саргая су камышы.
Камышларга җил киселә,
җанга үтә тавышы.

«Яшь ленинчы» газетасында эшләгән чак. Рәсемдә (сулдан): Рөстәм Мингалим, Фирая Маликова, Саимә Ибраһимова, Рәйсә Яхина, Ренат Харис, Илгизәр Сәмигуллина. 1970 нче еллар

Шушы кечкенә бер шигъри кыйтга турында гәзит битләрен тутырып нәсер язарга булыр иде. Шагыйрьнең асыл шигыре көчәнеп шагыйрь булырга маташучының тезмәләреннән күрер күзгә үк аерылып тора. Уйламаган, көчәнмәгән шагыйрь, шундый җайлы, шундый җиңел генә язган да ташлаган кебек күренә әлеге шигырь. Кайдан килә соң бу шигъри куәс шагыйрьгә? Укымышлы булганнанмы? Алай дисәң, университет-институт тәмамлаганнар бихисап, шагыйрьләр сирәк. Кайда укыталар шагыйрь булырга? Кайда укыталар сәләтле булырга? Җилкәннәр җилдә шаулый, камышлар җил искәндә кыштырдаша. Ә менә җилнең камышка тиеп киселгәне турында бер генә шагыйрьнең дә язганы юк иде. Рөстәмнең шигъри куәсе камышларны тибрәткән җилне телгәләнгән, кискәләнгән килеш күрә.Телем-телем кискәләнгән җилнең тавышы шагыйрьнең йөрәген телгәли, җанын кыя. Якын кошы – үрдәге чит җирләргә очып китәр алдыннан, аерылышу сагышыннан су камышының саргаюы да Рөстәм Мингалим иҗатында гына булырга мөмкин. Абстракт фикер йөртү, образлар белән эш итү ул нәселдән, каннан, йолалардан, борынгы җырулардан киләдер. Рөстәмнең әнисе халык авыз иҗатын яхшы белүче иде, мәрхүмә, авыр туфрагы җиңел булсын. Рөстәм әнә шул йола, җырулар мохитында үскән шагыйрь:

Ничек йөрмәсен хәтердә,
хәтердә терәк таулар,
безне тирбәткән каеннар –
ничек онытылсын алар.
Бала чакта ук сагынып,
безгә тимәгән тиңнәр...
Ничек йөрмәсен хәтердә
йокы кермәгән төннәр...

«Яшь ленинчы» редакциясенә Мәскәүдән кунаклар кайткан. Рәсемдә (сулдан): Саимә Ибраһимова, Рөстәм Мингалим, Туфан Миңнуллин. 1975-1977 нче еллар

Рөстәм – җирсү шагыйре. Җирсү ул – котылгысыз рәвештә, туганнарны, йолаларны, балачакны сагыну, җирсү ул – котылгысыз рәвештә, тарихны, узганнарны юксыну хисе:

Су кебек уза туйлар,
туй кебек уза еллар.
...Елмайсаң да
кулың болгап,
йөрәгең сулгып елар...

Рөстәм Мингалим турында «сагышлы, җирсүле шагыйрь» дип яздым да, үзем аптырап куйдым, бу сүзләрне күңеле төшенке дип аңламаслармы? Берүк аңлый күрмәсеннәр, Рөстәм кебек киләчәккә якты өмет белән караучылар сирәк була. Ул якты өметен сабыйларга (сабыйларга гына түгел!) менә шулай аңлата:

Яфрак хәтле генә ярату!
Урнаша да кереп күңелгә,
яшел урман булып куера,
бөтен дөнья шуңа күмелә.
Мин дөньяны шулай яраттым...

Рөстәм Мингалим 60 нчы елларда шигърияткә йолдыз кебек килгән якты иҗатлы шагыйрьләрнең берсе. Кызганыч, аның олы иҗаты турында мәкаләләр күп түгел. Әдәбият белгечләре, тәнкыйтьчеләр, студентлар киләчәктә бу бушлыкны тутырыр, дигән өмет бар. Чөнки Рөстәм Мингалимнең иҗат хәзинәсе бик бай. Аның иҗатына фәнни эшләр багышлап булыр иде.

Рөстәм Мингалим



ҮПКӘЛӘРМЕН КЕБЕК

Хатадырмы, юкмы,
һич сөйләмим көлеп:
Миңа Татарстан
Җир үзәге кебек...

Йөрим кайчак чыгып,
күп шәһәрләр күреп,
Казан шәһәрләрнең
иң гүзәле кебек.

Сорасалар әгәр,
бирә алмам бүлеп:
Мәскәү Татарстан
шәһәредер кебек.

Мин дөньяны сөйдем,
дөнья торсын белеп:
Ул да Татарстанның
бер өлеше кебек!

Хаталанма, диеп
әйтсә кемдер көлеп, –
Шул кешегә мәңге
үпкәләрмен кебек.

1973 ■

Остаз һәм шәкертләр. Рәсемдә беренче рәттә (сулдан) – Равил Фәйзуллин, Сибгат Хәким, Ренат Харис; икенче рәттә – Гәрәй Рәхим, Рөстәм Мингалим, Рәдиф Гаташ. 1970 ел

---

*Татарстанның халык шагыйре Рөстәм Мингалим (Рөстәм Гали улы Мингалимов) 1937 елның 15 августында Самара өлкәсенең Камышлы районындагы Йолдыз авылында туган. 2014 елның 1 июнендә Казанда вафат булды.

Безнең мирас №6 июнь 2019

ФӘТХУЛЛИННАР ЭЗЕ

Әхтәм Зарипов

Габдулла Фәтхуллин авыл карты ролендә (К.Тинчурин «Казан сөлгесе»). 1956 ел

Язмама шундый исем куйдым да, сагаеп калдым: бармы соң ул эзләр? Булса, кайда һәм ничек саклана лар?

1916 елда туып, 2001 елда бакыйлыкка күчкән артист Габдулла Фәтхуллин – аны Камал театры спектакльләрендә күргән тамашачылар күңелендә һәм аның белән бергә иҗат иткән артистлар хәтерендә гаҗәеп үзгәрү талантына ия актер, бәйсезлекнең кадерен белүче шәхес, күргәнен һәм уйлаганын яшерми әйтүче әңгәмәдәш буларак онытылмас кеше.

...Иҗади шәхес буларак, Габдулла Фәтхуллинның сәхнәдәге башкалар кабатлый алмас, үзенчәлекле эзләрен аяусыз вакыт та, һөнәри варисларының аның уенын кабатларга омтылышлары да җуйдыра алмас. Ул бар иде, бердәнбер иде.

Габдулла абый хәтерләрдә үзенчәлекле үзгәрү (перевоплощение) талантына ия артист, рухы белән ирекле шәхес буларак саклана. Иҗат кешеләре арасында андый шәхесләр сирәк очрый. Ул хөрмәткә мохтаҗ түгеллеген яшермәүче серсез кеше иде. Сансыз түгел – серсез.

Кайсы акыл иясе язганны укыганмындыр – хәтердә калган фикере шул: кеше буларак кешелеген аңлаган кеше, нинди генә байлыкларга һәм дәрәҗәләргә ия булмасын, әгәр дә ул башкалар күңелендә, бигрәк тә үзеннән башка кешеләрнең аңында үзе теләгән дәрәҗәле урынны биләми икән, аның уенда һәм күңелендә һәрчак шуңа омтылу өстенлек итәчәк.

Акыл иясе буларак, кеше нинди генә талантка, дәрәҗәләргә, сәламәтлеккә ия булса да, башкалар аңында башка кешеләрдән үзгә итәрлек бер үзенчәлеккә ия түгел икән – ул үзен оешмаган, өлгермәгән кешегә санаячак.

Миңа калса, Габдулла абый Фәтхуллинда үзен җитлекмәгән кешегә санау уе, кешеләр аңында үзенә уңайлы урын биләргә омтылу, гомумән, юк иде. Ул үзенең ничек бар – шулай кабул ителүеннән канәгать, ниндидер битлек-кабык астына керүне теләми дә, белми дә иде.

Һәр кеше башкалар турында фикер йөрткәндә, аны кылган гамәлләре, әйткән фикерләре буенча бәяли. («Акыллы иде», «эшчән иде», «усал иде», «киреләнүче иде», ди).

Габдулла абый белән турыдан-туры бәйләнешкә кереп иҗатташ буларак эшли башлавым 1961 елның көзендә, Әхмәт Ерикәйнең «Җәүһәрия» поэмасы буенча радиоспектакль әзерләгәндә булды. Артист буларак аны «Татар хатыны ниләр күрми» спектаклендә күреп сокланганлыктан, поэма буенча радиоспектакльдә дә аннан шундый уңышлы образ көтүемне белдергәч, ул миңа рольне кире биреп, андый эшкә бармаячагын белдерде: «Беренчедән, әсәрләр икесе ике дөнья, икенчедән, поэзияне инсценировать итү өчен драматик конфликт табылу тиеш, монда, конфликт ясыйм, дип, поэзия югалган. Шигырьнең бар кыйммәте поэзиядә булганлыктан, инсценировка төссез, иссез чәчәк кебек: чебен дә кунмый аңа, бал кортлары да читләтеп уза. Шигырь уку кәсепчеләренә биреп укыт. Әгәр инде миннән баш тартмыйм, дисәң – инсценировкаңны яңадан эшлә. Шигъриятне корбан итсәң, драматургияң үзен акларлык булсын!»

Инсценировканы өр-яңадан эшләп, радиоспектакльне куйдык. Аны тыңлагач, эшебезне хуплап, автор Әхмәт Ерикәй язган хат архивымда саклана. Үзгәртүләргә тулысынча ризалыгын белдерә ул.

Габдулла абый Фәтхуллинның усал холкын белсәм дә, мин аны тагы Хәсән Туфан шигырьләре буенча композициядә Хабул роленә чакырдым. Бу эшемдә ул, сценарийга бәйләнеп кенә тукталмады, кайсы рольгә кемне чакыру буенча да киңәшләр бирде. Һәр ике радиоспектакль дә фондта саклана. Аларда, режиссер буларак, минем эшемнән дә бигрәк, артистлар эше ачык күренә һәм Габдулла абыйның һәр эшкә җаваплы каравына ачык мисал булып тора.

Г.Фәтхуллин – Хөсәй, Дәллюс Ильясов Бакый рольләрендә (М.Фәйзи «Ак калфак»). 1951 ел

Театрның «Казан сөлгесе» спектаклендә ишан ролен уйнаучы Газиз Зыятдинов, мәчеттә онытып калдырылган сөлге табылгач, гөнаһлыларга нинди җәза бирү турында вәгазь сөйли. Гөнаһ ияләренә таяк белән бер сугу ничә сумлык сәдакага тиң булуын кисәтә. Массовкада уйнаучы артистлар, «ах-ух» килеп, җәзаның катылыгын расларга тиешләр. Шау-шуны исемсез рольне уйнаучы Габдулла абый туктата: «Хәзрәт, хәзрәткәем, минем сәдака бирерлек рәтем юк, ул гөнаһ ияләренә шушы таягым белән мин дә бер-икене кундырырмын әле», – ди. Ишан «рөхсәт» итә.

Без шушы күренешне көтеп ала идек. Без генә түгел, тамашачылар да, шушы эпизод уйналгач, озаклап кул чаба һәм рәхәтләнеп көлә иде. Кайсыдыр бер спектакльдә, әллә онытып, әллә юри, Габдулла абый ишаннан сугу «рөхсәтен» сорамый. Тынлык урнаша. Спектакль иң кирәкле урында кинәт өзелеп, тукталып кала. Кемдер, Габдулла абый кебек, «таяк белән сугарга» рөхсәт сорый... Тик бу сорауны ишетүче генә булмый. Кул чабулар да, рәхәтләнеп көлүче дә юк. Сәхнәдә – бушлык, өзеклек. Тәнәфескә чыккач, без – массовка артистлары – Габдулла абыйга сорау белән ташланабыз:

– Ник сүзеңне әйтмәдең?

Габдулла абыйның җавабы хәтердә:

– Алтынчы рәттә кемнәр утыруын күргәч, автор сүзләре дә онытылыр иде. «Отсебятина» гына түгел...

– Кем утыра иде?

– Баян Гыйззәт белән Гази Кашшаф.

Артистның бу җавабы тәнкыйтьчеләр фикеренә үтә иътибарлы булуын күрсәтсә, икенчедән, ул оста башкарылган кечкенә бер эпизодның спектакльдә зур әһәмияткә ия булуына да мисал.

...Габдулла абый Фәтхуллин башкаруында тамашачыларны куандырган «кечкенә булса да төш кенә» эпизодлар ул катнашкан һәр спектакльнең йөзек кашы иде, дисәк, арттырып әйтү булмас. Алар спектакльне бик табигый рәвештә, тулыландырып бизи иде.

«Татар хатыны ниләр күрми?» спектакленнән бер күренеш: Мәрхәбә – Рауза Әхмәрова, Шаһвәли – Габдулла Фәтхуллин, Шәйхел – Ибраһим Гафуров. 1960 ел

Галиәскар Камал әсәре буенча 1963 елда куелган «Банкрот» спектаклен генә алыйк. Анда Габдулла абый поездда барганда әсәрнең төп каһарманы Сираҗетдиннең талануына шаһит булган пассажир ролен башкара. Бик кечкенә бер эпизод. Сүзләре дә игътибарны җәлеп итәрлек түгел: «Поезд бара иде, аннары тукталды. Кузгалып китте дә, бераздан тагы туктады. Шунда кондуктор: «Кенәзне талаганнар», – диде». Шушы эпизодны спектакльдә катнашучы һәр артист көтеп ала, рәхәтләнеп карый, чын күңелдән көлә. Габдулла абыйның гади таш кисәгеннән бриллиант ясавын күреп соклана.

Гадәттә, үзләрен театр белгече дип атаучылар, спектакльләргә рецензия язганда, төп рольләрне башкаручы артистлар уенына гына тукталып, аларга «әйбәт булды, шәп уйнады» дигән ярлыклар беркетүне вазыйфаларына санаудан узмый.

Театр спектакльләренә кагылышлы мәкаләләр артистларның һәркайсына тансык булса, Габдулла абый өчен алар тикшерү, анализлау материалы да иде.

«Акчарлаклар» спектакле чыккач, Гази Кашшаф язган рецензияне укып (анда Габдулла абый уены мактала), артистның бу «рецензиягә рецензиясе» хәтердә: «Менә бу мәкалә – рецензия ничек булмаска тиешлек мисалы», – диде ул, газетаны артистларга күрсәтеп. Ял бүлмәсенә җыелып, әңгәмә корган артистлар, аяз күктән «күк күкрәүдән» өнсез калып, көтелмәгән хәбәр салучыга ташланалар:

– Син нәрсә заманыбызның иң абруйлы тәнкыйтьчесенә яла ягасың? Ул бит мәкаләсендә сине мактап, гел яхшылык белән генә телгә алган, – диләр.

– Иң абруйлы тәнкыйтьче буларак, ул спектакльнең төп мотивын ачып күрсәтергә тиеш иде. Ә ул спектакль тукымасына кермәскә тиешле ваклыкларны мактап, күзгә төтен җибәрү белән чикләнә. Спектакльнең пружинасы булырга тиешле чарасызлыкны күрми. Әйтерсең лә аңа Шәриф Камал кайсы рольнең нинди булырга тиешлегенә үз кулы белән язган билет калдырган!.. Роль турында сүз алып барганда, «әйбәт уйнады, килештерде, охшатты» сүзләрен тенденция һәм теманы ачу сыйфатларына бәһа алыштырырга тиеш. Алары юк. Шуңа күрә рецензиядән сәнгатьнең үсеше өчен импульс та юк.

Габдулла абыйның театр-сәхнә сәнгатенә таләпләре зур иде. «Ә ни өчен соң аны

Төрмәче – Габдулла Фәтхуллин (У.Шекспир «Чамасына күрә чарасы»). 1968 ел

күбрәк эпизодик рольләрдә генә уйнаттылар?» – дигәндә, миңа калса, аның уен стиленә спектакльдә катнашучы башка артистлар кушыла алмый иде. Габдулла Фәтхуллин холыкларны калкытыбрак күрсәтү остасы иде. Андый артистларны «гротесковый стильле», диләр бугай.

Шулай да, Габдулла Фәтхуллинга зур рольләр бирелүе дә хәтердә. Мәсәлән, Аяз Гыйләҗевнең «Җиргә тапшырылган серләр» спектаклендәге роле. Ул спектакльдә үзем дә уйнасам да, Габдулла абыйның уенын да, спектакльнең эчтәлеген дә хәтерли алмыйм. Ә сәбәбен хәтерлим: Габдулла абый ул спектакльне әзерләгәндә тотыныр бау да, таяныр нокта да таба алмады. Аның шундый «ноктасыз, баусыз» рольләре дә бар иде, әлбәттә. (Әйтик, «Угрюм-река» фильмында). Шуларның тагын берсе – М.Горький әсәре буенча куелган «Дошманнар» спектаклендәге эшче роле.

Ул чордагы сәхнә кануннары буенча «эшче» «изге»гә тиң булганлыктан, Габдулла Фәтхуллинга бу роль таяныр ноктасы да, тотыныр бавы да юк, фон буларак кына кирәкле роль-персонаж иде. Спектакльнең режиссеры (театрга баш режиссер итеп куелган) Михайлов дигән урысның бар гамәле, уй-фикерләре татар театры артистларында үзе турында уңай фикер, күп белүче һәм олы эшләрне дә җиңел башкаручы дигән фикер тудыруга юнәлгән иде. Спектакльдә баш рольләрнең берсен (Бардинны) Хәлил әкә Әбҗәлилов әзерли иде. (Театрның некорованный короле!)

Без – вак артистларның бөтен игътибары, мөкиббән китеп, Михайловны тыңлау

«Миңнекамал» спектакленнән (М.Әмир әсәре) бер күренеш: Венера – Асия Галиева, Карт – Закир Сафин, Хаҗи – Габдулла Фәтхуллин. 1957 ел

һәм татар артисты Хәлил әкәнең урыс режиссерына ничек яраклашуын күзәтүдән гыйбарәт булды.

Шулай атналар, айлар буена...

Тыңлаудан түгел, тыңлаган атлы булып көчәнеп утырудан – имитациядән арый идек. Ял итүгә сәбәп – тәмәке тарту өчен тәнәфескә чыгу гына.

...Артык озак утыруданмы, мәгънәсез буш сүзләрдән туепмы, Габдулла абый чираттан тыш тәнәфес сорарга җөрьәт итте. (Хәзер инде ул репетициядә булган артистлардан Батулла белән мин генә калдык). Хәлил әкә Әбҗәлилов Габдулла абыйга: «Тәмәкеңне өеңдә тартырсың, утыр», – димәсенме?! Шул «утыр» сүзе репетициядәге һәр артистның «көймәсен комга утыртты». Барыбыз да өнсез-сүзсез калдык: Хәлил әкә – пәйгамбәребез үртәлде...

Бары тик Габдулла абый гына, тәмәкесен авызына кабып, шырпысын сызды да, барлык артистның котын алып, буйсындырып яшәгән Әбҗәгә карап: «Син инде кешене утыртырга күнегеп, үзең дә утырып калгансың икән – безне утырта алмассың. Минем өем – шушы театр!» – димәсенме.

...Шуннан соң ниләр булуын аңлатып язарга көчем дә, хәтерем дә чамалы булганлыктан, бер генә нәрсәгә игътибар юнәлтәсем килә: Габдулла абыйның һәр сүзе белән һәр артист килешсә дә, аны белдерүдән куркуы – чынбарлык.

«Исә Болгар җилләре» фильмында (режиссер Булат Мансуров) Фатин Фәтхуллин Ыруг бәге ролен башкара

«Ничек инде Хәлил әкәгә каршы сүз әйтеп була?»

Шул репетициядә без табынган артистыбыз Әбҗәнең чын йөзен, асылын күреп һәм ишетеп белдек. Габдулла ага аның кайбер әйтергә ярамаган шәхси кимчелекләрен күрсәтсә дә, соңыннан аны беркем дә көндәшен мәсхәрәдә калдыруда гаепләмәде. Бу инде артист коллегаларының Габдулла Фәтхуллин фикерләре белән килешүен күрсәтә иде. Шул рәвешле «эпизодик рольләр артисты» дигән исем береккән Габдулла Фәтхуллин ирек сөючән холыклы, кыю, үз принципларына тугрылыклы, курку белмәс тәвәккәл булуын, зур рольләр генә уйнау «сунарчысы» Хәлил әкәдән ким артист түгеллеген күрсәтте. Шуннан соң аның шәхесенә хөрмәт бермә-бер артты. Кеше буларак шушы «фаш ителүеннән» соң, Хәлил әкә ничектер тонықланды, «тернәкләнә» алмады, 1963 елның гыйнварында, һич көтмәгәндә, мәңгелек йокыга талды. Бу фаҗигадә Габдулла абыйны битәрләп сүз әйткән кешене хәтерләмим. Ә менә хатынының Хәлил әкә җәсәден өенә керттермәве, күмәргә киемнәрен бирмәве, аны соңгы юлга Бардин костюмы белән генә озату – «боз астындагы суның составында» әлегә ачылмаган әллә ниләр булуы турында сөйләде. Шулардан чыгып караганда, Габдулла Фәтхуллин «шартлаткан» «мина»ның Хәлил әкәнең асылы шартлавы дип кабул итәргә була иде.

Олы дәрәҗәләргә ирешкән бу артист җирләү белән генә онытылмады, әлбәттә. Аның исемен төрләндереп, башкарган рольләрен үрнәк буларак күпертеп, үзләренә исем һәм дәрәҗә юллаучылар әле һаман да табылып тора.

Бу инде Хәлил әкә варисларының шәхескә түгел, ә үзләре күрергә күнеккән «потларга» табыну галәмәтеннән. Аның холкындагы кайбер сыйфатлары театрда гыйбрәт буларак та яши. (Мәсәлән, вакытлыча аңа калдырылган театр мөһерен директорга кайтарып бирми йөртүе, депутатлык значогын күрсәтеп, театр баскычында озаклап басып тору гадәте.)

Хәер, Хәлил әкәнең сәер сыйфатлары белән бергә, ул рәнҗеткәннәрнең дә кайбер сыйфатлары театрда яши. Шул исәптән, Габдулла абый Фәтхуллинның да. Мәсәлән, театрда: «Фатиннар кайткач күрерсез әле», – дигән бер җөмләсе әйтемгә әверелде. Театрда берәр ярамаган эш күрсә, Ленинградта артистлыкка укып ятучы улы Фатин Фәтхуллин укып кайткач, зур эшләр «майтаруына» өметләнүдән шулай дип әйткәндер ул. Әмма...

Аның өметләре өлешчә генә аклану – үзе бер тарих. Анысы соңрак.

Габдулла абыйның күңелләрдә билгән урыны башка күренекле шәхесләр билгән урыннар янәшәсендә. Сәхнәдә калдырган эзләрен туфрак та капламас, аларга чүп үләне

дә үсмәс. Язмама күренекле сәхнә остасы турында үз фикеремне әйттем дип имзамны куюу өчен, театр белгечләре традициясе буенча, артистның биографиясеннән кайбер фактларны күрсәтеп, уйнаган рольләрен санап узу кирәктер. Мин ул гамәлдән баш тартам. Чөнки артист Габдулла Фәтхуллин иҗат иткән чорда бүген телгә алырлык пьесалар язылмады. Язылганнары «денем өчен түгел, көнем өчен генә» иде.

Пьесаларның төзелеш материаллары заман каршылыкларында катнашучы төрле холыклар булганлыктан, ул чорда һәм әле хәзер дә заман каршылыкларын күрү тыелганлыктан, төрле холыклы персонажлар да, җиңүче дә, җиңелүче дә юк. Сәхнәдә очсызлы мәзәкләр һәм сыгылмалы, умырткасыз персонажлар «туй итә».

Габдулла абый иҗат иткән чорда вакыты белән классик әсәрләр сәхнәләштерелсә дә, ул спектакльләр «артистлар классик пьесаларда да уйнарга тиешләр» дигән «соус» белән генә аклана иде. Ә заман каршылыкларына аналог булмаган буш әсәрләрдә Габдулла абыйның осталыгы күренү фактын хәтерләмим. Кыскасы, ул – биргәнне алды, сораганны бирде. Шуны әйтеп узу кирәктер: Габдулла абый, солдат буларак ватанны саклау хезмәтен үтәгәндә аякларын туңдырып, ике аягының да табаннарыннан мәхрүм кала. Без аны инвалид буларак белсәк тә, ул үзенең гариплеген сиздерергә теләми иде. Дөресе – сиздерми иде. Аның адымнары ныклы, эзе таныла, барган юлы туры иде. Ул күп укыган, күпне белгән «грамотный» мужик булды. Габдулла абый театр сәнгате буенча белгәннәрен улы Фатинга да васыять иткән иде. Ләкин сәхнәдәге эзне күп белүчеләр түгел, үз эзе булганнар гына калдыра. Габдулла абый Фәтхуллинның варисы Фатин күп белү урынына күп эшләсә, инвалид атасы салган сукмак, һичшиксез, аны олы сәнгать юлына чыгарган булыр иде. Әмма дөнья теләк белән генә түгел, ә таләп белән тәрәккыяткә ирешә. Ә таләпләр көндәлек тормыш ихтыяҗыннан чыга. Габдулла абый варисларыннан Фатинга кагылышлы язмага күчкәнче, тагын шул «кешеләр аңында «күренекле урын» теориясен искә төшерү кирәк булыр.

Ни хикмәттер, күпчелек кешеләр күренекле урын алу өчен юлны иҗади хезмәттә күрә. Әйтик, рәссам-сынчы, музыкант, шагыйрь, артист булуда. Шул юлларның иң такыры артист булуда, дип караучыларның күпчелекне тәшкил итүе дә, иң хәвефле юл булуы да сер түгел.

Һәр елны йөзәрләгән шәкертнең театр уку йортларына урнашырга теләве, аларның, укыгач, эшсез йөрүләре дә бу күңелсез «инфекция»гә мисал.

«Ни өчен шулай икән?» – дигәнгә – җавап мондый: театр сәнгате – күмәк иҗат җимеше. Театрның уңыш казануы берничә факторга бәйле: әсәргә, режиссерга, композиторга, рәссамга, артистлар уенына. Бер артистның «начар» уйнавын икенче артистның «әйбәт» уены каплый алуы бер-береңне «коткаруга» ышыкланып, театрга эләгергә омтылу инстинктын көчәйтә. Рәссам сәнгатендә дә, сыннар ясау иҗатында да, композиторларда да һәр иҗатчы үз эшенә үзе генә җаваплы булу алар арасында «ЧП»ларга сәбәп булмый. Кешеләр күңелендә үзеңә урын табуда артист иҗаты иң туры, иң отышлы юл саналса да, шул отышлыга ирешә алмый харап булганнарның да саны артистлар арасында иң күбе. Әгәр күңелләрдә урын алуны биек тауга менү белән чагыштырсак, ул тауга сөзәк яктан үз аягың белән яки үз сукмагыңнан текә яктан төрле җайланмалар кулланып та күтәрелергә була. Сөзәгеннән күтәрелүчеләр кислородсыз һавага акрынлап күнексә, текәсеннән күтәрелгәннәр исә, җиңел тау һавасыннан җиңеләеп, биеклектә ярамаган эшләр эшләп ташлый. Театр – күмәк иҗат, бер кешенең ярамаган эше бөтен төркемгә зыян булганлыктан, гөнаһлы артисттан тизрәк котылу чарасын күрәләр. Бер театр тарихындагы харап булган язмышлы артистларны гына саный китсәк тә, аларның саны 1:1 чагыштырмасындадыр. Үзем күреп белгән берничә артистны гына атап узсам да, бу хәлнең милли театр сәнгатендә олы афәт булуы аңлашылыр:

Ленинград театр, музыка һәм кинематография институтының татар студиясен тәмамлаган сәнгать әһелләре (сулдан уңга): Ш.Галиуллин, Г.Шәрәфиев, Л.Шакирҗанова, Р.Абдуллаев, Ш.Бариев, И.Әхмәтҗанов, И.Фәхретдинов, Ф.Фәтхуллин. 1987 ел

баянчы һәм оригиналь артист Илдус Вәлиев, гаҗәеп үзенчәлекле артистлар Шамил Миңнуллин, Камил Камалов, Әмир Камалиев, Шамиль Бариев, Дусил Касыймов, Идрис Мәсгутов, Рәсим Сәлахов, Рифкать Бикчәнтәев, Хәмбәл Закиров, Наил Әюпов, Нариман Гарифуллин, Илһам Шәйдуллин, Харис Төхвәтулов. Бу артистларны беркем дә «дан тавыннан» төртеп төшермәде. Аларның күбесе үзе таеп егылды, ә кайберсенә, егылгач, тотынып торыр нәрсә җитмәде. Әмма бернәрсә бәхәссез: театрда ялгышкан артистларның хаталарын төзәтү системасы эшләнмәгән. Театр, хаталанучыны юкка чыгарып, бетерергә генә омтыла. Шуңа күрә спектакльләрдә бер үк артистлар күнеккән амплуаларында бер үк холыкларны күрсәтә. Бик аяныч хәл бу. Фатин Фәтхуллин да югарыда атап үткәннәр исемлегендәге сәнгатькәрләр токымыннан булган талантлы егет иде. Үзенчәлекле холыкка ия иде.

Мин аның турында бер җөмлә белән, урысчалатып: «Знал бы он меньше, делал бы больше», – дияр идем. Режиссер буларак, аның белән Тукайның тууына 100 ел тулганда куйган бер генә фильм-спектакльдә эшләдем. Ул Өфе шәһәрендә Тукайга каршы оештырылган фетнә башлыгын уйнады. Суның тәмен белү өчен диңгезне эчеп бетерү кирәк булмаган кебек, артистның иҗат потенциясен белү өчен дә сәхнәдә бер күренүе җитә. Фатинның уеныннан мин генә түгел, тамашачылар да канәгать булуына миндә сакланган тамашачы хатлары шаһит. Теләсәм дә, аны башка рольләрдә күрә алмадым. Миңа калса, ул үзенең иҗат мәйданын да, аңа бару юлларын да дөрес сайламаган. Янган иҗатчы, ашыгучан натуралы егет иде. (1949 елда туып, 2006 елда кинәт вафат булуы дә шуны раслый).

Фикерләремнең дөресме, ялгышмы икәнлеген ачыклау максатында, ярдәмгә Фатин белән бергә институтта укыган халык артистлары Илдус Әхмәтҗанов белән Луара Шакирҗанованы һәм аның белән бергә иҗат иткән сәхнәдәш дусты, халык артисты Илгизәр Хәсәновны һәм хатыны, бик үзенчәлекле артистка Аграфина Васильеваны чакырдым. Аларның һәркайсы беравыздан Фатинның таланты, укымышлылыгы, эшлеклелеге турында тәфсилләп сөйләгәч, ахырда бер үк нәтиҗә ясадылар: «Фатинны сак-

лап калырга кирәк иде, ярдәм кулы сузучы булмады», – диделәр. Кушылам. «Ярдәмче» булмады, дип, адрессыз кемнедер гаепләүдән фәтвә чыкмый. Алары тактика хаталары гына. Ә менә стратегик хата – андый авырулы артистларга реабилитация юклыкта һәм сәнгатьтә иҗатчылар әзерләүнең системасызлыгында. Һәр эшнең очраклылыкка, кемнеңдер кәефенә, холкына бәйлелегендә.

Ленинградта институт бетереп кайткан яшь артистлар Академия театры сәхнәсендә спектакль чыгаралар. Шулчакта ук Фатинның режиссурага тартылуы сизелсә дә, аны шул һөнәргә тарту өчен нindидер чара күрелми. Фатин ашыга, режиссер буласы килә һәм тагы укырга китә. Тик керә генә алмый, кире әйләнеп кайта. Кайткач, театрга алынмый, «тамыры белән йолкынып» күчерелә, башка театрда эшли башлый. Сабакташларыннан аерыла, бик кирәкле терәктән мәхрүм ителә. Яңа урында аңа Разил Вәлиевнең «Әйдә барыйк, кызлар карыйк» әсәрен куярга әзерлек эшен тапшыралар. Андый эшне театрда ассистентлык эше дип атыйлар. Ә Фатинның өмете сорежиссер дип аталуда була. Ирексездән, конфликт шытып чыга. Бу очракта Фатинның түземсезлеге, «мин беләм» авыруы, «тау һавасын» килештермәве «ярылып ята».

Әлбәттә, ул эзләнә, тик ятмый. Ниһаять, Ю.О'Нилның «Любовь под вязами» дигән әсәрен, «Богауланган мәхәббәт» исемендәге спектакль итеп, театр сәхнәсендә күрсәтүгә ирешә. Әгәр бу спектакльнең ничек әзерләнүен күз алдына китерсәк, андагы артистларның һәркайсына тырышлыклары, түземлекләре өчен орден-медальләр бирелергә тиеш. Репетицияләр театрның төп эшләреннән соң гына, качып-посып, яшеренеп кенә, артистларның үз ихтыярлары буенча гына уздырыла.

Спектакль чыгып, телевидениедә күрсәтелеп, хуплау хатлары килүгә карамастан, Фатиннан (күтәреп алып) тагы спектакльләр куйдыру урынына, аны кыерсыту, кимсетү чаткылары күренә башлый. Ул, үзлегеннән, Хәләф Гарданов әсәре буенча спектакль әзерләргә тотына.

Артист иҗатында булгач, башкалар белән бергә гастрольләргә дә чыга, рольләр башкара. Түзә, тырыша. Бүген иптәшләре аны һәр эштә булдыклылыгына, ярдәмчеллегенә, ихласлыгына басым ясап искә алалар. «Оригиналь иҗатчы иде», – диләр...

...Казанга Булат Мансуров дигән режиссер килеп, республика бюджетына көя төшерә башлауга, Фатин тагын тактик хата ясый – ул шул аферистка ярдәм итәргә алына. Ярдәм итеп кенә калмый, шул елгыр кешенең вәгъдәләренә алданып, кинорежиссерлыкка укырга китә. Укуны тәмамлагач, үзлегеннән, Ибраһим Сәлахов әсәре буенча фильм да төшерә (каян һәм ничек акча табуын белүчене тапмадым). Шул фильмда катнашкан халык артисты Николай (Наил) Дунаев әйтүенчә, «фильм кеше карарлык мәгънәгә ия милли әсәргә нигезләнеп эшләнгән булса да, аның ни өчен күрсәтелмәве сәбәбен дә, кайда югалуын да белүче юк». Бу – үзе генә дә безнең республикада иҗатчылар әзерләү стратегиясе булмауны күрсәтүче яман факт. Ә бит Фатинның режиссер булып эшләвеннән берәүгә дә зыян булмас иде. Тар күңеллелек һәм көнчелек аркасында үз эзе калырлык сәләткә ия егет шулай «янды-көйде, егылды», диләр дуслары. Шулай да, театр сәнгатендә аның эзе калды. Бар ул эзләр. Аның уйнаган рольләрен, яхшы яктан хәтерләп, сагынып искә алалар.

«Әгәр дә сәхнәдән китмәгән булса, ул этисе Габдулла абыйдан ким эз калдырмас иде», – диләр иҗатташлары.

Театр сәнгатендә, сәхнәдә берәү дә икенче артистны кабатлап уңышка ирешә алмый. Ул үзенчә, үз эзен калдырса гына, күңелләрдә үз урынын алып, саклана.

Аталы-уллы Фәтхуллиннарның иҗат эзе җуелмас та, аны тузан да капламас, әлбәттә. Тик шунысы мөһим: безнең иҗатташларның хәтерләрен тузан капламасын, аларның иҗат тәҗрибәләре варисларда гыйбрәт булып яшәсен иде. ■

Истә, һаман да истә!

Рәссам Әхсән Фәсхетдиновның тууына 80 ел

Рәссам, сынчы һәм монументаль бизәлеш рәссамы, агачка уеп рәсем ясаучы, Татарстан Республикасының халык рәссамы, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Әхсән Сарим улы Фәсхетдинов 1939 елның 7 июнендә Татарстанның Чирмешән районы Үтәмеш авылында туа.

Авыл мәктәбен тәмамлаганнан соң, ул Куйбышев (Самара) өлкәсенең Камышлы татар педучилищесында һәм Түбән Тагил педагогия институтының сәнгать-графика факультетында белем алып, 1969 елда Татарстанга кайта.

Әхсән Фәсхетдинов иҗат иткән әсәрләр Түбән Каманың үзенчәлекле символы булып тора. Ул күп кенә объектларны, җәмәгать биналарын бизәкләп эшләүдә катнаша. Алар арасында – музыка училищесы, энергетика-төзелеш техникумы, «Бигеш» аэропорты, «Кама» кунакханәсе, аттракционнар паркы, «Әкият» кафесы, балалар бакчалары бар.

Ә.Фәсхетдиновның әсәрләрендәге төп темаларның берсе – Габдулла Тукай тормышы һәм иҗаты. Аның бик күп рәсемнәре һәм скульптур композицияләрендә шагыйрь һәм аның әсәрләренең геройлары урын ала.

2012 елның 15 июлендә якты дөнья белән хушлаша.

Җырчы Хәйдәр Бигичевның тууына 70 ел



Җырчы, ТАССРның халык (1980), РСФСРның атказанган артисты (1986), Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1984) Хәйдәр Әббәс улы Бигичев 1949 елның 16 июнендә Түбән Новгород өлкәсендәге Кызыл Октябрь районы Чүмбәләй авылында күп балалы гаиләдә туа.

Совет Армиясендә хезмәт иткәннән соң, Мәскәүгә килеп, заводка эшкә урнаша. «Алло, без талантлар эзлибез» дигән телевизион тапшыруда катнашып, лауреат була. Әлеге бәйгенең жюри рәисе М.Таривердиев яшь башкаручының чыгышына югары бәя бирә һәм аңа җыр-музыка белән чын-чынлап шөгыльләнергә киңәш итә.

1977 елдан алып вафатына тиклем Х.Бигичев М.Җәлил исемендәге Казан дәүләт опера һәм балет театрында эшли.

Казанның Совет районындагы бер урамы Х.Бигичев исемен йөртә. Җырчы исемен йөрткән урам Балтач районының Балтач бистәсендә дә бар.

Х.Бигичев 1998 елның 13 ноябрендә Казанда вафат була.

Язучы Кыям Миңлебаевның тууына 90 ел

Тәрҗемәче, язучы, РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1980) Кыям (Кыяметдин) Сәләхетдин улы Миңлебаев 1929 елның 25 июнендә Татарстанның Чүпрәле районы Кече Чынлы авылында туа.

Башлангыч белемне туган авылында, 1938 елда гаиләләре белән Казанга күчеп килгәч, укуын Дәрвишләр бистәсендәге җидееллык һәм Кабан күле буендагы 12 нче татар урта мәктәбендә дәвам итә.

1953 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлагач, ике ел Татарстанның Сарман урта мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укыта. 1955 елның көзендә ул янәдән Казанга кайта һәм Татарстан китап нәшриятында эшли башлый: әүвәл яшьләр-балалар әдәбияты редакциясендә – редактор (1955-1958), редакция мөдире (1958-1966), ә 1967 елдан бирле матур әдәбият редакциясенең өлкән редакторы вазыйфасын башкара.

К.Миңлебаевның тәүге тәрҗемә эше (П.Цвирканың «Сандугач» исемле җыентыгы) 1954 елда басылып чыга. К.Миңлебаев тәрҗемәсендә рус классикасы, чит ил әдәбияты һәм совет авторларының егермеләп китабы дөнья күрә: Лев Толстой «Балачак», «Үсмер чак», «Егет чак» (1955-1957); «Ярты колак» (төрекмән халык әкиятләре, 1958); Н.В.Шишков «Хәсрәт дәрьясы» (1963); Т.Семушкин «Айвам маҗаралары» (1964) һ.б.

К.Миңлебаев 2005 елның 3 сентябрендә бакыйлыкка күчә.

Җырчы Нажия Теркулованың тууына 90 ел

Җырчы, ТАССРның халык артисты (1982) Нажия Габдрахман кызы Теркулова 1929 елның 25 июнендә Әстерхан шәһәрендә туа.

1957 елда ул Казан дәүләт консерваториясенең вокал бүлеген (Е.А.Абросимова классы) тәмамлый һәм Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенә эшкә җибәрелә. Шул ук елда Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең солисты булып катнаша. 1959 елда ул Абай исемендәге Казакъ дәүләт академия опера һәм балет театрына (Алма-Ата) солист итеп чакырыла. 1966 елда исә Казанга әйләнеп кайта, үз эшчәнлеген филармониянең әдәби-музыкаль лекторий бүлегендә дәвам итә. Татар композиторларының җырларын аеруча яратып башкара: «Беренче мәхәббәт» (С.Садыйкова көе, Ә.Рәшит шигыре), «Оныта алмыйм» (Р.Яхин көе, М.Ногман шигыре), «Яшьлек вальсы» (З.Хәбибуллин көе, М.Хөсәен шигыре), «Былбыл» (Л.Хәмиди көе, Г.Әхмәтҗанов шигыре), «Өзелгәнсең сиреньнән» (Н.Җиһанов көе, С.Хәким шигыре).

Н.Теркулова 2016 елның 14 октябрендә Казанда вафат була.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

БОРЫНГЫ ТАТАР МИЛЛИ МУЗЫКА УЕН КОРАЛЛАРЫ

КӘККҮК

Ике генә көпшәдән торгангамы, татарлар яшәгән бик күп төбәкләрдә бу уен коралын *кәккүк* дип йөртәләр. Бер көпшәне кыскарак, икенчесен озынрак ясап «сызгыртсаң», дөрестән дә, күке тавышы чыгарырга мөмкин. Сүз дә юк, элек ул ике генә көпшәдән тормагандыр, гүзәл көйләр уйнарлык камил уен коралы булгандыр.

Без аны алтмышынчы елларда өлкәнрәк яшьтәге малайлардан күреп ясый идек. Кәккүкне ясау бик җиңел. Бармак калынлыгында булган 10 см тирәсе озынлыктагы ботаксыз тал чыбыгын үткен пәке белән кисеп аласың да, кабыгына аз гына суккалап, үзәген акрын гына тартасың, әмма ахыргача тартып чыгармыйсың. Шул үзәкне күчереп йөртеп, тавыш югарылыгын көйлисең.

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2019) санында.

Бүгенге көндә, һичнигә кытлык юк заманда, элек киң кулланылышта булып та, хәзер балалар уенчыгы дәрәҗәсенә төшкән мондый уен коралларына ныграк игътибар итсәк иде. *Кәккүк, таш сыбызгы, тал сыбызгы, җәя кубыз* кебек уен коралларына профессиональ күзлектән карарга кирәк, минемчә.

Мондый уен коралларында дөньяның барлык халыклары да диярлек уйнаганнар. Һәр халык аны үзенчә атаган. Арада иң мәгълүме – борынгы юнан (грек) алласы Пан исемен йөрткәне: ул *Пан флейтасы* дип атала һәм бер-берсенә тоташтырылган төрле озынлыктагы җиде көпшәдән тора. Гагаузлар, украиннар аны – *най, мускал*; фин-угыр халыклары – *скучудай, чипсан*; Америка индеецлары – *сампоньо;* урыс халкы – *кугиклы (кувиклы)* дип йөртә. Шунысын да искәртик: Америка индеецларында әлеге уен коралында уйнау традициясе гасырлар буе сакланып килгән. Җитмешенче елларда исә кәккүккә охшаган шушы гади генә уен коралын бер төркем румын-молдаван музыкантлары күтәреп алды, аны һәм аның аша үзләрен бөтен дөньяга танытты.

Кәккүкне һәркем үзе ясап уйный ала. Ул башлап уйнарга өйрәнүче балалар өчен аерата отышлы. Моның өчен 10-20 см озынлыктагы берничә көпшә (эбонит, пластик йә агач материалдан) әзерлибез. Һәр көпшәнең бер башына, эчке яктан кучеп йөрерлек итеп, бөке ясыйбыз. Уйналасы көйгә карап, һәр көпшәне кирәкле тавыш югарылыгына көйлибез. Тавыш чыгару өчен, көпшәнең ачык башын авышрак итеп иренгә терибез дә акрын гына өрәбез.

Җөмләдән, Казан шәһәренең 149 нчы татар лицее каршында 2008 елдан бирле «Сорнай» балалар хәзерлек төркеме эшләп килә. Кәккүк – аларның иң яраткан музыка уен коралы.

Ринат Гыйләҗев,
«Сорнай» фольклор ансамбленең сәнгать җитәкчесе

Дәвамы бар ■

ТАССР

«ТАТАРСТАН»

Рәис Сәфәров

Туган көненнән, ягъни 1920 нче елның 5 нче маеннан алып 70 яшенә кадәр безнең дәүләтебез «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы (ТАССР)» дип аталып килде. Дөньялар үзгәреп, яңа Конституция кабул ителгәч, аңа «Татарстан Республикасы» дигән рәсми исем кушылды. Илебездәге сәяси вазгыятькә яраклаштырып бирелгән бу соңгы атамада тәүгесендәге сыйфат сүзләре алып ташланса да, дәүләт исемен билгеләүче төп сүз – «Татарстан» саклана. Кем белә, әгәр дә мәгәр киләчәктә сәясәт өлкәсендә тагын да үзгәрешләр килеп чыгып, суверен дәүләтебезнең исемен тагын да алмаштырырга туры килсә, анда милләтебезне белдергән этноним – «татар» сүзе, һичшиксез, сакланачак, чөнки ул – мәңгелек исем: милләтебез яши икән, ул да яшәр.

«Татарстан» атамасындагы беренче төп компонент – «татар» этнонимының ничек килеп чыгуы, барлыкка килүе мәсьәләсен галимнәребезгә калдырып, бу топонимның икенче компоненты – «стан» сүзенең, бу очракта сүз ясагыч кушымчаның этимологиясен ачыклап карыйк.

Башта шуны исебезгә төшерик: «стан» кушымчасы белән ясалган дәүләт исемнәре «Татарстан»нан тыш та байтак. Мәсәлән, Һиндстан, Көрдстан, Әфганстан, Үзбәкстан, Таҗикстан, Казакъстан, Төрекмәнстан һ.б. Күренеп тора, боларның да беренче төп компоненты – этнонимнар, халык исемнәре. Ләкин этносны белдермәгән топонимнар да очрый. Мәсәлән, Дагыстан җөмһүрияте, Үзбәкстанда гына да Гөлстан, Шаһистан районнары бар. Сәмәркандтагы мәшһүр Регистан архитектура ансамбле... Шунсы әһәмиятле: «стан» кушымчасы кергән бу топонимнар һәммәсе дә шәрык һәм Азия төбәкләренә карый һәм алар өчен уртак атама булып тора.

«Стан» сүзен борынгы славян-урыс телендәге кайбер мәгънәдәш сүзләрнең тамырын тәшкил иткән «стан»га бәйләүче галимнәр дә бар. Мәсәлән, Фасмер, Преображенский, Шанский, Бертельс, Кононов. Аларның фикеренчә, урыс телендә хәзер дә актив кулланышта йөргән «военный стан», «полевой стан», «станция», «пристань», «становление» шикелле «стан»лы сүзләр «утрак», «лагерь», «туктап тору урыны» кебек бер-берсенә якын мәгънәне белдерә. Чыннан да, беренче карашка аларның дәлилләре шактый төпле күренә.

Ярый, шулай булсын, ди. Ләкин бер сорау туа: әгәр «стан» славян-урыс сүзе булса, ничек итеп, нинди юллар белән ул таулар-диңгезләрне кичеп, әллә кайлардагы, географик яктан бик ерактагы, урыслар, славяннар белән икътисади, сәүдә, мәдәни һәм башка мөнәсәбәтләрдә, элемтәләрдә булмаган илләргә барып җиткән дә, аларның

телләренә үтеп кереп, әлеге илләрнең борынгыдан килгән атамасының бер өлешенә әверелгән икән. Ышандырмый, ни өчен дигәндә, урыслар, мәсәлән, Һиндстан дигән илнең барлыгын фәкать XV гасырда, Тверь сәүдәгәре Афанасий Никитин бу якларга сәфәр тотып кайткач, «Путешествие за три моря» дигән юлъязмасын бастырып чыгарганнан соң гына беләләр.

Димәк, «стан» урыс сүзе түгел. Безнеңчә, урыслар бу сүзне үзләре кайсыдыр бер телдән алган булып чыга. Ә кайсы телдән?

Борынгы һинд-санскрит телендә «станам» дигән сүз булган, бу сүз Һиндстанга географик яктан күрше булган Иран, Әфганстан халкы сөйләшә торган фарсы телендә, бераз фонетик үзгәреш кичереп, «стан» шәкелен ала һәм гомуми кулланышка кереп китә. Әлеге «станам» – «стан» сүзе мәгънә ягыннан ил, йорт, җир, торак урын, төбәк төшенчәләренә якын була. Академик Мирза Мәхмүтовның «Гарәпчә-фарысча алынмалар сүзлеге»ндә дә «стан» фарсы телендә җирне, урынны күрсәтүче исем ясагыч кушымча», диелгән. Нәкъ шушы мәгънәләрен саклап, бу сүз, әлеге илләр белән элемтәләр барлыкка килгәч, урыс теленә дә күчә һәм аерым сүзләр, топонимнар, атамалар ясауда катнаша, шулай ук үзгәрешсез, мөстәкыйль формада да кулланылып килә (становой, военный стан, стан һ.б.).

XIX гасыр ахырында Россия империясе төрки халыклар яшәгән җирләрне (Хива, Коканд, Үргәнеч ханлыкларын) коралды көч белән басып ала, үз колонияләренә әйләндерә. Патша хөкүмәте зур территорияне биләгән бу Үзәк һәм Урта Азиядәге колониясен, әлеге җирләргә чиктәш булган Һиндстан исеменә охшатып, «Туркестанский край» дип атый. Һиндстан һиндлар станы (иле) булса, Төркестан төркиләр станы (иле) була.

Инкыйлабтан соң бу «төркиләр станы» берничә административ-территориаль милли өлкәләргә, җөмһүриятләргә бүленә һәм РСФСР карамагына алына. Әлеге җөмһүриятләр, «Төркестан» исеменә охшатып, «стан» кушымчасы белән аталалар (Үзбәкстан, Таҗикстан, Кыргызстан, Казакъстан һ.б.). Болардан соң, РСФСРның Европа өлешендә дә автономияле милли җөмһүриятләр төзелә, аларга да Төркестан җирендә оештырылган дәүләтләр үрнәгендәге исемнәр бирелә: Башкортстан, Татарстан, Дагыстан.

1999 ел ■

Ә маймылы кайда?

Мөдәррис Әгъләм

Без яшь чакта яңа әсәр укыганнан соң бәхәсләшерлек, киңәшләр бирерлек тә рәте булмаган язмага төгәл бәяләмә бар иде:

– Маймылы юк. Маймылы табылмаган.

Инде бу атама онытыла, югала бара. Шулай да соңгы елларда Туфан Миңнуллин язмаларында берничә мәртәбә ялтырап китте. Без инде күптәннән үзебезнең мәгънәле тәгъбирләребезне югалта барабыз. Европа латиннан үзләштергән, урыслар исә Европадан үзләштерә. Без аларга ияребез. Шулай итеп, куян шулпасының шулпасы килеп чыга. Төп мәгънә халыктан ераклашканнан-ераклаша бара.

Шулай да каян килеп чыккан соң бу атама? Югыйсә бит узган гасырның 70-80 нче елларында инде бу бәяләмә әдәби кулланышка ук кереп бара иде.

Сугыштан соң беренче мәртәбә Казанга алдынгы колхозчыларны җыялар. Тантаналы җыелыш, бүләкләүләр. Менә аларны Казан буйлап экскурсиягә алып чыгып китәләр. Кунакларны журналистлар, язучылар, артистлар озатып йөри. Алар арасында Кави Нәҗми, Гомәр Бәширләр бар. Димәк, халыкка, аның язучыларына хөрмәт булган ул чакта.

Менә бер төркемне зоопаркка алып керәләр. Аларны маймыл кызыксындыра, чөнки сез маймылдан яратылган, дигән фикер башларына нык сеңдерелгән. Шуңа күрә үзләренең шушы көнгә калуларының башын эзлиселәре, күрәселәре килә.

Менә колхозчылар маймыллар читлеге янында.

Гомәр ага Бәширов, үз гомерендә бер мәртәбә дә шаркылдап көлмәгән зат, җәелеп көлә иде. «Читлекләрне уратып алдылар, – ди, – ник шылт иткән бер тавыш булсын, тып-тын. Берзаман үзләренең ерак бабаларын сыйларга керештеләр. Өйләренә кайткач, бала-чагаларын сыйларга дигән тәмле кәнфит-перәннекләрен таратып бетерделәр. Тагын тын калдылар. Ә теге ач тәреләр, маймылланып, тагын сорый. Шунда берсе әйтеп куя:

– Юк, җәмәгать, без алардан түгел, алар бездән яратылгандыр. Бу кадәр ач булмаслар иде.

Зоопарктан соң, Шәриф Камалның музей йортына юнәләләр. Кереп тулгач, бүлмә кечерәеп кала. Ул чагында әле ул хәзергечә киңәйтелмәгән. Эчтән ягулы. Тын гына басып торып тыңлыйлар да – бетте.

Шунда бер җор телле колхозчы сорап куя:

– Ә моның маймылы кайда соң?

Бу сүзнең мәгънәсе иң әүвәл Кави Нәҗминең зиһененә барып җитә. Ул аны, кайтып, язучыларга сөйли. Әнә шуннан инде бу канатлы тәгъбир язучылар арасында таралып китә.

«Әгәр зирәк Кави игътибар итмәсә, мин, томана-лирик баш, бу сүзләрне колак тирәсеннән генә уздырган булыр идем әле», – дип сөйли иде Гомәр ага Бәширов. Әнә шулай итеп «маймылы кайда?» дигән атаклы гыйбарә барлыкка килә. Чиле-пешле әсәр турында «маймылы юк», дип юкка гына әйтмиләрдер...

2006 ел

*Сәхифәне **Рөстәм Акъегет** Татарстан радиосының «Тел күрке – сүз» тапшыруы язмаларына нигезләп әзерләде.* ■

«Сүзләр тавыш биреп атлыйлар...»

Биредә Самара өлкәсенең Камышлы районындагы Иске Ярмәк авылы халкында сакланып калган тел берәмлекләре тупланды. Бу сүз яки гыйбарәләрнең кайберләре тирә-як татар авылларында бөтенләй кулланылмый һәм «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге»нә дә кертелмәгән.

Яңа дәүләтләргә мәйдан булып,
Нигез булып сүзләр яттылар...
Сүзләр көрәшәләр, сүзләр җиңә,
Сүзләр тавыш биреп атлыйлар...
Рөстәм Мингалимов

Алаңгыр – нык зур тишек;
ачка койрык чәнчү – ачлыктан интегү;
бо(ы)йрык тотмый – туры эчәкле кеше;
брамат – юк-бар эш белән озак йөрү;
бричкә – җиңелчә арба;
бүкәй – карачкы, сабыйлар өчен куркыныч зат;
былкылдап тора – бик симез;
дө(е)ңгер сөяк – тез капкачы;
зад – зад ти-зи – җилбәзәк кеше;
зурат – ашлык көлтәсе өеме;
икеле кунда-шау берле – ахмак;
йө(е)лсенгән – шешкән;
кавырсын – пластмасс;
кәлтин-пүлтин – селкенеп йөрү;
көрчек – чик;
куҗыту – котырту;
кузла – утын кисү өчен җайланма;
куркуль – бик саран;
кытыркуык – тиктормас;
лакап куйган – ашап бетергән, ялтыраткан;
ләхер-лөхер – көчкә селкенеп торучы;
ләшперәйгән – юешләнгән, сыгылып төшкән;
мәмерҗә – упкын сыман текә чокыр;
моңгылланган – бозылган, исләнгән;
мөшкә – тегермәндәге он агу урыны;
мүкәнәй – акылга сай, җүләр кеше;
мышаяк – хәйләкәр, астыртын кеше;
пыраксыту – кирәгеңне бирү;
пырныша – бозыла (исләнә);
талкый – имчәкне нык имгән җан иясе;
тартай – тел бистәсе (болтун);
тәбәшәк – астан өскә таба биек булмаган;
тотрык – түземлелек, зур сабырлык;
тубырчык – мичкә бөкесе яки бик тере (шустрый) бала;
тырыпша – каплау өчен зур һәм калын чүпрәк материал;
үтләтә – бик туйдыра;
уйлык – билгеле аерым бер җирдә бер нәрсәнең күп булуы;
чәлтер – тубык;
чәтнәби – үткен, сүзгә бик оста яки чая;
чәүчәләк – тынычсыз;
чиннек – йорттагы корылма;
чурлаган – бик ачыккан;
чыгынкы – бик күп (мәсәлән, бик тозлы);
чыжым тарту – серне белергә тырышу;
шәйтан арбасы – озын арба яки су арбасы;
шо(ы)бынный – урлый яки чәлдерә;
ялгаш – улак, маллар өчен су савыты.

*Сүзләрне **Габдулла Мөхәммәдкәрим** туплады* ■

Безнең мирас №6 июнь 2019

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе

XIX ГАСЫР АХЫРЫ-XX ГАСЫРНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЯРТЫСЫНА КАРАГАН ФОТОСУРӘТЛӘР ТУПЛАНМАСЫ

Китапханәнең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә XIX гасыр ахыры-XX гасырның беренче яртысына караган фотосурәтләр тупланмасы да саклана, ул кызыклы һәм кабатланмас нөсхәләргә ия. Әлеге тупланманың башлангычы бүлек оешкан 1992 елга ук нисбәт ителә һәм бүген дә яңадан-яңа табышлар – әүвәлге уникаль фотолар белән тулылана бара. Биредә хәзер Казан тарихын, республикабыз һәм татар халкының үткәнен чагылдыра торган 700дән артык фотосурәт бар.

Археограф Зәйнәп Максудова архивыннан

Дәвамы. Башы журналның 2017 елгы 10 нчы санында.

Журналист Вафа Бәхтияров архивыннан

Шагыйрә Гыйффәт туташ – Заһидә Бурнашева архивыннан

Якуб һәм Госман Хәлилиләр архивыннан

Казан сәүдәгәрләре Мусиннар – Даутовлар – Юзеевлар архивыннан

Казан сәүдәгәрләре Әхмәдуллиннар архивыннан

Сәүдәгәрләр Салиховлар – Ибраһимовлар – Кятиевләр архивыннан

Алар халкыбыз тормышына, җәмгыять үсешенә бибәһа зур өлеш керткән мәшһүр затлар, мәдәният, мәгариф, фән эшлеклеләре турында сөйли. Сурәтләрдән безгә шулай ук әдипләр һәм шагыйрьләр, дин әһелләре, күренекле сәүдәгәрләр нәселләренең вәкилләре, артистлар, сәнгатькәрләр карап тора.

Шиһабетдин Мәрҗанинең, Мөхлисә Бубыйның, Гаяз Исхакыйның, Габдулла Тукайның, Салих Сәйдәшевнең, Нияз Даутовның һ.б.ның төп нөсхә фоторәсемнәре аеруча зур кыйммәткә ия булып санала.

Татар журналистлары Вафа Бәхтияров һәм Якуб Хәлилинең, сәүдәгәр Мусиннар, Даутовлар, Акчуриннар, Хәировлар, Вәлитовларның, шагыйрә Заһидә Бурнашева, шәрык белгече Зәйнәп Максудова, педагог Вәли Хаҗиевнең гаилә архивларыннан алынган фотосурәтләр дә татар халкы тарихын өйрәнүдә гаять кыйммәтле чыганаклар буларак бәяләнүгә лаек. ■

МАЙ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында



● Май башында «Җыен» нәшриятында «Шәхесләребез» сериясеннән «Таҗетдин Ялчыгол» китабы (төзүчеләре – Рөстәм Галиуллин, Ирек Һадиев, фәнни мөхәррире – Җәүдәт Миңнуллин) дөнья күрде.

● 1 майда Арча районының Казиле авылы мәчетенең 120 еллыгын билгеләп үттеләр.

● 2 майда Әстерханда «Татар гаиләсе» конкурсының финалы узды. Берьюлы ике гаилә – Агаевлар һәм Насыйбуллиннар җиңүче булып танылды.

● 2 майда мөселман дин эшлеклеләре Татарстан Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә Казан шәһәренең Яңа татар бистәсе зиратында Остазларны искә алу чарасына җыелды.

● 4 майда Кама Тамагы районының Мәрәтхуҗа авылында Татарстанның халык язучысы Туфан Миңнуллинны (1935-2012) искә алу чарасы үтте. Чарада дин әһелләре, әдипләр, сәнгатькәрләр, район хакимияте җитәкчеләре һәм әдипнең туганнары катнашты.

● 8 майда бер төркем зыялылар беренче театрыбызга нигез салган мәшһүребез Габдулла Кариев каберен зиярәт кылды. Чарада галим ИндусТаһиров, шагыйрьләр Разил Вәлиев һәм Ләбиб Лерон, дин әһеле Ильяс хәзрәт Җиһаншин, җырчы Миңгол Галиев, «Җыен» фондының директоры Фоат Рәфыйков, Г.Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачылар театры директоры Гүзәл Сәгыйтова һәм әлеге театрның баш режиссеры Ренат Әюпов, артист Эмиль Талипов һ.б. чыгыш ясады. Чараны «Болгар» фонды идарәсе рәисе Фәрит Мифтахов алып барды.

● 11 майда Әтнә театрында Башкорт дәүләт акадамия драма театры режиссеры, Башкортстан Республикасының Ш.Бабич исемендәге яшьләр премиясе лауреаты Илсур Юлай улы Казакбаев Анна Батуринаның «Фронтовичка» әсәрен сәхнәләштерергә җыена. Спектакльнең премьерасы 28-29 июнь көннәренә тәгаенләнгән.

● 12 майда Изге Рамазан аеның алтынчы көнендә Актаныш районында «Наил» дип аталган яңа мәчет ачылды. Аны ачу тантанасында Татарстан Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, Актаныш муниципаль район хакимияте башлыгы Энгель Нәвап улы Фәттахов һәм имам-мөхтәсиб Руслан хәзрәт Мортазин катнашты һәм чыгыш ясады.

● 14 майда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Актаныш район мәдәният йорты халык театры Н.Фәттах әсәренә нигезләнгән «Әтил суы ака торур» спектаклен күрсәтте. Артистларны һәм Казан тамашачыларын Актаныш муниципаль район хакимияте башлыгы Энгель Фәттахов һәм Актаныш якташлар җәмгыятенең Казандагы җитәкчесе Вәсим Вахитов котлады.

● 15 майда Казанның УНИКС бинасында «Белем.ру» җитәкчесе Раил Гатауллин оештырган «Әдәби марафон» бәйгесен йомгаклау чарасы узды. Чарада сәясәт эшлеклеләре, әдип һәм әдибәләр, аерым алганда, Разил Вәлиев, Римма Ратникова, Рабит Батулла, Равил Фәйзуллин, Мәдинә Маликова, Эльмира Шәрифуллина, Газинур Морат, Хәбир Ибраһим, Ләбиб Лерон, Ленар Шәех, Рифат Сәлах, Зиннур Хөснияр, Рафис Корбан, Айгөл Әхмәтгалиева катнашты һәм чыгыш ясады.

● 15 майда Зәйдә фән һәм әдәбият дөньясында киң танылу алган күренекле галим һәм язучы Хатыйп ага Миңнегуловка 80 яшь тулуга нисбәтле тантаналы кичә булып үтте.

● 17 майда сәгать 10да Татарстан Дәүләт Советында Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин массакүләм мәгълүмат чаралары җитәкчеләре белән очрашты. Әлеге чарада журналистларга дәүләт бүләкләре дә тапшырылды.

● 18 майда К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында «Минем Такташым» дигән опера (либретто авторы – Рүзәл Мөхәммәтшин, композиторы – Ильяс Камал) куелды.

● 18 майда Актанышның «Яшьлек» милли-мәдәни үзәгендә «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон китапханәчеләр һәм укытучылар белән очрашты.

● 18 майда Мөслимнең Үзәк китапханәсендә «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон китапханәчеләр, укытучылар һәм тәрбиячеләр белән әңгәмә корды. ■

Мирасворд

Киндер сукканда кыстырыла торган җеп

Хәснул Вәлиуллин операсы

Теш чистарткыч (иск.)

... Байҗиев (кыргыз әдибе)

... Бәдигый

... Гамзатов

Зөянең сул кушылдыгы

Әхсән Баян поэмасы

Шагыйрь ... Идиятуллин

Бөек Болгар дәүләтенә нигез салган хан

Габдулла Тукай яшәгән кунакханә

... Хачатурян

... Ши Мин

...-баба йоласы

Рикки-Тикки-Тавиның дошманы

Борынгы Идел

Себер шаманы

Элекке административ-территориаль берәмлек

Шагыйрә ... Сөләйманова

Рәт, мәгънә, җай

Якутларның элекке җәйге торагы

Фәнис Яруллин повесте

Сагыш төсе

Ашлык әрҗәсе

Гарәп язуында тартыктан соң сузык авазның булмавын күрсәтүче билге

Габдулла Тукайның 1909 елда язган шигыре

Себер халыкларының йомшак табанлы, озын кунычлы мех аяк киеме

Совет автомобиле

Әмирхан ...

Мәхмүт Хәсәновның «Язгы аҗаган» романындагы персонаж

Чех космонавты

Нота

Сугарга дигән көлтәләрне киптерү урыны

Кара көлсу төстәге ат

Җай, уңай, көй

Француз микробиологы

Шагыйрь ... Давыдов

Реклама газы

Гел, һәрвакыт (иск.)

Ишек, капка биге

Борынгы грек шагыйре

5 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: хираҗ, әл, мәхдүм, дан, бине, Наис, Марс, дая, сага, Бәркә, Шода, алман, керәч, акын, авар, «Уел», әзи, Ярлы, Рой, Аван, намә, ладья, хаҗ, мум, әгәр, Атаи, Арат.
Өстән аска: каган, Ямашев, Вахит, агора, Ама, брадәр, Нәҗми, әнис, ач, илхан, Ури, рәдде, аел, яраклы, Җаманаклы, камәр, «Адәмнәр», «Дуга», зольмәт, скандий.

***Рәис Габдулла** төзеде.*

Н.Җиһановның «Качкын» операсы афишасы

«Безнең мирас» елъязмасы /июнь

130 ел элек (1889)

Актер, режиссер, театр эшлеклесе, Хезмәт Батыры Зәки Баязитский ((Вәлиев (1889-1957)) туа.

110 ел элек (1909)

Казанда «Рус Щвейцариясе» паркы территориясендә Халыкара күргәзмә ачыла.

100 ел элек (1919)

Буа район газетасы «Байрак» («Знамя», «Ялав») чыга башлый.

100 ел элек (1919)

Шагыйрь Шәехзадә Бабич (1895-1919) фетнәчеләр тарафыннан үтерелә.

100 ел элек (1919)

Самарада «Таң» исемле татар театры труппасы оештырыла.

95 ел элек (1924)

Казанда Шамил Усманов җитәкчелегендә урам театрлары (фестивале) булып уза.

90 ел элек (1929)

Көнчыгыш педагогия институтының идарә утырышында Габдрахман Сәгъдине татар теле һәм әдәбияты кафедрасы профессоры итеп билгеләү турында карар кабул ителә.

85 ел элек (1934)

Совет язучылары союзына әгъзалар кабул итү Үзәк комиссиясенең утырышы була. Бу утырышта татар совет язучыларының Татарстан Совет язучылары союзын оештыру комитеты аркылы Үзәк комиссия карамагына җибәрелгән гаризалары карала. Комиссия Татарстан Совет язучылары союзына әгъза итеп түбәндәге иптәшләрне кабул итә: Г.Ибраһимов, Г.Нигъмәти, К.Нәҗми, К.Тинчурин, Ш.Камал, Г.Гали, Г.Толымбай, Ф.Бурнаш, М.Әмир, Х.Туфан, Ф.Сәйфи, М.Гали, И.Гази, М.Крыймов, М.Җәлил, Ә.Фәйзи, И.Туктаров, М.Максуд, Ф.Кәрим, С.Баттал, Т.Госманов.

Совет язучылары союзына әгъзалыкка кандидат итеп кабул ителүчеләр: Ш.Усманов, Р.Ишморатов, Б.Зернит, А.Шамов, Г.Мөхәммәтшин, Т.Гыйззәт, Ә.Ерикәй, Н.Баян, З.Гали.

80 ел элек (1939)

Н.Җиһановның «Качкын» операсы (Ә.Фәйзи либреттосы) белән Татар дәүләт опера һәм балет театры ачыла.

75 ел элек (1944)

«Ватан намусы өчен» газетасында «Беренче Украина фронтындагы татар сугышчыларыннан татар халкына җавап хаты» басылып чыга.

*Журналга **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■



СОДЕРЖАНИЕ. ИЮНЬ 2019

И останется в мире слово моё...: Зия Ярмаки

Историческое наследие: «Сююмбике». О.Иванова; «Краткая история одной школы». К.Назми, Я.Мамкиев, И.Хамзин; «Родник Тазетдина». Р.Ахунзянова; «Исламская религия в Казанском ханстве». А.Аксанов; «Чатские татары». Ф.Байрамова.

Татарский мир: Амир Гараев: « Богатство татарской культуры – наша гордость!»

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов.

Литературное наследие: «Наш рассвет». Халик Садри.

Кладезь памяти: «След Фатхуллиных». А.Зарипов.

Художественное наследие: «Древние татарские музыкальные инструменты». Р.Гилязов.

На страже памяти: «Национальная библиотека Республики Татарстан».

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT. JUNE 2019

There will be left my word in the world...: Ziya Yarmaki.

Historic heritage: «Suyumbike» by O.Ivanova; «Brief history of the school» by K.Nazmi, Y.Mamkiev, I.Khamzin; «Tazetdin's spring-well»; by R.Akhunzyanov; «Islam in the Kazan khanate» by A.Aksanov; «The Tatars of Chat» by F.Bayramova.

Tatar world: «Our dignity is the exuberancy of Tatar culture.

Religious heritage: «Islamic world» by Gabdurashit Ibragimov.

Literary heritage: «Our dawn» by Khalik Sadri.

From the deepest store of memory: «The Fatkhullins' legacy» by A.Zaripov.

Creative heritage: «The ancient Tatar national musical instruments».

On the guard of the memory: «The National library of the Republic of Tatarstan».

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation's life.

«Вак һөнәрчеләр». 1925. Киндер, майлы буяу



Григорий Медведев

Ставрополь краендагы Курск станицасында 1868 елда туа.

1894 елда Петербург сынлы сәнгать академиясен тәмамлый.

1920-1930 елларда Марий-Эль Республикасында иҗат итә.

Соңрак Казан сынлы сәнгать мәктәбенә нигез сала һәм аның директоры булып эшли.

1944 елда вафат була.

«Йөкчеләр Иделдә». 1929. Киндер, майлы буяу

«Сабан». 1901. Киндер, майлы буяу

татмедиа

Язык һәм от!

Телевизор, көнкүреш техникасы, башка күп кенә бүләкләр

Бүләкләр 2019 елның 16 августында уйнатылачак

1 ЯЗЫЛ — 30.06.2019 кадәр «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең кимендә өч басмасына языл (акциядә катнаша торган басмалар белән tatmedia.ru сайтында таныша аласың)

2 ҖИБӘР — язылу квитанцияләренең күчермәсен «Акция» билгесе белән түбәндәге адреска җибәр (телефон номерыңны күрсәтергә онытма!) Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 ОТ — телевизор, мультиварка, иттарткыч, блендер, йон юрган һәм башка призлар от

Реклама 16+

Акция турында тулырак – tatmedia.ru сайтында. Акцияне үткәрү вакыты: 22.04.2019 – 20.09.2019
Заявкалар 2019 елның 20 июленә кадәр кабул ителә. Оештыручы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.